ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№08 (403)
АВГУСТ 2025

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

РОССИЯ – КЫТАЙ: ЗУР МӨМКИНЛЕКЛӘР ВАКЫТЫ



№08 (403)
АВГУСТ 2025

16+

Редакция:
Адрес: 420066, Россия,
Татарстан Республикасы,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина, vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров, sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов, Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Авторлар: Олеся Бондаревская, Илсөяр Закирова, Фәнзилә Җәүһәрова, Олег Платонов, Айдар Шәйхин, Әхмәт Шакиров
Фотографлар: Александр Ефремов, Айдар Мөшәрәпов, Лилиана Вәлитова
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Аида Демьянова, Wanmei Trade консалтинг агентлыгы җитәкчесе. Аида Демьянова архивыннан

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы ордены белән бүләкләнә

ММЧ исеме: ТАТАРСТАН TATARSTAN

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды. Адрес: 420066, Россия, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: М-1503
Басарга кул куелды: 14.08.2025
Чыгу көне: 20.08.2025

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900

Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Ирина Захарова, irinamoroz10@mail.ru

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

РЕДАКЦИЯДӘН

ҖӘЙ ДӘВАМ ИТӘ

Җәйге көннәр күзгә күренеп кимүгә таба бара. Бу мәңгелек, туктатып калып булмый торган гаделсез процессны ничек соң беераз гына салмакландырырга? Ничек кенә бу матур көннәрне озынайтырга?

Хәер, сәбәпләр юк түгел, бар бит! Әле алда безне күркәм бәйрәмнәр көтә. Август азагында Республика һәм шәһәр көнен билгеләп үтәсебез бар. Татарстан бу бәйрәмгә нинди уңышлар белән килә? Яраткан республикабыз, меңьеллык тарихка ия мәркәзебез ирешкән казанышлар турында август санында укып белә аласыз. Бәйрәмнәр дигәннән, татар вакытлы матбугатының беренче карлыгачы – Петербургта басыла башлаган «Нур» газетасының 120 еллыгы да әле безне. Сүз уңаеннан, бу санда Матбугат йортының 90 еллыгына багышланган язманы да укый аласыз.

Бездә дә – бәйрәм: «Татарстан»ның юбилеена да ерак түгел. Инде җиң сызганып әзерләнә башладык. Шуңа күрә җәй рухы дәвам итә, дип ышандырып әйтә алабыз.

Сезнең бәйрәмнәр яратучы редакциягез

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзүм Хәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
Адрес: 420097, Россия,
Татарстан Республикасы, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2025 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1305 сум 00 тиен китереп бирешле,
1274 сум 28 тиен соратып алганда.
2025 елга ТР буенча язылу бәясе:
2610 сум 04 тиен китереп бирешле,
2548 сум 46 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 104 ЯШЬ

ТАТАРСТАННЫҢ 100 җәүһәре

бары тик ТАТАРСТАНДА



КАЗАНДА – ПЕТЕРБУРГ ЧАГЫЛЫШЫ

Нева елгасы ярындагы шәһәр Казанның меңьеллыгына тулы бер урам бүләк итә. Петербург урамын 2005 елның 24 августында ачтылар. «Татарстан үзе дә Санкт-Петербург шәһәренең 300 еллыгына яңартылган Казан урамын бүләк итте, – дип аңлатты ул вакытта Төньяк башкала губернаторы Валентина Матвиенко, – хәзер Невадагы шәһәр Казанга урам бүләк итә». Анда Васильев утравы, Неваның гранит яр буе, Петербург күперләре, Казан өчен бик күпне эшләгән патшабикә Екатерина II 1767 елда әлеге шәһәргә утырып килгән «Тверь» галерасы чагылыш таба. «Әмма иң мөһиме, бу урамда Петербург рухы сакланган, – диде Валентина Матвиенко. – Һәм без Казан тарихында шәһәребезнең бер өлеше, Санкт-Петербург почмагы мәңгегә калыр дип өметләнәбез».

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Хезмәттәшлек юнәлешләре
Татарстан белән Кытай арасында нинди элемтәләр үстерелә

6. Чәкчәкме, әллә шацимамы?
Кытай кухнясы татарныкына кай ягы белән охшаган

8. «Бер пояс һәм бер юл»
Логистика терминалы илләрне һәм континентларны ничек якынайта

16. Бөекләрнең зирәк сүзләре
Алар аңлашуга ничек ярдәм итә

20. Цин дәвере җәүһәрләре
Алар нинди серләрне саклый

22. Кытайга күпер
Казан студенткасы аны ничек «салган»

26. Хаостан – яңа базарларга
Цифрлы чишелешләр бизнеска ничек булыша

игелекле эшләр

30. Казан. Миллениум
Шәһәр үзенең меңьеллыгына нәрсәләр алган

36. Киләчәк буынга юллама
Кем аны уйлап тапкан

50. Татарстан табигате
Бөек Шишкин каян илһам алган

54. Гамьле әңгәмә
Рәшит Сабиров ничек яшь булып калган

58. 41 ел балалары
Сугыш чоры балалары нинди авырлыклар күргән

мәңгелек кыйммәтләр

62. Беренче татар газетасы
Төньяктан нинди «Нур» тарала

66. 30 нчы еллардан калган Матбугат йорты
Бина нинди раритетларны саклый

77. Китап киштәсе
Татар әсирләренең җырлары туган илгә ничек кайта

80 Татарстан авыллары
Көмеш-Күл күлләрендә нинди балыклар йөзә

88. Казанның агач архитектура һәйкәлләре
Мәрҗани йорты ничек сакланган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
protatarstan.ru

Фото: tatar-inform.ru

Акыллы гамәлләр

21.07

Кирилл, Мәскәү һәм бөтен Русия патриархы, – Казан Кремлендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов белән очрашуда:

– Сез Россия төбәкләре һәм элеккеге Советлар Союзының барлык илләре өчен үрнәк булып торасыз. Православие һәм мөселман җәмгыятьләре вәкилләре күпләп яшәгән төбәкләрдә сезнең динара мөнәсәбәтләрне оештыру тәҗрибәгезгә ихтыяҗ зур булырга мөмкин. Мин һәрвакыт сезнең имин республикагызга рәхәтләнеп киләм һәм беркайчан да бу халәтемнән ваз кичеп китмим. Сезгә, Татарстан Хөкүмәтенә һәм Сезнең аша ислам дине әһелләренә рәхмәтемне белдерәм.

23.07

Виталий Савельев, Россия Хөкүмәте Рәисе урынбасары:

– Татарстанда транспорт комплексын үстерү буенча эзлекле һәм системалы эш алып барыла. 2024 елда республиканың барлык аэропортларында хезмәт күрсәтелгән пассажирларның гомуми саны 6 миллионнан артык кешене тәшкил итте. Бүген без «Казан» халыкара аэропортының яңа терминалы проекты белән таныштык. Шулай ук Яшел Үзәннең Горький исемендәге заводында җыела торган «Метеор 2020» тизйөрешле судносын да карадык. Татарстан предприятиеләре транспорт мегапроектларын гамәлгә ашыруда катнаша. Мәскәү – Санкт-Петербург югары тизлекле магистрален төзү өчен «Нацпроектстрой» КАМАЗда чыгарыла торган 400 берәмлектән артык махсус техника сатып алырга планлаштыра.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

25.07

Айгөл Латыйпова, Казанның Парклар һәм скверлар дирекциясе җитәкчесе:

– Яшелләндерү турында уйларга һәм шәһәрдә машинаны түгел, ә кешене беренче урынга куярга өйрәнергә кирәк. Дөньяда шәһәрләшү дәрәҗәсе югары, әмма шул ук вакытта агач-куаклар, күпьеллык чәчәкләргә күмелгән калалар да шактый. Сүз парклар турында гына бармый, анда автотрассалар, юл чишелешләре, гомуми файдаланудагы юллар – барысы да яшеллек эчендә. Бу зур шәһәрләрдә яшәүчеләргә «кислород белән туенырга» һәм өйләренә ял итеп кайтырга мөмкинлек бирә. Минем фикеремчә, 5–10 елдан Казан нәкъ шундый булырга тиеш.

Фото: tatar-inform.ru, government.ru, kzn.ru

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр/
мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстанга **күпме** Кытай инвестициясе җәлеп ителде

Ни өчен Ленин музее кытайларда зур кызыксыну уята

Көндәшлек профессиональлеккә **ничек** йогынты ясый

Алабугада Цин дәверенең **нинди** җәүһәрләре «яши»

Казан студенткасы **ничек** Кытайга «күпер сала»

РОССИЯ, ТАТАРСТАН – КЫТАЙ:

Россия – Кытай
товар әйләнеше

2024 елда

244,8
МЛРД $*

1,9%
2023 ЕЛ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДАГЫ ҮСЕШ

Татарстан – Кытай
товар әйләнеше

2024 елда

3,3
МЛРД $

9%
2023 ЕЛ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДАГЫ ҮСЕШ

39 МЛН $

2024 елда Татарстанга Кытай инвестицияләрен җәлеп итү күләме

20 МЛН $ АРТЫК

2023 елда Татарстанга Кытай инвестицияләрен җәлеп итү күләме

Татарстан – Кытай
товар әйләнеше

2023 елда

3 МЛРД $ АРТЫК

2 тапкыр
2023 ЕЛ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДАГЫ ҮСЕШ

1,6 МЛРД $ → **2022 елда Татарстан – Кытай** товар әйләнеше

ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫРЛАРЫ

2024 ел

Материктагы Кытайдан

1 МЛННАН АРТЫК

граждан** 2024 елда Россияне беренче сәфәрләре өчен сайлаган

209,3%

2023 ЕЛ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДАГЫ ҮСЕШ

200 МЕҢНӘН АРТЫК

Кытай туристы Казанга килде

84%

2023 ЕЛ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДАГЫ ҮСЕШ

1,5 МЛННАН АРТЫК

Россия туристы материктагы Кытайга барды

115,1%

2023 ЕЛ БЕЛӘН ЧАГЫШТЫРГАНДАГЫ ҮСЕШ

Татарстанда теркәлгән

100дән АРТЫК КОМПАНИЯНЕ,

гамәлгә куючылар – Кытай бизнесменнары

70%

СОҢГЫ 2 ЕЛДАГЫ ҮСЕШ

ТАТАРСТАННАН КЫТАЙГА ЭКСПОРТЛАНА ТОРГАН ТОВАРЛАР:

каучук, нефть продуктлары, пластмасса эшләнмәләр, рапс мае, җитен мае, бодай, борчак, сөт продукциясе, кондитер эшләнмәләре, тавык тәпиләре

2,6 МЕҢГӘ ЯКЫН

Кытай студенты Татарстанда укый

Казанда **КЫТАЙНЫҢ ГЕНЕРАЛЬ КОНСУЛЛЫГЫ** уңышлы эшли,

Пекинда исә **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘҮДӘ-ИКЪТИСАД ВӘКИЛЛЕГЕ БАР**

* *КХР баш таможня идарәсе мәгълүматлары буенча*
** *Кытай статистикасы мәгълүматлары буенча*

НИ ӨЧЕН КАЗАНДА ӘЙБӘТ, Ә КЫТАЙДА ТАГЫН ДА ЯХШЫРАК. ҺӘМ КИРЕСЕНЧӘ

Кытай Халык Республикасының Казандагы Генераль консулы Сян Бо безгә ни өчен кытайларда Ленин музее кызыксыну уятуы һәм чәкчәкнең нинди җылы хисләр кузгатуы турында сөйләде.

ТУРИЗМ ЕЛЛАРЫ ТУРЫНДА

– Туризм буенча хезмәттәшлек Кытай һәм Россия арасындагы гуманитар элемтәләрнең мөһим өлешенә әйләнде. 2012–2013 елларда безнең илләр үзләрендә Туризм еллары оештырдылар. Соңгы елларда кайбер уңышлы чаралар күрелү нәтиҗәсендә ике яктан да туристлар агымы сизелерлек артты. Моңа шул исәптән Кытай һәм Россия хөкүмәтләре тарафыннан кертелгән виза сәясәте һәм илгә туристлар керүне җайлау да ярдәм итте.

ШАНХАЙДАН – КАЗАНГА. КАЗАННАН – ШАНХАЙГА

Татарстан Республикасы бай туристик ресурска ия, биредә кунакчыллык индустриясе алга киткән. Казанның мең еллык тарихы бар, ул – халыкара мәйданда танылу алган һәм Кытай туристларын җәлеп итәрлек истәлекле урыннарга ия шәһәр.

Узган елның сентябрендә Шанхай – Казан авиарейсы ачылды. Ул инде тулы көченә эшли, әлеге вакыт аралыгында 48 000 нән артык пассажирга хезмәт күрсәтелде. Болар барысы да үзара сәфәрләргә сизелерлек ярдәм итә. 2024 елда Казанга Кытайдан 20 000 нән артык турист килгән, бу, үткән ел белән чагыштырганда, 84%ка күбрәк.

Казан Кремле, Зөя утрау-шәһәре һәм борынгы Болгар шәһәре ЮНЕСКО Бөтендөнья мирасы исемлегенә керә һәм күп кенә Кытай сәяхәтчеләрен җәлеп итә.

ЛЕНИН МУЗЕЕ КЫТАЙЛАРДА КЫЗЫКСЫНУ УЯТА

Казанда В.И. Ленин музей-йорты туристлар арасында аеруча популяр, чөнки нәкъ менә монда яшь Ленин революцион юлны сайлаган – бу тарихи чор кытайларда зур кызыксыну уята. Кытай – Россия туристлык хезмәттәшлеге үсеше тирәнәя барган саен, киләчәктә Кытай туристлары Татарстан Республикасына Казанның уникаль шәһәр цивилизациясен һәм аның Мәскәү белән Санкт-Петербургтан аерылып торган күпмилләтлелеге кушылмасын тою өчен килерләр, дип уйлыйм.

Фото: tatr-inform.ru, Александр Ефремов



Кытай Генераль консулының яраткан урыны – Казансу яр буе.

Кытай Халык Республикасы Генераль консуллыгы ишегалдындагы алмагачлар быел бик шәп уңыш биргән. Сян Бо әфәнде гаиләсендә Казан алмаларын яраталар.

Казанда В.И. Ленин музей-йорты туристлар арасында аеруча популяр, чөнки нәкъ менә монда яшь Ленин революцион юлны сайлаган — бу тарихи чор кытайларда зур кызыксыну уята.

КЫТАЙ СТЕНАСЫННАН – ТЫЕЛГАН ШӘҺӘРГӘ КАДӘР

Кытай – дөньяда иң зур илләрнең берсе, аның халкы илләр гизәргә ярата, үзе дә туристлык ресурсларының гаҗәеп күптөрлелегенә ия популяр туризм юнәлеше: борынгы Бөек Кытай стенасыннан һәм тыелган Гугун шәһәреннән алып Шанхайдагы заманча Вайтань яр буена һәм Гуанчжоу телебашнясына кадәр; Сиань Терракота армиясеннән һәм Дуньхуандагы Могао мәгарәләреннән алып, меңьеллык мәдәниятне үз эченә алган Гуйлинь һәм Цзючжайгоуның матур пейзажларына кадәр. Кытайның территориясе зур, транспорт элемтәсе уңайлы итеп эшләнгән һәм туристлык маршрутлары да бик төрле. Без Татарстандагы дусларны Кытайга, аның гаҗәеп матурлыгын ачарга кунакка чакырабыз.

ЧӘКЧӘК ҺӘМ ШАЦИМА

Идел буе төбәгенең кулинария культурасы гаять бай, һәм татар аш-сулары – аның үзенчәлекле «визит карточкасы». Казанга килгәннән бирле мин бик күп татар ризыкларын авыз итеп карадым. **Миңа бигрәк тә чәкчәк ошады. Атланмайга изелгән йомшак камырдан, балдан ясалган бу милли сый формасы буенча да, тәме буенча да кытайларның яраткан тәм-томы – шациманы хәтерләтә, нииндидер бер җылы тану хисе уята.** Миңа шулай ук өчпочмак белән токмач ошый.

КЫТАЙНЫҢ СИГЕЗ КУЛИНАРИЯ МӘКТӘБЕ

Кытайда ашау культурасы шактый төрле һәм бай. Традицияләр, климат һәм әзерләү ысуллары йогынтысында Кытайда Сигез бөек кулинария мәктәбе формалашкан. Кытай мәкалендә әйтелгәнчә: **«көньякта – татлы, төньякта – тозлы, көнчыгышта – борычлы, көнбатышта – әче», бу исә Кытай кухнясының төрлелеген чагылдыра**. Аеруча билгелесе – Пекинча үрдәк – Кытай кухнясының символына әйләнгән тирән тарихлы ризык. Аны әзерләү чын сәнгатькә тиң: симез, нәфис Пекин үрдәген тиресе кетердәгәнче җиләк-җимеш утыны ягылган утта кыздыралар, шулай иткәндә итнең сусыллыгы һәм кабатланмас тәме саклана. Кытайның төрле төбәкләрендәге кулинария җәүһәрләрен шәхсән күреп, татып карар өчен Россиядәге дусларны Кытайга чакырабыз.

«БЕР ПОЯС ҺӘМ БЕР ЮЛ»: ИЛЛӘР АРАСЫНДАГЫ КҮПЕР

2024 елның октябрь азагы. Татарстаннан тимер юл буйлап Кытайга йөк поезды кузгала. 76 контейнерда – гадәти чөгендер түбе. Ләкин аны океан лайнерын беренче рейсына җибәргәндәй тантаналы нотыклар һәм файерлар белән озатып калалар. Вакыйга чыннан да моңа лаек, гәрчә бу очракта «корабль»не түгел, «причал»ны котласалар да. Дөресрәге, илдә иң эре «Бер пояс һәм бер юл» логистика терминалын.

Әхмәт Шакиров

Бер километрдан артык озынлыктагы йөк төяү урыны (анда берьюлы ике составны кабул итеп, эшкәртеп була), 8 мең стандарт контейнерны урнаштыра алу мөмкинлеге, 170 мең квадрат метр мәйданга ия автоматлаштырылган заманча склад комплексы. Складларда, куркыныч төрләрдән кала, барлык йөкләр дә саклана ала. Өстәвенә, 4 мең квадрат метрдан артык мәйдан аерым кросс-докинг зонасына бирелгән... Бирелә йөкне, складка урнаштырып тормыйча гына, башка контейнерларга төяргә була. Сүз Татарстанның Тукай районында эшли башлаган «Бер пояс һәм бер юл» терминалы турында бара.

ВАКЫТ АКЧА БЕЛӘН ИСӘПЛӘНГӘНДӘ

Тимер юл буйлап даими рәвештә йөк җибәрергә һәм кабул итәргә кирәкмәгән бәхетлеләр өчен без атаган саннар, бәлки, кызык та түгелдер. Ә менә юлларның, төяп-күчерү үзәкләренең җитмәве, технологияләрнең иске булуы аркасында, еш кына товар кайтартуның һәм озатуның никадәр газаплы булуын үз тәҗрибәләрендә татып караган эре, урта һәм хәтта вак эшкуарлык вәкилләре өчен бу зур уңайлыклар тудыра. Әйтик, Кытайдан йөк поезды килә, җиде дистә контейнерга төялгән комплектлау әйберләрен һәр станциядә дә бушатып булмый. Моның өчен көн түгел, кайчак бер атна да җитми, ә вакыт, билгеле булганча, акча белән исәпләнә.

«Бер пояс һәм бер юл» терминалының мөмкинлекләре бөтенләй башка. Төп үзенчәлекләрнең берсе – тимер юл составы бик тиз бушатыла, төяләә. Монда өч сәгатьтән дә кимрәк вакыт эчендә һәм берниндиндипдомамм өстәмә чыгымнарсыз тулы бер контейнер поездына хезмәт күрсәтелә ала. Алай гына да түгел, терминал берьюлы ике составны эшкәртә. Шул ук вакытта комплексның урнашу урыны да бизнес өчен уңайлы. Якында гына Чаллы, Түбән Кама һәм Алабуга, махсус икътисадый зона предприятиеләре. М-12 федераль трассасына кадәр – унике

Фото: alabuga.ru

километр, Бигеш халыкара аэропортына кадәр тагын да якынрак...

Ниһаять, иң мөһиме турында. Логистика комплексын оештыручыларның фикеренчә, проект Россия – Кытай маршрутында экспорт һәм импорт йөкләрен бер ноктада берләштерергә мөмкинлек бирә. Әйтик, Кытайга Татарстаннан нефть химиясе һәм авыл хуҗалыгы продукциясе озатыла, ә кире юнәлештә сәнәгать предприятиеләре өчен компонентлар һәм комплектлау өлешләре һәм халык куллану товарлары, шул исәптән маркетплейсларда сатып алынган продуктлар китерелә. Һәрхәлдә, терминал ачылышында контейнер терминалы атна саен, ким дигәндә, берәр йөк поездын кабул итәчәк һәм кире Кытайга җибәрәчәк, дип белдерделәр. Россия тимер юлларының җитмәве шартларында, ягъни буш контейнерларны яңадан җибәрү озакка сузылган һәм чыгымлы квестка әверелгәндә, мондый схема – бизнес өчен вакытны сизелерлек кыскартырга һәм акчаны янга калдырырга сәләтле идеаль ысул.

ИМПОРТ ТАБЫЛЫР. Ә ЭКСПОРТ?

Бу схема, сүз уңаеннан, «Бер пояс һәм бер юл» терминалы эшенең беренче көннәрендә үк уңышлы сыналды. Бездән Кытайга чөгендер түбе тутырылган 76 контейнерлы техник рейс китте, ә моңа кадәр алардан әлеге контейнерларда «Алабуга» МИЗда эшли торган «Соллерс» предприятиесе өчен комплектлау детальләре килгән иде. Сынау моделе практикада үзенең яшәү сәләтен исбатладымы?

Скептикларның бу хакта үз фикере бар. Бүген Россиягә Кытайдан товар күбрәк кертелә, димәк, импорт күләме экспорттан артыграк. Куәтле сәнәгать потенциалы булган Татарстан да искәрмә түгел. 2024 ел нәтиҗәләре буенча Кытайга безнең республикадан озатылган товар күләме, кертелгәнгә караганда, ике тапкырга кимрәк. Димәк, бушралы маршрутлар һәм контейнерларны максималь нәтиҗәле куллану турында сөйләргә иртәрәк?

Әмма монда, мөгаен, уникаль логистика үзәге булдыру идеясе Кытай белән хезмәттәшлекне җитди киңәйтүне күздә тоткан фаразларга таяна дип әйтергә кирәктер. Һәм бу фаразлар тулысынча аклана, өстәвенә, товар әйләнешен үстерү юнәлешендә генә түгел, Кытайга экспортны арттыру ягыннан да. Аерым алганда, узган ел Кытай белән Татарстан арасында товар әйләнеше беренче мәртәбә 3,3 миллиард долларны тәшкил итте, тугыз процентлы үсеш күрсәтте. Әйе, Татарстан Республикасыннан Кытай Халык Республикасына экспорт импорттан ике мәртәбә кимрәк булды, әмма шул ук вакытта ул шактый югары үсеш күрсәтте: әле бер ел элек кенә Кытайга Татарстаннан товарлар, китерелгәнгә караганда, дүрт мәртәбә кимрәк җибәрелә иде. Алай гына да түгел, Татарстан Республикасының экспорт потенциалы арта барачак.

Ниһаять, терминалның уникаль мөмкинлекләреннән файдаланыр өчен билгеләнгән төп юнәлеш Кытай белән генә чикләнергә тиеш түгел. Контейнерлы составлар Себергә, Ерак Көнчыгышка, Көньяк-Көнчыгыш Азия, Үзәк Азия илләренә китә һәм кире кайта ала. Потенциаль маршрутлар географиясе зур, асылда, потенциаль клиентлар саны да чикләнмәгән.

ЧИКЛӘРСЕЗ ҺӘМ КАРШЫЛЫКЛАРСЫЗ МАРШРУТ

Аңлашыла ки, барысына да берьюлы ирешү, ягъни куәтле комплексның тулы йөкләнешен тәэмин итү һәм кыска вакыт эчендә аннан максималь нәтиҗәле файдалану мөмкин түгел. Һәм монда күп нәрсә, мөгаен, «Бер пояс һәм бер юл» логистика

терминалы операторының контейнерлы ташуларны оештыручы компанияләр белән үзара хезмәттәшлегенә бәйледер. Соңгылары мондый хезмәттәшлекнең уңайлылыгын һәм файдасын тоярга тиеш. Тукай районында комплекс эшли башлаганнан бирле бер елдан азрак вакыт узды. Асылда, бу вакыт аралыгы эре компанияләрнең яңа мөмкинлекләр белән ни дәрәҗәдә кызыксынулары турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә ала.

Логистика терминалының көндәлек эше – бу сорауга җавап бирергә мөмкинлек бирә торган үзенчәлекле лакмус кәгазе. 2025 елның июне, гадәти эш көннәренең берсе. «Бер пояс һәм бер юл» – инде даими сервис кысаларында – Кытай Халык Республикасыннан «СВС Контейнер» компаниясе белән берлектә оештырылган беренче чит ил поездын кабул итә. Поездны каршы алу тантанасында «СВС Контейнер» компаниясенең коммерция директоры Михаил Михалев ассызыклаганча, алар тәкъдим ителә торган сервисның даимилеген, ешлыгын һәм сыйфатын беренче урынга куя, шулай ук «Бер пояс һәм бер юл» контейнер терминалы клиентлары өчен транспорт логистикасын оптимальләштерергә омтыла. «Бер пояс һәм бер юл» ЛК башкарма директоры Хәйдәр Вәлиуллин, үз чиратында, партнёрына терминалның импорт юнәлешен үстерүгә керткән өлеше өчен рәхмәтен белдерде.

Ачыкланганча, «СВС Контейнер» Кытай һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия портларыннан контейнерлы йөкләр ташуны оештыру буенча даими сервисны уңышлы эшләп чыккан. Әлеге сервис диңгез юлы белән Ерак Көнчыгыш портларына товар китереп җиткерүне үз эченә алган мультимодаль логистика схемасыннан гыйбарәт. Аннан соң товар Ерак Көнчыгыш Транспорт компаниясенең коры терминалыннан Круглое Поле станциясенә кадәр – «Бер пояс һәм бер юл» контейнер терминалына тимер юл белән озатыла. «СВС Контейнер» товарларны әлеге ысул белән даими рәвештә аена ике тапкыр китерүне планлаштыра.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: Кытайдан товар китертүне оештыру сервисын кертү, асылда, «СВС Контейнер» һәм «Бер пояс һәм бер юл» логистика компаниясе арасындагы хезмәттәшлекне үстерүдә икенче җитди адым санала. Беренчесе, эш көндәлегеннән күренгәнчә, яз көне була. Ул чакта Ерак Көнчыгыштагы Угловая станциясеннән (Приморье крае) Татарстандагы терминалга кадәр даими тимер юл контейнерлы йөк ташу сервисын эшләтеп җибәрү турында килешәләр.

Әлеге сервис эшли башлаганда, Татарстан логистика компаниясенең башкарма директоры Хәйдәр Вәлиуллин аны «ике як өчен дә перспективалы үсеш юнәлеше» дип атады. Ике як та ул вакытта яңа сервисны тышкы сәүдә өчен дә кулланачаклары турында белдерде: Кытай, Көньяк Корея һәм Көньяк-Көнчыгыш Азиянең башка илләре портларыннан йөкләрне диңгез буйлап ташу күздә тотылды. Июнь вакыйгалары бу планнарның уңышлы тормышка ашырылуын күрсәтте.

Тагын бер эш көне, 2025 елның язы. Терминалдан нефть коксы төялгән поезд китә. Аны Кытайга җибәрүне һәм китертүне Татарстанда контейнер терминалы белән идарә итә торган «Бер пояс һәм бер

юл» логистика компаниясе һәм Кытайда иң зурлардан саналган China Shandong International Economic & Technical Cooperation Group Ltd (Shandong Hi-Speed холдингына керә) транспорт-инфраструктура компаниясе тәэмин итә. Поездны озату – «хезмәттәшлеккә яңа старт», дип белдерде тантанада China Shandong International Economic & Technical Cooperation Group Ltd компаниясенең Россиядәге филиалы генераль директоры Лю Чжуняо. «Без киләчәктә дә хезмәттәшлекне һәм үзара файдалы элемтәләрне ныгытырга ниятлибез», – диде топ-менеджер. «Ике компания дә Россия белән Кытай арасында йөк ташуны оптимальләштерү өчен көчләрен берләштерергә әзер», – дип дәвам итте Хәйдәр Вәлиуллин.

ИКЪТИСАДЫЙ ҮСЕШ ДРАЙВЕРЫ

Күргәнебезчә, «Бер пояс һәм бер юл» логистика терминалы эшенең беренче айлары аның кирәклеген, бүгенге куәтен һәм киләчәктәге мөмкинлекләрен ачык күрсәтә. Өстәвенә, безнең компания портфелендәге партнерлардан тыш, – төрле дәрәҗәдәге хезмәттәшлек һәм килешүләр, аерым алганда, FESCO Транспорт төркеме, «ТРАНЗИТ», Казахстанның KTZ кебек компанияләр белән. Соңгысы белән хезмәттәшлек турында килешү – йөк ташу ысулларын оптимальләштерү һәм аларның нәтиҗәлелеген арттыру максатында ике илнең көчен берләштерү юлы белән бердәм логистика системасын оештыруда җитди алга китү мөмкинлеге.

Болар барысы да, исегезгә төшерәбез, әле эшләрнең башы гына. Шуны да онытмаска кирәк: 51 миллиард сумнан артык инвестиция салынган логистика комплексы проекты әле йөз процентка тормышка ашырылмаган. Инфраструктураның кайбер объектларын төзеп бетерәсе бар. Проектны гамәлгә ашыруда төп максатларның берсе – полимерларны контейнерларга төяү һәм Азия-Тын океан төбәгенә экспортка җибәрү. Бу максат та хәл итү стадиясендә. Монда күп нәрсә «Этилен-600» сәнәгать паркын сафка бастыру вакытына бәйле.

Тик бер генә нәрсә экспертларда шик тудырмый. «СВС Контейнер» компаниясенең коммерция директоры Михаил Михалев билгеләп үткәнчә, терминалның Татарстанда урнашуы стратегик яктан «аны транспорт системасында төп звенога әйләндерә һәм йөк агымын берләштерү өчен ныклы нигез булдыра». Ә Ерак Көнчыгышны Россиянең үзәк өлеше белән тоташтыра торган тотрыклы һәм нәтиҗәле логистика маршрутын формалаштыру «мультимодаль логистика үсеше өчен яңа мөмкинлекләр ачып кына калмыйча, икътисадый үсеш һәм эшлекле активлыкны арттыру өчен стимул да булачак».

Терминал атна саен Кытайдан, ким дигәндә, бер контейнер поездын кабул итәргә һәм җибәрергә планлаштыра. Бу Азия илләре белән Россия төбәкләре арасында, шул исәптән Идел буе федераль округында, өзлексез логистика маршрутлары формалаштыра. Проект тышкы икътисадый активлыкны үстерү драйверы булырга һәм илнең экспорт потенциалын арттырырга ярдәм итәргә тиеш.

Фото: Аида Демьянова архивыннан, tatar-inform.ru, rais.tatarstan.ru. РЕКЛАМА

РОССИЯ–КЫТАЙ: ЗУР МӨМКИНЛЕКЛӘР ВАКЫТЫ

Николай Крушинин

Аида Демьянова, Wanmei Trade* консалтинг агентлыгы җитәкчесе, – безнең журналның даими кунагы. «РОСТКИ: Россия һәм Кытай» Өченче Халыкара форумы алдыннан – бигрәк тә кадерле кунак, чөнки ул Кытай белән бизнес алып бару буенча шәп белгеч. Нәкъ менә Россия–Кытай бизнесы хакында сөйләшәчәкбез дә аның белән бүген. Татарстан–Кытай багланышларына аерым басым ясап, әлбәттә.

– Аида, Кытай, дөньядагы ситуация белән бергә, өзлексез үзгәрешләр кичерә. Без моны күреп-күзәтеп торабыз. Әйтегез әле, Кытай бизнесы белән эш итүдә бүген нинди үзгәрешләр аеруча күзгә ташлана?

– Әйе, сез хаклы: Кытай базары – үсешүзгәрешләр кичерә торган, динамикадагы тере организм. Теләсә нинди катлаулы система шикелле үк, ул – һәрдаим трансформациядә. Бигрәк тә хәзерге глобаль тотрыксызлык шартларында. Кытайның эчке ландшафты гына түгел, ә Россия партнёрлары белән аралашу, багланышлар кору форматы да үзгәреш кичерә. Берничә ел элек актуаль булган кайбер нәрсәләр инде андый түгел, әйтик, аерым бер логистика чылбырлары, түләүләр буенча өстенлекләр, я булмаса, килешүләр структурасы. Кайсыберләре үзгәрде, кайсыберләре бүген элеккечә эшләми, кайсыберләре адаптацияне, яңа шартларга яраклаштыруны таләп итә. Бу үзгәрешләр Кытай тәэминатчылары һәм җитештерүчеләре тарафыннан да тәкъдим ителә, шулай ук – Россия эшкуарлары ягыннан да. Соңгылары да торган саен күбрәк турыдан-туры сәүдә итү ысулын сайлауга йөз тота, җитештерү белән кооперация өлкәсендә дә хәлләр шундыйрак.

УРТАК ПРОЕКТЛАРНЫҢ КҮБӘЮЕ

– Үзгәрешләрнең берничә төп тенденциясен аерып күрсәтә аласызмы?

– Әлбәттә, соңгы арада берьюлы берничә кызыклы һәм әһәмиятле тренд пәйда булды. Аеруча күзгә ташланганнарының берсе – **Кытай җитештерүчеләренең Россия маркетплейсларына актив үтеп керүе**. Без Кытай компанияләренең арадашчылар аша товар тәкъдим итүен генә түгел, ә үзләренең, Россиягә килеп, юридик яктан теркәлүен, фулфилментлар, складлар ачуын, Wildbeeries, Ozon һәм башка мәйданнарны үзләштерүен күреп торабыз. Бу аларга логистиканы оптимальләштерергә булыша, товарның үзкыйммәтен төшерергә ярдәм итә. Һәм, болардан тыш, кулланучыга турыдан-туры якын булырга да.

Алай гына да түгел, бүген шактый күп Кытай компанияләре Россияне товар сату урыны итеп кенә түгел, ә **җитештерүне җайга салу мәйданы итеп тә күрә**. Бездә инде Кытай партнёрлары җитештерүне урнаштыру тәкъдиме керткән кейслар да бар: алар хәзерге шартларда РФ территориясендә җитештерүне оештыру Кытайдан товар китерүгә караганда файдалырак булырга мөмкин икәнен яхшы аңлый. Бигрәк тә – таможня пошлиналары алышынып, валюта курсы тирбәлеп торган вазгыятьтә. Чөнки логистикага киткән чыгымнар бу очракта үзен акламый.

Шул ук вакытта без капма-каршы тенденцияне дә күрми кала алмый-

Россия–Кытай бизнес-форумында тәрҗемәче сыйфатында катнашу. Шанхай, 2023.

* Ванмей трейд.

«РОСТКИ» Икенче Халыкара форумында тәрҗемәче буларак катнашканнан соң. 2024 ел.

быз – Россия клиентларыннан да нәкъ менә Кытайда **контрактлы җитештерүләр ачу** мөрәҗәгатьләре дә ешайды. Бу Кытай масштабларына һәм фабрикаларына юл ачарга тырышу гына түгел, бу андагы финанс системасының бизнес өчен шартлары гаять кызыктыргыч булуына да бәйле. Мисал өчен, КХРдагы түбән кредит ставкалары ил территориясендә урнашкан җитештерүләр өлкәсендә конкуренцияне шактый дәрәҗәдә арттыра. Без хәтта турыдан-туры Кытайда эшләячәк клиентлар өчен индивидуаль техник чишелешләр дә әзерлибез, әлбәттә, бу вакытта андагы спецификаны, логистиканы истә тотабыз.

Мондый очраклар аз түгел. Мәсәлән, Минпромторг мәгълүматларына караганда, 2025 елның беренче яртысында гына да җиңел сәнәгать өлкәсендә һәм машиналар җыю юнәлешендә Кытай капиталы кергән проектлар узган елдагыдан 30%ка арткан. Димәк, сүз эзлекле тенденция турында бара.

Болар барысы да Кытай ягы Россия җирлеген элеккеге шикелле инде «күзәтеп», өйрәнеп кенә калмый, ә актив рәвештә үзләштерә дә дигәнне аңлата. Җирле партнёрларны таба, Россиядәге озак вакытка сузылган проектларга инвестицияләр кертә. Россия ягы исә, үз чиратында, Кытайның җитештерү мөмкинлекләрен активрак куллануга йөз тота.

КӨНДӘШЛЕКМЕ, ӘЛЛӘ КООПЕРАЦИЯМЕ?

– Димәк, Кытай компанияләре Россия компанияләренә көндәшкә әйләнә, шулаймы? Бу җирле бизнеска нинди йогынты ясый?

– Өлешчә – көндәшлек, әйе, әмма монда вазгыятьне киңрәк колачта аңларга кирәк. Конкуренция, чынлап та, көчәя төшә, бигрәк тә югары маржинальлек категорияләрендә, чөнки Кытай уенчылары җитештерү масштабы һәм сыгылмалылыгы шартларында арзанрак бәяләр тәкъдим итә алачак. Икенче яктан карaганда, бу Россия эшкуарларын күпкә сыйфатлырак һәм һөнәрмәндлерәк булырга да өнди: брендларга нигез салырга, сервисны яхшыртырга, логистика өлкәсендә һәм клиентлар белән эшне алып баруда күпкә аныграк система булдыру кирәклеген искәртә.

Моннан тыш, Россиядә Кытайның булуы бәйләнешләрнең дә яңа форматларына юл ача. Хәзер күпчелек Россия компанияләре кооперация юлларын эзли, көндәшлеккә ыргылмый: бу продукцияне бергәләп чыгару ысулы була ала, үз сәүдә маркасы (ҮСМ) булган бизнеслар белән контрактны күздә тота, логистика чылбырында рольләрне бүлү ихтыяҗын каплый. Кытай бизнесы Россия базарын кысрыкламый, ә үзгәртә, ярыш кичерергә өнди.

ПЕРСПЕКТИВАЛЫ ЮНӘЛЕШЛӘР

– Ә нинди юнәлешләр хәзерге вакытта хезмәттәшлек өчен иң перспективалы дип исәпләнә?

– Хәзер актив рәвештә берничә юнәлеш үсеш кичерә. Беренчедән, бу кулланучылык товарлары сегменты: текстильдән башлап, көнкүреш техникасы, йорт өчен кирәк-яраклар һәм балалар товарларына кадәр. Икенчедән, сәнәгать хезмәттәшлеге актуаль, аеруча – җиңел сәнәгать, машина төзелеше, компонентлар җитештерү өлкәсе. Кытай партнерлары җиһазларга, технологияләргә, персоналның белемен арттыруга инвестицияләр кертергә әзер.

Моннан тыш, цифрлаштыруның алга китүе логистика, платформалардагы карарлар, электрон коммерция юнәлешләрендәге хезмәттәшлекне көчәйтә. Мисал өчен, Россия компанияләренең күпчелеге Кытай ERP-системасына, CRM а актив тоташа, трекинг белән сыйфатны контрольдә тоту буенча уртак платформаларны ешрак куллана. Бу чын мәгънәсендә бер-беренә керешеп киткән бизнес-процессларны булдырырга ярдәм итә.

КАГЫЙДӘЛӘР БУЕНЧА ЭШЛӘҮ ҺӘМ ПРОДУКТНЫ ЯРАКЛАШТЫРУ

– Хәзер Кытай базарына чыгу өчен иң уңайлы вакыт дип әйтеп буламы?

– Мин хәзер бик зур мөмкинлекләр вакыты, дип әйтер идем. Кытай базары – киң колачлы, яхшы конкурентлык сәләтенә ия, шул ук вакытта ул искиткеч тәртипкә, системага салынган, гаять оешкан мохит тә. Әгәр Россия компанияләре кагыйдәләр буенча уйнарга, продуктларны Кытай җирлегенә яраклаштырырга, аларның телен һәм менталь үзенчәлекләрен өйрәнергә әзер икән, аларны чынлап та уңыш көтәргә мөмкин. Бигрәк тә Россия колориты ярылып яткан өлкәләрдә – косметика, туклану продуктлары, балалар товарлары, крафт җитештерүдә.

Тагын шуны да онытмаска кирәк: җирле экспертиза бик мөһим. Бу – я шәхси офис, я Кытайда яхшы партнёрның булуы. Кытай базарына чыгу – «товарны маркетплейска урнаштырдым да шуның белән оныттым» түгел. Бу – даими, эзлекле эшчәнлек. Тиешле дәрәҗәдә эшне оештыра һәм җайга сала алсагыз, аның нәтиҗәләре дә шактый уңышлы була ала.

Татарстан җитәкчелегенең Kangrun Group компаниясе генераль директоры Ван Гуймин белән очрашуында тәрҗемәче булып эшләгән вакытта.

САБАНТУЙ ҺӘМ ЧУНЬЦЗЕ МӘДӘНИЯТЛӘР ДИАЛОГЫНДА

Олег Платонов

Кытай дирижёрлары Хаожань Ли, Кристофер Чен, Тао Линь, Лю Тинтин «Ак сирень», «Concordia», «Рахлин сезоннары», «Мирас» кебек абруйлы фестивальләрдә катнаша, пианистка Сюаньи Мао – Алабугада Борис Березовский фестивалендә... Бүген Татарстанның мәдәни тормышында Кытай йолдызларының катнашуын сирәк күренеш дип әйтеп булмый. ТР белән КХР арасындагы мәдәни элемтәләр үсешкә ягына бара.

Кытай пианисткасы Сюаньи Мао Борис Березовский фестивалендә.

Бу юнәлештә халыкара танылу алган (бигрәк тә Кытайда) Казан консерваториясе аерым урын тота. ТР башкаласындагы консерваториядә белем алучы Кытай студентлары, дөньякүләм музыкаль осталык серләренә төшенеп кенә калмый, алар, үзара мәдәни диалогка өлеш кертеп, рус һәм татар музыкасын башкаручыларга да әйләнә.

Кинематография өлкәсендәге элемтәләр Кытай фильмнары һәм режиссёрларының «Алтын мөнбәр» халыкара фестивалендә даими катнашуларында чагылыш таба. Республиканың мәдәни тормышында лаеклы урын алган тагын бер күркәм күренеш – Казанда бүгенге заман рәссамы Лу Линь һәм фоторәссамы Алмонд Чуның шәхси күргәзмәләрен оештыру.

Музейлар да бу эштән читтә калмый. «Бәхетнең биш символы. Дәүләт Эрмитажы тупланмасындагы XVII – XX гасыр Кытай сәнгатендәге матур теләкләр», «Кытай коллекциясе: традицияләр һәм матурлык гармониясе» күргәзмәләре, борынгы Кытай цивилизациясе турында «Лянчжу» фотопроекты презентациясе зур уңыш белән узды.

Фото: tatar-inform.ru, elabuga-rt.ru, media.kpfu.ru, La Primavera оркестрының матбугат хезмәтеннән алынды

Ван Юйцань Казанга биш ел элек килгән. «Биш ел эчендә Казан консерваториясе минем өемә әйләнде», – ди пианист.

Кытай рәссамы Лу Линьнең Казан Кремледәге «Хәзинә» Милли сәнгать галереясындагы күргәзмәсе.

La Primavera Казан камера оркестры Кытайда гастрольләрдә.

КЫТАЙ БУЙЛАП ГАСТРОЛЬЛӘРДӘ

Хезмәттәшлек театр сәнгатен дә урап узмый. Мәсәлән, «гучжень» дип аталган музыка уен коралында уйнаучы Ван Шэнг М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында куелган «Иакинф» спектаклендә катнашты. Театр үзе Кытайның җиде шәһәрендә – Шанхай, Нанкин, Ухань, Гуанчжоу, Чжухай, Сямынь, Шэньчжэньда «Щелкунчик» һәм «Лебединое озеро» спектакльләрен күрсәтте. Кытай тамашачысы Татарстан артистлары чыгышын искиткеч җылы кабул итте.

Быелның җәендә Кытайга La Primavera Казан камера оркестры сәфәргә чыгып китте. Казан музыкантлары рус классикасы – Чайковский, Бородин, Шостакович, Шнитке әсәрләрен, шулай ук Вивальди, Монти музыкасын һәм татар халык көйләре темасына сюита башкардылар.

– Монда да тулы заллар җыю бик күңелле, бигрәк тә аларның шактый зур булуын искә алганда, – дип сөйләде La Primavera оркестрының баш дирижёры һәм җитәкчесе Рөстәм Абязов. – Без Харбинда бик матур чыгыш ясадык. Ике мәртәбә алкышлап сәхнәгә чыгардылар. Халык безнең оркестрны бик яратты. Эксперимент буларак шулай ук «Катюша»ны башкардык – Кытай балалары белән бергә.

Ә Сабан туе? Ансыз булмый. Әле 2018 елда ук татар халык бәйрәме беренче мәртәбә Көлҗә, Өремче һәм Чавучак шәһәрләрендә үткәрелә.

ЗИРӘК СҮЗЛӘР КӨЧЕ

Казан федераль университетында 2000нән артык студент белем ала, шул ук вакытта 120 гә якын кеше аспирантурада укый. КФУны һәм Кытайны хезмәттәшлек турында 36 килешү бәйли. Күптән түгел генә Пекин университеты, Гуанчжоу фән һәм технологияләр институты, Гуандун финанс-икътисад университеты, Ухань университеты, Хубэй университеты белән дә мөнәсәбәтләр урнаштырылды.

2025 елның гыйнварында КФУ Чжэнчжоу университеты (Хэнань провинциясе, КХР) белән хезмәттәшлек турында килешү имзалады, киләчәктә аны биш елга озайту мөмкинлеге дә каралган. Югары уку йортлары яшел химия, наноматериаллар химиясе, биовизуализация, сенсорика, коллоид һәм синтетик химия юнәлешләрендә эшләячәк. Планнарда – уртак тикшеренүләр проектлары, фәнни семинарлар, конференцияләр, симпозиумнар, мастер-класслар үткәрү, тәҗрибә уртаклашу һәм лекцияләр уку өчен галимнәрнең сәфәрен оештыру, алдынгы технологияләрдән уртак файдалану.

Мондый тыгыз хезмәттәшлек ике илнең традицияләрен яхшы белүне дә күздә тота. Мисал өчен, быел вузда Чуньцзе – Кытай Яңа елын халык күңел ачулары белән билгеләп үттеләр. Моннан тыш, КФУ рус телендә «Си Цзиньпинның яраткан канатлы гыйбарәләре» телепроектының өченче сезонын эшләүдә актив катнашты. Бу – Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясе һәм Кытай медиакорпорациясенең уртак эше. Ул Кытай лидерының характеры һәм идеяләре белән танышырга гына түгел, ә бу илнең уникаль тарихын, сәясәт, иҗтимагый тормыш фәлсәфә белән тыгыз үрелгән дәүләтнең корылышын яхшырак аңларга да мөмкинлек бирә.

Ике ил хезмәттәшлеге өчен бик мөһим коллаборация видеороликлар сериясенә корылган. Аларның эчтәлеге – афоризмнар, лидерның шәхси сүзләре һәм борынгы риваятьләрдән, тарихи һәм фәлсәфи трактатлардан алынган цитаталар. Аларны КХР Рәисе Си Цзиньпин төрле вакытта үзенең чыгышларында, мәкаләләрендә һәм сөйләшүләр вакытында кулланган.

– Кытай белән Россия арасындагы мәдәни аралашуның тамырлары тирән. Конфуций, Лао-цзы һәм башка Кытай фикер ияләрен Россиядә яхшы беләләр, – ди Кытай Коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының пропаганда бүлеге мөдире урынбасары, Кытай медиакорпорациясенең (CMG) генераль директоры һәм баш мөхәррире Шэнь Хайсюн әфәнде. – Россия Президенты Владимир Путин үз чыгышларында берничә тапкыр борынгы кытай гыйбарәләрен кулланды. Шуның белән беррәттән, бай рус мәдәнияте бөтен дөньяга зур йогынты ясый. Пушкин лирикасыннан алып Лев Толстойның эпик романнарына һәм Антон Чеховның җәмгыятьнең үзгәрүчәнлеген чагылдырган күзәтүләренә кадәр – Кытайда рус әдәбиятын сөючеләр бик күп.

Ике ил лидерлары җитәкчелегендә Кытай – Россия элемтәләре югары тарихи дәрәҗәгә күтәрелде. Алар яңа тип – зур мәмләкәтләр арасындагы мөнәсәбәтләр үрнәген чагылдыра.

ЦИН ДӘВЕРЕ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

Әхмәт Шакиров

Будда Амитабха. Ул барлык акыллы затларга ярдәм итәр өчен яратылган. Янәшәсендә дхармапала, аның сакчылары, ягъни буддизмны дошманнардан саклый торган дәһшәтле аллалар. Һәм, әлбәттә, сәдака өчен касәләр, һәркайсы тирән мәгънәгә ия...

Бу – гаилә алтаре. Аны күргәч, сәер хис туа. Гүя ачкыч тишегеннән карагансың да, башка бер дәвергә килеп чыгып, башка бер тормышны тамаша кыласың. Һәм Алабугада «Татарстан Республикасының Милли музее ядкарьләреннән Кытай коллекциясе» күргәзмәсен караганда син бу хистән берничек тә котыла алмыйсың.

Күргәзмәгә куелган 136 экспонатның һәркайсы вакыт капсуласы кебек. Үзенең тарихы, кайчагында җиде кат йозак астындагы серләре белән... Ә сез ничек уйлаган идегез? Бу Кытай, XIX гасыр ахыры, Цин империясе һәм аның кояшы баеган чор. Шуңа да нинди дә булса җәүһәрнең нәфислегенә соклану гына аз, кайчагында аны аңлар өчен табышмак чишәргә кирәк. Икенче яклап, ә нигә чишмәскә әле?

АЛТАРЬДАГЫ ҖИДЕ КАСӘ

Гаилә алтаре читендәге сәдака өчен куелган касәләр – шундый табышмакларның берсе. Аларның һәркайсы нәрсә өчен икәнне, нәрсәне символлаштыруын әйтеп карагыз. Кыенмы? Беренчесенә, дип әйтеп җибәрә экскурсияне үткәрүче, эчә торган су салалар, ул акыл чисталыгын символлаштыра. Икенчесендә – юыну өчен су, анысы тән чисталыгына ишарә итә. Өченчесендә – дөге ярмасы һәм чәчәкләр, болары инде карашларның чисталыгын аңлатырга тиеш...

Гаилә алтаре янындагы сәдака касәләренең җидәү булуы мәҗбүри – азрак та, күбрәк тә түгел, һәркайсының үз мәгънәсе, үз вазифасы бар. Казан музее запаслары арасында йөз елдан артык сакланган алтарьда андый касәләр бишәү генә: икесе югалган, ихтимал, бик күптәннән. Хәзер кайсыларының югалганын белеп булмыйдыр да инде. Шәм яна торганымы (аң ачылып китүне символлаштыра), бәлки, хуш исләндерелгән су сала торганыдыр (тугрылык)...

Фото: Әскәр Сабиров

ХАКИМЛЕКНЕҢ САРЫ ТӨСЕ

Нәфис кытай вазасы, өстенә глазурь йөгертелгән. Шома өслеккә төшерелгән классик сюжетлы рәсемнәр урынына кабарынкы «барельефлар». Андыйларны кытай мануфактураларында унтугызынчы гасырның икенче яртысында ясый башлыйлар.

«Барельефлы» вазалар безне экспозициягә кергәндә үк каршы ала. Мондый өстенлекнең сәбәбе нидә? Яшеме? Сәнгати кыйммәтеме? Аерым статуска ия булуымы? Ким дигәндә, соңгы сәбәп. Төгәлрәк әйткәндә – вазаның төсе, ул тыйнак кына дәрәҗәгә ишарә итә.

– Кытай мәдәниятендә сары төс аерым бер әһәмияткә ия, – дип ачыклык кертә Алабугада сирәк коллекцияләр галереясы караучысы. – Ул император хакимияте символы. Риваять буенча, Кытайның беренче хакиме Сары император булган.

Сары ваза таң калдыра, әмма ул биредә урын алган шедеврларның берсе генә. Кытайның традицион няньхуа картиналары ике гасыр элеккеге тормыш турында сөйли. Будда бодхисатвалары һәм традицион аллаларының сыннары. Чәй мәҗлесләре өчен нәзакәтле предметлар, фарфор һәм бронзадан нәфис эшләнмәләр: вазалар, савытлар, көзгеләр. Таш һәм кызыл агачны үтә зур осталык белән юнып ясалган әйберләр. Тунцао джиның гаҗәеп миниатюралары...

ИМПЕРИЯ КОЯШЫ БАЕГАНДА

– Эш барышында күргәзмә «Цинның соңгы еллары – Милли музей тупланмасында» дип аталган иде. Хикмәт шунда: бирегә китерелгән предметларның күпчелеге нәкъ менә шул чорга – олы бер мәмләкәт булган Кытайның кояшы баеган чорга карый, – дип шәрехли күргәзмәнең эчтәлегенә салынган мәгънәне ТР Милли музееның махсус саклана торган әйберләр бүлеге мөдире Влад Мухин. – Күргәзмәгә килгән кешеләр Кытай һөнәрчеләренең осталыгын бәяләп кенә калмый, даими рәвештә үзгәреп торган дөньяда милли мәдәниятне булдыру һәм аны саклау дәверен дә күздән кичерә ала.

Йомгаклар алдыннан, вәгъдә ителгәнчә, җиде кат йозак астындагы серләр турында. Экспозициядә тәмәке тарту әйберләре дә бар: кальяннар, төрепкәләр, көл савытлары – чын мәгънәсендә сәнгать әсәрләре. Аларга карап сокланасы гына килә, билгесез осталарның кул эшләре таң калдыра. Шул ук вакытта бу предметларның күбесе – «яхшылык теләүче» инглизләрнең Күк асты иленә әфьюн ташыган чорыннан. Ул вакытта дистәләрчә миллион кытай кешесе әфьюнга бәйлелеккә эләгә, Цин империясенең тулы бер буыны деградация кичерә. Гүзәллек, камиллек һәм фаҗига. Кайчагында алар янәшә атлый...

КАЗАННАН КЫТАЙГА КҮПЕР

Казаннан студент кыз Кытай мәдәниятен яхшы белүчеләр бәйгесендә катнаша.

Евгения Чеснокова

«Миңа кытай теленең салмак һәм матур яңгырашы ошый, – ди Виталина. – Европа телләренә охшамавын яратам, аның белән сиңа бөтенләй яңа дөнья ачыла».

Казан университетына укырга кергәнче, Виталина Николаева кытай телен бөтенләй белми. Ә быел яз көне КФУның дүртенче курс студенты «Кытай теле – күпер ул» Бөтендөнья бәйгесенең Россия этабында җиңеп чыга һәм августның шушы көннәрендә Кытайда әлеге конкурсның финалында катнаша.

ИҢ МӨҺИМЕ – ҮЗЕҢӘ ЫШАНЫЧ

Казанга Виталина Башкортстанның Стәрлетамак шәһәреннән килгән. Кыз тарих буенча БДИ тапшыра, тышкы сәясәт белән кызыксына. Үзегез беләсез, Кытай – бүгенге көндә сәясәттә бик тә актив уенчы. Шулай итеп, Виталина Халыкара мөнәсәбәтләр һәм Көнчыгышны өйрәнү институты студенты булып китә. Һәм бер тапкыр да үкенми.

Ике ел элек, икенче курста укыганда, фәнни җитәкчесе аңа беренче тапкыр Кытай Халык Республикасының Мәгариф министрлыгы студентлар һәм мәктәп укучылары арасында (алар аерым, һәркайсы үз категориясендә ярыша) үткәрә торган «Кытай теле – күпер ул» Бөтендөнья бәйгесенең төбәк этабында катнашырга тәкъдим итә.

– Телне шактый яхшы белә идем, әмма югары курстагылар белән ярышырга туры килгәнлектән, миңа өмет багламадылар да, – ди Ваталина. – Киресенчә: «Ә син кая ыргыласың?» – дигәннәрен дә ишетергә туры килде. Әмма җитәкчем Елена Иго-

Фото: Виталина Николаева архивыннан

ревна Нестеренко беркемне дә тыңламаска һәм белемнәремдә шикләнмәскә киңәш итте.

Нәтиҗәдә ул, көтмәгәндә, Идел буе федераль округында өченче урынны яулый. Ул елны конкурсның бөтенроссия этабында әлләни зур уңышларга ирешә алмаса да, тәҗрибә туплый һәм уңышка ирешер өчен нәрсәләр кирәк икәнен үзе өчен киртләп куя.

БӨЕК ДИВАР ҺӘМ БӘРӘҢГЕ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАР

Беренче тапкыр Кытайны Виталина узган җәйдә генә күрә, ул студентлар алышу программасы кысаларында Пекин технологик институтының җәйге лагерена бара. Анда аны һәм башка студентларны тел өйрәнү буенча өстәмә дәресләр, шулай ук күпсанлы экскурсияләр көтә. Моңа кадәр укып кына белгәннәрне үз күзләре белән күрү насыйп була. Мәсәлән, Бөек Кытай диварын.

– Бу гаҗәеп тәҗрибә булды, – дип хәтерли ул. – Мин беренче тапкыр үзем генә башка шәһәрдә яшәдем, бик күп яңа дуслар таптым… Дөрес, смена ахырына ризыклардан туя башладым, – дип көлә кыз. – Кытай ашлары бик тәмле, әмма аларның ризыклары күптөрле ингредиентлардан тора, әллә никадәр тәмләткеч салына. Ә без аңа өйрәнмәгән, шуңа да ирексездән гап-гади генә, берни кушылмаган карабодай белән бәрәңгене сагына башлыйсың.

ИМПРОВИЗАЦИЯ ӨЧЕН КҮП БЕЛЕРГӘ КИРӘК

Ике ел элек, беренче тапкыр «Кытай теле – күпер ул» бәйгесенең бөтенроссия этабында катнашканда, Виталина Николаева 17 нче урынны ала. Икенче ел катнашканда инде алтынчы урынга күтәрелә, аны хәтта Кытайга күзәтүче итеп тә чакыралар. Быел КФУның IV курс студенты аңлы һәм максатчан рәвештә җиңәргә дип әзерләнә.

Ярыштагы биремнәрнең беренчесе – кытай телендә алдан әзерләнгән чыгышын – ул конкурска кадәр узган юлына багышлый. Зур булмаган шәһәрдә туып-үскән, беркайчан да чит ил кешеләрен күрмәгән кыз, университетка килгәч, Кытай мәдәниятенә гашыйк булуы, аның ярдәмендә үзе өчен яңа офыклар ачылуы турында сөйли.

Конкурстагы биремнәр арасында иҗади чыгыш та була (Виталина кытай телендә җыр башкара), импровизация һәм Кытай турында белемнәрне тикшерү. Соңгы ике бирем, аңлавыбызча, шактый охшаш – кытай телендә импровизация ясар өчен синең Күк асты иле турында теләсә кайсы тема би-

Узган елда Кытайга конкурс финалына Виталина күзәтүче булып барган.

Бөек Кытай диварында.



рергә мөмкиннәр. Бу инде шактый тирән белемнәр таләп итә. Катнашучыларга әзерләнер өчен узган елгы конкурсның сораулары бирелә, чыганаклар тәкъдим ителә.

– Теләсә нәрсә турында сорарга мөмкиннәр – кытай операсы, эндемик кошлар, Кытайдан чыккан Нобель премиясе лауреатларының исемнәре... – дип сөйли Виталина. – Яки, мәсәлән, шигырьдән өзек буенча авторын белергә кирәк...

Виталинага импровизация этабында мәгълумати технологияләрнең кытай теленә йогынтысы турындагы сорау эләгә. Күргәебезчә, биремнәр шактый катлаулы, һәм КФУ студентының Россия этабында катнашучыларны уза алуы – үтә җитди әзерлек нәтиҗәсе.

Әмма Виталинага әзерлек процессы ошый. Ул безнең көнчыгыштагы күршеләребез белән бәйле бөтен нәрсә белән дә мавыга: кытай операсын ярата башлаган, халык сәнгате белән кызыксына (бу юлы Кытайдан традицион ике яклы чигү эшләнмәләре алып кайтырга хыяллана). Тагын бу сәфәреннән ул бәйгенең Россия этабында танышкан дуслары белән очрашуны көтә.

«Кытай теле – күпер ул» бәйгесенең йомгаклау этабына 150 илдән катнашучы килгән. Без, әлбәттә, Россия студентларына уңышлар телибез. Һәм беренче чиратта – Казан университетыннан Виталина Николаевага.

Виталина Николаева – «Кытай теле – күпер ул» бәйгесенең Россия этабы җиңүчесе.



Фәнни җитәкчесе Елена Игоревна Нестеренко белән.

Конкурсның түбәкара этабында 1 нче урын алганда бүләкләү тантанасы. КХРның Казандагы Генераль консулы Сян Бо әфәнде белән.

ХАОСТАН – ЯҢА БАЗАРЛАР ЯУЛАУГА

ERP ЧЫГЫМНАРНЫ КИМЕТЕРГӘ ҺӘМ БӨТЕН ДӨНЬЯ БУЙЛАП ЯҢА КЛИЕНТЛАР ТАБАРГА НИЧЕК БУЛЫША

Олеся Бондаревская

Бүген Татарстанда торган саен күбрәк сәнәгать предприятиеләре, җитештерү күләмен арттырып кына калмыйча, өлгергәнлек дәрәҗәсе буенча да ышанычлы үсеш күрсәтә. Яңа тармаклар үзләштерелә, экспорт юнәлешләре һәм халыкара партнёрлар белән хезмәттәшлек үстерелә. Әлеге кыю ниятләргә ирешү өчен, бизнес цифрлы карарларга ешрак мөрәҗәгать итә, чөнки бүгенге көндә бу масштаблаштыруның шарты буларак кабул ителә.

Бу җәһәттән ERP*-системалар – мәгълүмат белән идарә итү, процессларны башыннан ахырына кадәр планлаштыру, компания белән идарә итүне югарырак дәрәҗәгә күтәрү мөмкинлеген бирә торган комплекслы платформалар кертү буенча төп инструментларның берсенә әйләнә.

– Бүген цифрлаштыру – «киләчәккә инвестиция» генә түгел, ә бәлки позицияләрне саклап калу һәм үсешнең яңа баскычына күтәрелү чарасы да. Компанияләр безгә ачыклыкны тәэмин итү, процессларда тәртип урнаштыру, халыкара таләпләргә җавап бирә торган стандартлар кертү кебек конкрет бурычлар белән килә, – ди Казанның IBR («ИБР», Мәгълүмати бизнес-карарлар) бизнесны автоматлаштыру һәм ERP-чишелешләр кертү буенча махсуслашкан ИТ-компаниясе генераль директоры Сергей Лунин.

Мондый чишелешләр бигрәк тә экспортка юнәлтелгән бизнес өчен мөһим.

IBR компаниясенә нигез салучылар – Юлия һәм Сергей Луниннар.

*ERP (Enterprise Resource Planning) – предприятие ресурсларын планлаштыруның цифрлы системалары; компаниянең төп бизнес-процессları белән идарә итү өчен интеграцияләнгән программа тәэмин ителеше.

IBR компаниясе «1С:Ел проекты» конкурсының «Тармакларда иң яхшы проектлар» номинациясендә җиңүчеләр арасында.

ҖИТЕШТЕРҮГӘ ЧИКЛӘР ЮК

2024 ел башында IBR белгечләренә медицина җиһазлары, кораллары һәм перчатка, шприц, бинт кебек бер генә тапкыр кулланышлы материаллар җитештерә торган компания мөрәҗәгать итә. 2026 елда предприятиедә урнаштырылган 1С:УПП идарә системасы гамәлдән чыга икән. Әмма үсешне туктатмау, бигрәк тә халыкара базарларга чыгуны дәвам итү өчен, компаниягә югарырак дәрәҗәдәге система таләп ителә. 1С:ERPны сайларга булалар: чөнки идарә хисабын гына түгел, катлаулы операцияләр җитештерүне дә автоматлаштырырга ярдәм итәрлек платформа кирәк була. Циклның нәкъ менә «күп баскычлылыгы» – бер үк эшләнмәне эшкәртүнең биштән алып җидегә кадәр этабын үтүе стандарт булмаган һәм төгәл чишелешләр таләп итә.

– Мондый проектларга «тартма» версиясе туры килми. Алдан аудит үткәреп һәм заказчы белән элемтәдә торып, без 1С:ERPны компания ихтыяҗларына яраклаштырдык. Әзер продукциянең үзкыйммәтен санау өчен товарны исәпкә алуны FIFO методына күчерү, идарә отчетының аңлаешлылыгын арттыру, җитештерү процессларын автоматлаштыру кебек төп таләпләрне үтәү барышында без, заказларның төрлелеген истә тотып, автомат генерацияләнү функциясен гамәлгә керттек, материаллар хәрәкәтен контрольдә тотуның цифрлы инструментларын урнаштырдык, идарә блогын унификацияләнгән цифрлы тәрәзәгә күчердек. Хәтта штрих код ясау кебек техник элемент та яңача исәпкә алу һәм контрольнең мөһим буынына әйләнде, – ди IBR компаниясенең үсеш буенча директоры Юлия Лунина.

Җитештерү системасы 2025 елның гыйнварыннан эшли дә башлаган. Беренче атналар ук шуны күрсәткән: операцияләрне үтәү вакыты сизелерлек кимегән, эш өчен түләү тоткарлыкларсыз үткән, үзкыйммәт буенча саннар һәркемгә аңлаешлыга әйләнгән. Хәзер компания, сыйфатка зыян китермичә, зур күләмдә продукция җитештерә ала, төрле илләрдәге заказчылар таләбе буенча процессларны тиз арада үзгәртеп көйләргә сәләтле.

БАШТА – ТӘРТИП УРНАШТЫРЫРГА, АННАРЫ – ДАН КАЗАНЫРГА

Чит ил клиентлары белән эшләү әзерлек таләп итә, беренче чиратта – бизнес-процессларны бердәм һәм чит ил компанияләренә аңлаешлы таләпләргә буйсындыруны. Мондый үтенеч белән IBR компаниясенә Татарстандагы мөгезле эре терлек өчен комбиазык җитештерүче бер эшкуар мөрәҗәгать иткән. Соңгы елларда аның бизнесы сизелерлек үскән, һәм, алга таба халыкара сәүдәдә зуррак уңышларга ирешү өчен, тагын да аңлаешлырак, тагын да төгәлрәк, тагын да стандартлаштырылганрак яңа эш ысуллары кирәклеге ачыкланган.



Аудит вакытында шул аңлашылган: эш ресурслар җитмәүдә түгел, бәлки, бердәм таләпләр булмауда икән. Кабул итү озаккарак сузыла, складта артык йөк туплана, операцияләрнең бер өлеше кулдан башкарыла.

– Тышкы базарларда ышанычлы эшләү өчен, компанияләргә эшкәртү, саклау һәм исәпләүнең билгеле бер кагыйдә һәм стандартларына тәңгәл килергә кирәк. Проектта иң мөһиме нәкъ менә шул инде: процессларны аңлаешлы, идарә ителешле һәм киләчәктә халыкара партнёрларның таләпләренә туры килерлек итеп көйләү, – дип сөйли Юлия Лунина.

IBR компаниясе комплекслы чишелеш тәкъдим иткән: идарә итү платформасы сыйфатында 1С:ERP һәм складта мобиль эш инструменты буларак DataMobile**.

– Җитештерү, склад, документлар әйләнеше – барысы да бердәм цифрлы контурга берләштерелде. Нәтиҗәне без шунда ук тойдык: бер атнага сузыла торган кабул итү берничә сәгатькә генә калды. Җитмәүчелек кимеде, заказны җыю һәм төяп җибәрү тизәйтелде. Шул ук вакытта ERP-система тагын да югарырак уңышлар өчен юл ачты: автоматлаштыру хезмәткәрләргә үзләренең стратегик бурычлар кую һәм хәл итү ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген бирде, ә склад һәм җитештерү белән комплекслы идарә итү компаниянең чит ил заказчылары арасында дәрәҗәсен күтәрде, – дип, шатлыгы белән уртаклашты IBR компаниясенең үсеш буенча директоры.

Татарстан компанияләре, зур базар кагыйдәләрен әкренләп үзләштереп, алга бара. Ә IBR локаль чишелешләрдән системалы идарәгә (автоматлаштыру, стандартлар кертү, төп процессларда тәртип урнаштыру) кадәр юлны үтәргә булыша. Шул рәвешле, теләсә нинди масштабта булганда да, аңа таяна алырлык цифрлы инфраструктура булдырыла.

Фото: IBR компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

** DataMobile – мобиль мәгълүматны тапшыру.

RESEDAODOR: КАЗАНДА ТУГАН МАТУРЛЫК ФӘНЕ

ResedaOdor® компаниясе – инде дистә елдан артык профессиональ косметика базарында лидерлар рәтендә. Аны оештыручы – фармакологиядә 25 еллык эш тәҗрибәсе булган Резеда Нурисламова. Ул үз алдына тән тиресен кайгыртуны гына түгел, булган проблемаларның эчке сәбәпләрен ачыклап, аны хәл итә торган косметика эшләү максатын куя. Бүген Россиядән читтә дә танылу алган бренд әнә шулай пәйда була.

ResedaOdor® – күпьеллык тикшеренүләр һәм клиник сынаулар нәтиҗәсе ул. Брендның һәрбер продуктының составында актив матдәләр дәвалый торган микъдарда кулланылган, агрессив, исле матдәләр һәм төрле буяулар юк. Компаниянең пептидлар һәм миорелаксантлар концентратлары кебек беренче продуктлары тиз арада популярлык казана. Мәсәлән, SCC5 инновацияле формуласы күп кенә клиентларга дүрт ай эчендә чәч коелуны туктатырга ярдәм иткән.

ХАЛЫКАРА БРЕНД

Бүген ResedaOdor® – Казанда үз лабораториясе һәм җитештерү үзәге булган халыкара бренд. Компания үзенең продукциясен актив рәвештә Якын Көнчыгыш, БДБ һәм башка илләргә экспортка чыгара, ә 2024 елда «Ел экспортёры» дигән бүләккә лаек була. Шунысы да мөһим: ResedaOdor®ның бөтен продукциясе дә «Хәләл» сертификатына ия, бу исә аның югары сыйфат һәм этика стандартларына туры килүен раслый.

«ХӘЛӘЛ» СЕРТИФИКАТЫ

ResedaOdor® продукциясе Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә аеруча популяр. Бу косметиканың югары сыйфаты белән генә түгел, эссе һавалы климатта тән тиресенең үзенчәлекле проблемаларын хәл итә алуы белән дә бәйле. Бренд актив рәвештә Дубайдагы клиникалар һәм матурлык салоннары белән партнёрлык мөнәсәбәтләре кора, бу исә аның халыкара статусын раслый. «Хәләл» сертификаты Якын Көнчыгыш илләрендә кулланучыларның ышанычын яуларга да ярдәм итә.

130 ТӨРЛЕ ПРОДУКТ

ResedaOdor® 130 төрле продукт эшләп чыгара, алар – бит тиресен һәм чәчләрне кайгыртуга юнәлтелгән. Компания Россиянең «Профессор Юцковский хастаханәсе», «СМ Клиник» һәм «Медси» кебек әйдәп баручы клиникалары белән хезмәттәшлек итә. Һәрбер продукт пациентларның ихтыяҗларын һәм косметолог-табиблар биргән киңәшләрне истә тотып эшләнгән. 2025 елда ResedaOdor® берничә яңа линейка чыгарырга планлаштыра.

КАЗАНЫШЛАР

Компаниянең соңгы казанышларыннан берсе тән тиресенең хроник авыруы булган розацея белән комплекслы рәвештә көрәшү өчен сүл эшләп чыгару була, моңа кадәр әлеге авыруны дәвалауның нәтиҗәле юлы юк иде әле. Нибары өч ай элек чыгарылган әлеге продукт клиник тикшеренүләр нәтиҗәсендә профессионаллар арасында танылып өлгергән инде*.

ResedaOdor® Казанда үзенең Матурлык һәм диагностика үзәген ачты, анда теләгән һәркемнең бушлай консультация алу мөмкинлеге бар. Үзәк продуктларны сату урыны гына түгел, ул кулланучылар белән аралашу мәйданы да, бу исә компаниягә аларның ихтыяҗларын яхшырак аңларга ярдәм итә.

Якын киләчәктәге планнар – маркетплейсларда сатып алу мөмкинлеге булган ваклап сату линейкасын эшләү.

Гомумән, әгәр косметика индустриясенең киләчәге фән, этика һәм кеше турында кайгыртуның синтезы икән, ResedaOdor® бүген үк инде аңа тон бирә.

**15 апробантта (27–52) уздырылган клиник тикшеренүләрнең нәтиҗәләре: ай ахырына эритма (кызарулар) дәрәҗәсе күрсәткече – 43,7%; эритема (мексаметрия) дәрәҗәсе төшү күрсәткече – 20,9%; апробантларның 100%ы да уңай нәтиҗә барлыгын билгеләгән; дерматологик тест үткән; яхшы үзләштерелә (тикшеренүләр барышында кирәкмәгән бер очрак та теркәлмәгән), кызарган урыннарны нәтиҗәле бетерә, тән тиресен тынычландыра. Парфюмерия-косметика продукциясенең кулланучылар бәяләмәсе буенча нәтиҗәсе «КосмоПродТест» Туклану һәм косметика продуктларының сыйфатын һәм куркынычсызлыгы буенча эксперт бәясе буенча фәнни-гамәли үзәк» ҖЧҖ тарафыннан 2025 елның 20 февралендә NCP 028853 номеры белән бирелгән. Беркетмә «КосмоПродТест» ФГҮ» ҖЧҖнең баш тикшеренүчесе, дерматовенеролог, косметолог, Россия ФМБАнең ФФКУ ФДБУнең дерматовенерология һәм косметология кафедрасы доценты Я. А. Петинати; «КосмоПродТест» ФГҮ» ҖЧҖнең клиник тикшеренүләр бүлегенең әйдәп баручы белгече, профессор, медицина фәннәре докторы, табиб-дерматовенеролог Н. И. Измерова; «КосмоПродТест» ФГҮ» ҖЧҖнең клиник тикшеренүләр бүлеге белгече, табиб-косметолог О. В. Сидорова тарафыннан расланган.*

Фото: Резеда Нурисламова архивыннан алынды. РЕКЛАМА

акыллы гамәлләр / игелекле эшләр / мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Казан үзенең меңьеллыгына **нәрсәләргә** ирешә

Камил Исхаков **ничек** «акчаларны җиргә күмгән»

Константин Васильев йортын ишүдән **кем** саклап калган

Рәшит Сабиров **ничек** яшь булып калган

Сугыш чоры балалары **нинди** авырлыклар күргән

2005 ЕЛ

КАЗАН. ҮЗЕНЕҢ МЕҢЬЕЛЛЫГЫНА

Казан метросының 5 станциясе

Казансу аша Миллениум күпере

Казан ипподромы

Кол Шәриф мәчете

Кол Гали һәйкәле

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты

Меңьеллык паркы

Татнефть-Арена

«Пирамида» мәдәни-күңел ачу үзәге*

Фото: ru.wikipedia.org, topclimat.ru, tatar-inform.ru, tatarica.org

*2002 елда ачылды

**Программа гамалга ашыру 2024 елның декабрендә төгәлләнде

МИЛЛЕНИУМ

ШӘҺӘР НӘРСӘ АЛДЫ

«МЕГА» СҮ

Җәяүлеләр өчен Петербург урамы

Казан елга портының яңа причаллары

Казан ратушасы
(реконструкция)

Казан аэропорты
(реконструкция)

Тимер юл вокзалы
(реконструкция)

Горький шоссесы
(реконструкция,
юл дүрт полосалыга әйләнде)

Тузган торакны бетерү программасы** буенча Казанның иске йортларында яшәүчеләр 33734 фатир алды

КАЗАН. МИЛЛЕНИУМНАН

БЕРЕНЧЕ МЕҢЬЕЛЛЫГЫННАН СОҢГЫ 20 ЕЛ

6 метро станциясе

«Казан» гаилә үзәге

Игенчеләр сарае

«Ак Барс Арена»

Универсиада Авылы

Казансу яр буе
Милли китапханәдән
Киров дамбасына кадәр



Камал театрының
яңа бинасы



Зур Казан Боҗрасы



Кабан яр буе

Фото: ru.wikipedia.org, topclimat.ru, tatar-inform.ru, tatarica.org

СОҢ БЕР МИЗГЕЛ

2025 ЕЛ

ЭЧЕНДӘ ШӘҺӘР НӘРСӘЛӘР АЛДЫ

Горки-Әмәт урманы

Бәшир Рәмиев исемендәге IT-парк

«Казан Экспо»

Казан аэропортының 1А терминалы

Су спорт төрләре үзәге

«Замбези» зоопаркы

«Әкият» курчак театры бинасы

Горький шоссесы
(реконструкциядән соң, юл алты полосалыга әйләнде; өч катлы юл чишелеше; эстакадалар; тоннель; борылыш төеннәре; җәяүлеләр кичүләре)

Фотолар: Александр Ефремовтан һәм катнашучыларның шәхси архивыннан алынды

«Татарстан» журналының махсус проекты

ЗАРЛАНМЫЙЧА ЭШЛӘГӘН БУЫН

Авыр вакытларга, кырыс заманнарга, кайчак түзеп булмаслык тормыш шартларына да карамастан, зарланмый-сукранмый, үз юлларында очраган бөтен кыенлыкны җиңеп алга атлаучы, дөньяны ямьлерәк, уңайлырак итәргә омтылучы кешеләр бар. Алар юллар сала, күперләр төзи. Балаларны, аларның укытучыларын өйрәтә. Арабызда алтын куллы иске әйберләрне яңартучы, сирәк һөнәргә ия фидакарь затлар да бар.
«Татарстан» үз укучыларын шундый якташларыбыз, аларның могҗизага тиң эшчәнлекләре белән таныштыруны дәвам итә. Бу санда без эш вакытының күп өлешен ҖИР АСТЫНДА үткәрүчеләр турында язабыз. Сезгә, Казан шәһәре халкының һәм килүче кунакларның тормышын уңайлы итеп, моннан 30 ел элек метро төзи башлаучылар һәм бүген дә әлеге эшне дәвам итүчеләрнең тарихларын тәкъдим итәбез. Бүген казанлылар үз тормышларын метродан башка күз алдына китерә алмый.
Метро төзелә башлаганчы Казанда тормыш нинди була һәм хәзер ничек? Метро ничек пәйда булган? Бу эшне кемнәр башлаган?
Әйдәгез шул заманга әйләнеп кайтыйк әле. Бүген сез түбәндәгеләрне белерсез:

24 НЧЕ ТАРИХ
Камил Исхаков ничек итеп «акчаларны җиргә күмеп куйган»

25 НЧЕ ТАРИХ
Татьяна Ларионова ничек итеп метро төзүчеләргә ярдәм кулы сузган

Башка тарихларны «Татарстан» журналында, 2022 елның 10–12 нче, 2023 елның 1–2, 6 нчы, 2024 елның 1,4 нче, 2025 елның 6 нчы саннарында укырга була.

КАЗАН МЕТРОСЫНЫҢ ЧИШМӘ БАШЫ

– Казанда метро булганга, бүген барыбыз да шат һәм бәхетле. Көн саен әлеге транспорт төре 100 мең пассажирны йөртә. Хәзер ул гадәти хәл кебек, шулай була күрсен. Тик шәһәрдә бер урыннан икенчесенә метрода барганда, бүген ул араны җир өстеннән ничек үтәр идем дип, уйлап та карамыйсың. Шулай бит? – дип сорый Татарстан Рәисе ярдәмчесе, 1989–2005 елларда Казан мэры булып эшләгән Камил Исхаков.

Аның белән килешеп, баш кагабыз. Ә Казаннның метро төзелеше башланган чактагы мэры дәвам итә:

– Әмма бүген гадәттә барысы да күңелле яңалыклар турында гына сөйли: ничек яхшы, рәхәт. Белмим, бәлки, кемдер бу эшләрне башкару өчен күпме көч түгелгәнен дә искә аладыр. Тик минем әлегә андый кешене очратканым юк. Ә бит бу вакыйгалар башланганга, 27 ел да түгел, 30 ел да түгел, ә 50 еллап вакыт үткән!

ИРЕК МОСТАФИН ҺӘМ МЕТРО ТӨЗҮ ХОКУКЫ

Казан метросының башланган мизгеле – Казанда миллионынчы кеше туган көн. Сабый 1979 елның 30 октябрендә Мостафиннарның интернациональ эшче гаиләсендә туа, һәм аңа Ирек дип исем кушалар.

Әлбәттә, миллионынчы кеше туганчы ук, казанлылар метро турында хыяллана. Хыяллануын хыялланалар, әмма шәһәрнең метро төзелеше өчен хокукы булмый. Һәм менә 1979 елда миллионынчы кеше тугач, ил җитәкчелеге Казанда метрополитен төзү турында карар кабул итә. Бу чишмә башы гына әле. Бер үк вакытта Уфага да метро төзергә рөхсәт бирелә.

Мондый рөхсәтне алу безнең өчен зур шатлык булды. Һәрбер Казан кешесе өчен дип әйтә алмыйм, әмма җитәкчелектә ихластан куандык.

- Төрлесе булды. Шуңа да төзелешкә резин итекләрдән генә чыга идек.

Фотоларны «Казметрострой» АҖ тәкъдим итте

ҖИТӘКЧЕЛЕКНЕҢ ШАТЛЫГЫ

Мин 1973 елдан шәһәр җитәкчелегендә кайнадым. Казанның Совет райкомында комсомол секретаре идем. Аңа кадәр университетта мине республиканың Югары Советына депутат итеп сайладылар. Мин Югары Советтагы беренче студент булдым, бу – уникаль күренеш. Биредә минем анкетаның роле зур булгандыр. Мин – Савин бистәсендә гомер иткән эшче гаиләсеннән. 14 яшьтән эшли башладым, эшче һөнәрем бар. Ә ул вакытта 14 яшьтә эшкә алсыннар өчен, балигъ булмаган балалар белән эшләү комиссиясен узарга кирәк, карарлар индивидуаль кабул ителә: Камилгә заводта эшләргә рөхсәт итәргәмеюкмы. Рөхсәт иттеләр, һәм шунда мин, ул вакыттагыча итеп әйткәндә, пролетар чыныгу уздым.

Аннан соң – элемтә техникумы, Казан университетының физика факультеты студенты булдым. Һәм менә шул яшьли башланган эшче-студент тормышым мине депутатлыкка, Югары Советка алып килде. Ул бер дә көтелмәгәнчә килеп чыкты. Мине университетның актлар залына җыелышка чакырып алдылар. Әле минем барасым да килмәде – анда нишлим, янәсе. Студентларның, үзегез беләсез, җыелыштан мөһимрәк эшләре дә күп. Һәм менә – бер могҗиза! – мине сайлап куйдылар!

КАЗАН МЕТРОСЫНЫҢ БАШЛАНГАН МИЗГЕЛЕ – КАЗАНДА МИЛЛИОНЫНЧЫ КЕШЕ ТУГАН КӨН. САБЫЙ 1979 ЕЛНЫҢ 30 ОКТЯБРЕНДӘ МОСТАФИННАРНЫҢ ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ЭШЧЕ ГАИЛӘСЕНДӘ ТУА, ҺӘМ АҢА ИРЕК ДИП ИСЕМ КУШАЛАР. ҺӘМ ИЛ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕ КАЗАНДА МЕТРОПОЛИТЕН ТӨЗҮ ТУРЫНДА КАРАР КАБУЛ ИТӘ. БУ ЧИШМӘ БАШЫ ГЫНА ӘЛЕ.

БЕРЕНЧЕ ТАПКЫР ҺӘМ ЯҢАДАН

Шулай итеп, шул даирәдә кайный башладым һәм республика җитәкчелегенең метро төзелешенә рөхсәт алганга ничек куанганын үзем күрдем. Болар барысы да минем хәтергә уелып калды. Мәскәүгә баргач, метрода йөргәннәр дә истә калган. Без анда, метрога төшеп, барасы җиргә генә бармыйбыз, юри тегендә-монда утырып йөрибез! Сокланабыз, көнләшәбез һәм шундый ук транспорт турында хыялланабыз. Әлбәттә инде, киләчәктә Казан метросының да көненә йөз мең пассажир йөртер чакларын күрербез дип, башыбызга да китермибез.

Шатлык әкренләп конкрет гамәлләргә әйләнә башлады. Ул чакта берәү дә эшне каян һәм ничек башларга икәнен белми. Шулай да боз кузгалды - Казан метрополитенының проектын төзү турында карар кабул ителде.

Хакимият коридорлары буйлап йөрүләр, СССР хөкүмәте бюджетыннан бераз таммасмы, дип өметләнүләр. Кыскасы, хакимият бусагаларын таптау Казан метросының проектын эшли башлауга китерде. Әмма... Түбән Новгородта! (Ул вакытта Горький дип атала иде әле.) Советлар Союзында бары тик кайбер үзәкләрнең генә мондый проектларны эшләү мөмкинлеге бар иде.

КАЗАН МЕТРОСЫ ПРОЕКТЫН ГОРЬКИЙ ТӨЗИ

– Һәм Горький Казан метросының проектын төзи алдымы?

– Юк, булдыра алмады. Әмма бу соңыннан ачыкланды. Вакыт узу белән, без шәһәребез метросына дигән проектны башка шәһәрдә эшләүнең дөрес түгеллегенә инандык.

Мине Казан башкарма комитеты рәисе итеп сайлагач, җиң сызганып шөгыльләнә башлаган эшләремнең берсе метро булды. Казанга метро кирәклеген аңлый идем, чөнки шәһәрнең яртысы Казансуның бер ягында, икенчесе икенче ягында яши. Мәдәният – бер җирдә, сәнәгать – икенче урында, торак йортлар – өченче якта. Күп йөрергә кирәк. Һәм мин, чынлап торып, бу темага ябыштым. Шулай итеп, проектны Горькийда эшлиләр, проект өчен техник бирем миңа кадәр бирелгән. Ул вакытта мин Казанда метро төзелеше өчен бик күп көч куйган



2000 елның марты. РФ Президенты вазифаларын башкаручы Владимир Путин Казанның меңьеллыгын бәйрәм итү буенча дәүләт комиссиясе утырышында катнашты. Утырыш башланыр алдыннан дәүләт башлыгы метро төзелеше мәйданчыгын карап чыкты.

кешегә – әлегә кадәр шәһәрнең башкарма комитеты рәисе булып эшләгән һәм, башка бик күп эшләреннән тыш, вакыт-вакыт метро белән дә шөгыльләнгән Александр Иванович Бондаренкога мөрәҗәгать иттем. Ул вакытта бу теманы аннан да яхшырак белүче кеше юк иде. Нәкъ менә Александр Иванович метро проекты буенча техник биремне Горькийга кадәр җиткергән була.

Мин аны эшкә алдым, вазифасын булдырдык, кабинет бирдек, һәм ул бары тик шушы эш белән генә шөгыльләнергә билгеләнде. Эшнең гамәлдә чагылышының башы иде бу. Әмма аның хакында сезгә беркем дә сөйләмәячәк. Беркем дә.

МӘСКӘҮГӘ БАРГАЧ, МЕТРОДА ЙӨРГӘННӘР ДӘ ИСТӘ КАЛГАН. БЕЗ АНДА, МЕТРОГА ТӨШЕП, БАРАСЫ ҖИРГӘ ГЕНӘ БАРМЫЙБЫЗ, ЮРИ ТЕГЕНДӘ-МОНДА УТЫРЫП ЙӨРИБЕЗ! СОКЛАНАБЫЗ, КӨНЛӘШӘБЕЗ ҺӘМ ШУНДЫЙ УК ТРАНСПОРТ ТУРЫНДА ХЫЯЛЛАНАБЫЗ. ӘЛБӘТТӘ ИНДЕ, **КИЛӘЧӘКТӘ КАЗАН МЕТРОСЫНЫҢ ДА КӨНЕНӘ ЙӨЗ МЕҢ ПАССАЖИР ЙӨРТЕР ЧАКЛАРЫН КҮРЕРБЕЗ ДИП, БАШЫБЫЗГА ДА КИТЕРМИБЕЗ**.

Хәзер исә метро төзелешен 1997 ел белән бәйлиләр, ә без инде 89 елда ук эшли башладык. Бу сигез ел элек дигән сүз. Һәм шушы сигез ел эчендә бик җитди юл уздык. Югары кабинетларда янә активлаштык, акча таптык, Горькийның проект институтларына техник биремнәрне яңарттык, аның өчен түләдек...

БАШЛАНГЫЧ СТАДИЯ

Башта өчәү шөгыльләндек: Бондаренко, мин һәм капиталь төзелеш буенча урынбасарым Евгений Петрович Лапшин. Фикердәшләрнең менә шундый тар даирәсе. Һәм, ниһаять, Горькийдан якынча проект килә: анда Казан картасына метрополитенның станцияләре һәм трассалары урнаштырылган.

Белгечләр, Горькийда яшәп, андагыча фикер йөрткән. Алар үзләрендә метро төзегәндә дә бик зур хата ясаган. Анда шәһәрнең Обь елгасы аккан түбән өлешендә Горький автомобиль заводы урнашкан. Аның буеннан-буена озын трамвай юлы уза. Һәм алар шушы трамвай юлы астына метро төзеп куйганнар. Нәрсәгә аларга трамвай да, метро да? Кешеләр җир өстендә транспорт булганда, ни өчен әле җир астына төшәргә тиеш? Хәзер алар бу хатаны төзәтте инде. Әмма нәкъ менә без аларның проектына төзәтмәләр кертә башлагач.

Алар гаепле түгел, дип уйлыйм. Алар өчен безнең шәһәр ят бит. Гомумән, алар троллейбус, автобус маршрутлары белән параллель рәвештә бармаска тырышмаганнар да. Шәһәрдәге транспорт төеннәре белән бәйләнеш тә юк. Һәм без ул проектны кабул итмәдек. Нәтиҗәдә, без дөрес фикергә килдек. Белгечләр табып, аларны үзебезгә чакырып китердек, «заказчы» функциясен булдырдык. Бу да җиңел генә эшләнмәде. Чөнки заказчының үз даирәсе булырга тиеш: сууткәргечләр буенча да, канализация буенча да, электр белән тәэмин итү буенча да үз инженерлары һ.б.

ҮЗЕБЕЗНЕҢ ЗАКАЗЧЫ, ҮЗЕБЕЗНЕҢ ПРОЕКТ

Башта без заказчы итеп Казанның капиталь төзелеше идарәсен сайладык, идарәдә метро төзелеше буенча бүлекчә булдырдык. Аннан соң яңа заказчы эшләдек, үзебезнекен.

Хәзер инде проект оешмасы кирәк. Горький метро проекты белән бәхәсләшүнең файдасыз икәнлеген аңладык һәм Марат Абдулла улы Кафиатуллин җитәкчелегендәге

«Казгражданпроект»та бүлекчә булдырдык. Зур тырышлык белән, бик күп бәхәсләрдән соң. Белгечләр җәлеп иттек, һәм бүлекчә метрополитен проектын эшли башлады. Кафиатуллин – бөек проектчы һәм төзүче, ул бу эшне үз җаваплылыгына алды. Аннан соң без аның белән четерекле хәлләргә күп тарыдык, чөнки таныш түгел эшкә тотынсаң, һәрвакытта да хаталар шактый була. Әмма барыбер ерып чыктык: үзебезнең проект эшләнде, без Горькийда эшләнгән метрополитен линиясен бөтен килеш өскәрәк күтәрдек: Кремльдә станция булдырдык, Куйбышев мәйданына да куйдык (хәзерге Тукай мәйданы – **ред. иск.**), соңыннан космик кораб кебек итеп Әмәт станциясен «элдек». Нигә «элдек»? Чөнки зур ерганакны үтәсе бар иде. Ул район әле бөтенләй төзелмәгән, һәм анда метро килгәч, шунда ук торак йортлар төзелә башлады, инфраструктура барлыкка килде – актив тормыш башланды. Берочтан тулы бер районга җан өрдек.

Шул рәвешле, казанлылар өчен уңайлы метрополитен линиясен эшләдек. Казан метрополитенының Куйбышев мәйданындагы беренче станциясенә нинди исем бирергә? Әлбәттә, Тукай станциясе! Һәм аны Тукай әсәрләрендәге геройларның сурәтләре белән бизәдек. Башка шәһәрдә эшләнгән проектта болар була алыр идеме? Юк. Бары тик үзебез генә мондыйны эшли алабыз. Чөнки бу шәһәр дә, аның геройлары да – үзебезнеке.

БЕЗНЕҢ БӘХЕТКӘ ТАБЫЛГАН ПОДРЯДЧЫ

...Болар, әлбәттә, хәзер тарихта калды. Әмма проект, шул проектны тулыландыра торган идеяләр, заказчы һәм проектлаучы булганда, продрядчы да кирәк. Марат Муллахмәт улы Рәхимов белән таныштым, мин моны зур бәхет дип саныйм. БАМны төзегән кеше ул. Ул да Казанда метро төзү идеясе белән яна башлады. Аңа гаҗәеп сыйфат хас: эшне башлаганда, аның нәтиҗәсе булачагына ышана һәм шул нәтиҗәгә ирешү өчен барысын да ерып чыга.

Без аның белән күпне күрдек, күпне белдек һәм күп нәрсәләр төзедек. Казанда туфракның артык дымлы булуы ачыкланды. Без метро булган төрле шәһәрләргә бардык, аларның ничек төзелүен өйрәндек. Канадада тоннельләр казый торган комплекс эшләүчене таптык. Алар нәкъ менә безнеке кебек дымлы туфраклы җирләрдә артык тирәннән узмый торган метро төзү өчен комплекслар эшләп чыгара булып чыкты.

Рәхимов һәм аның берничә хезмәттәш дустыннан торган команда төзелде. Бөтен эш алар тирәсендә кайный башлады. Барысы да беренче тапкыр бит. Менә яссы грунт бар, менә – гадәти җир. Һәм шушы урында

ӘММА ИҢ ЗУР КЫЕНЛЫКНЫ, НИЧЕК КЕНӘ СӘЕР ТОЕЛМАСЫН, БЕЗ ХАЛЫКНЫҢ КАНӘГАТЬСЕЗЛЕГЕННӘН КҮРДЕК. «УЛ АКЧАНЫ БЕЗГӘ БИРСӘГЕЗ, ЯХШЫРАК БУЛЫР ИДЕ...», «АКЧАНЫ ҖИРГӘ КҮМӘЛӘР...», – ДИЛӘР. АХЫР ЧИКТӘ ЭШ БАРЫБЕР ЭШЛӘНДЕ, ҺӘМ БУ – БИК ЯХШЫ. **КАЗАННЫҢ МЕҢЬЕЛЛЫГЫНА МЕТРОНЫ АЧА АЛДЫК – ХЫЯЛЛАР ТОРМЫШКА АШТЫ.**

станция төзергә кирәк. Димәк, стеналары су үткәрмәскә тиеш. Һәм без бораулап тутырылган субайлар системасын үзләштерә башлыйбыз. Бу эшне ниндидер «Космос» дигән фирма эшләгәнен хәтерлим. Бу сүзне ишетүгә шатланыштык. О! Космик технологияләр! Ә ул Мәскәүнең кремний-органик кушылмалары дигән гыйбарәдән кыскартып алынган сүз икән. Менә шундый космос!

Шулай да, космосмы-түгелме, бик куәтле конструкция килеп чыкты, алардан җир асты стеналары корылды. Метроның барлык станцияләрендә дә зур һәм куәтле трасформатор подстанцияләре төзелде. Электр энергиясеннән башка, үзегез аңлыйсыз, метро да юк.

ҮЗЕБЕЗДӘ ҖИТЕШТЕРЕЛГӘН

Казый торган комплекс тоннель ясап бара һәм казыган өлешкә бетон боҗралар урнаштыра. Боҗралар да ул вакытта әллә каян алынмады. Без аларны җитештерә торган завод ачтык. Тимер-бетон эшләнмәләр заводын үзгәртеп кордык. Һәм бетон боҗралар ясарга өйрәндек. Боҗралар сегментларыннан хасил булган тоннель тыштан сыек бетонит белән чолгап алына, нәтиҗәдә су үткәрми торган була.

ТӨРЛЕСЕ БУЛДЫ...

Төзелеш вакытында төрлесе булды. Бервакыт тоннель казый торган комплекс су астында калды. Суны суыртып алырга туры килде.

Бу тоннельләрне тикшерергә чыккач, җир астына төшеп, шпаллар буйлап җәяү барабыз: мин – алдан, арттан – озата баручылар. Шпаллар арасында ара бәләкәй. Вак-вак атлап барырга туры килә, дөрес атламасаң, суга, пычракка төшәсең дә китәсең... Төрлесе булды. Шуңа да төзелешкә резин итекләрдән генә чыга идек.

Эш бара, тоннель казыла... Поездлар өчен вагоннар кирәк була башлады. Аларга Санкт-Петербург заводында заказ бирдек. (Сүз уңаеннан, соңыннан бу заводта Путинның әтисе эшләгәнне белдек – **ред. иск.**). Вагоннарны ясадылар, без алар өчен депо төзедек, тимер юл буйлап Казанга алып кайттык. Әмма аларны вокзалдан депога ничек китереп җиткерергә? Шундый конструкция уйлап таптык: вагоннарны зур яссы корыч җәймәләргә утырттык, аларны трослар белән танк училищесы биргән танкларга бәйләдек, төнлә кирәкле урамнарда хәрәкәтне туктаттык һәм шул рәвешле аларны депога алып бардык. Бу тамашаны күз алдына китерәсезме! Танклар вагоннарны асфальт буйлап өстери – дөбер-шатыр килә, тирә-якка очкыннар чәчри! Ә башкача ничек? Вагоннарсыз метро булмый.

Әмма иң зур кыенлыкны, ничек кенә сәер тоелмасын, без халыкның канәгатьсезлегеннән күрдек. Алар нәрсә күрә: бөтен җирдә чокыр-чакыр, нәрсәдер төзиләр, менә тоннель казый торган «Сөембикә» комплексын алып кайтканнар да җир астына кертеп җибәреп маташалар... «Ул акчаны безгә бирсәгез, яхшырак булыр иде...», «Акчаны җиргә күмәләр...», – диләр. Нәрсә генә сөйләмәделәр!

Бервакыт безнең Рөстәм Нургали улы Миңнеханов Герман Грефта «Эшлекле иртәнге аш»та чыгыш ясады. Ул анда кайчандыр метро төзелешенә каршы булуын әйтте. (Чөнки ул вакытта финанслар министры булып эшли иде һәм метрога акчаны да ул табарга тиеш. «Каян алыйм?» – ди ул миңа). «Шуңа да каршы идем, – дип сөйләде ул. – Әмма безнең ул вакыттагы мэр бик үткен иде. Ул президентка керә, аны үгетли, ә җитәкче аннары мине мәҗбүр итә. Метро бездә шулай башланды.

Ә бүген метрода күпме кеше йөри! Шуңа да хатамны таныйм: мин хаклы булмаганмын!»

Аның чыгышының мәгънәсе шунда: киң колачлы эшләргә каршы булырга кирәкми, киресенчә, мөмкинлек табып эшләвең яхшырак. Ахыр чиктә метро барыбер төзелде, бу – бик яхшы. Без Казанның меңьеллыгына метроны ача алдык – хыяллар тормышка ашты.

КИЛӘЧӘК БУЫННЫ АЛДАМАДЫК

Киләчәк буынга капсула күмеп калдырганны хәтерлим. Хәтта фотографиясе бар: Минтимер Шәрип улы, Марат Муллахмәт улы, мин... Бер үк вакытта Башкортстанда да капсула күмәләр. Шулай ук метро төзи башлыйлар.

– Ә ул капсулада ниләр язылган иде?

– Кайдадыр әлеге документның күчермәсе саклана миндә. Карарга кирәк... Казанлыларның киләчәк буынына бу җирдә метрополитен булачак, аны без төзибез, шундый игелекле гамәл кылып калдырырга сүз бирәбез, дип хәтердә калган...

Хәзер ничек? Метро эшли. Киләчәк буынны алдамадык. Ә Уфада метро юк. Шул Түбән Новгородтагы сәбәп аркасында: Уфа Агыйдел елгасы буйлап урнашкан шәһәр. Трамвай Уфаның бер башыннан икенче башына кадәр йөри. Һәм алар проектта метроны трамвай астыннан үткәрәләр... Шуңа күрә дә аларның эшләре килеп чыкмый. Ә без булдырдык! Һәм шуның белән горурланабыз да!

МӨМКИН БУЛМАГАН ЭШ ЮК

– Ни өчен сез һәрвакытта да колачлы проектларга алына идегез: Казанның меңьеллыгын үткәрү, Казанның Изге ана тәресен кайтару, метрополитен төзү?..

Рөстәм Миңнеханов һәм Камил Исхаков Казан метросы төзелешендә.

– Күрәсең, ул бала чактан ук киләдер. Холкым шундый, – дип кулларын җәя Камил Шамил улы. – Республиканың Югары Советына, хакимияткә эләккәч тә, безнең арада шундый инану яши иде: без халыкка хезмәт итәргә килдек. Һәм ничек кенә авыр, катлаулы булмасын, халыкның проблемаларын хәл итәргә кирәк, без тиеш. Бу хәл итәргә кирәк дигәндә, уңышка ирешүнең формасы бик гади – мөмкин булмаган эш юк. Чынлап та юк. Тәрене кайтаруны халык сорады – кайтардык. Меңьеллыкны үткәрдек. Тарихи, истәлекле урыннарыбызның ЮНЕСКОның Бөтендөнья мирас объекты итеп танылуына ирештек. Метро төзергәме? Төзедек. Ахыр чиктә барысы да килеп чыкты бит. Иң мөһиме – эшкә тотыну. Кайсыдыр эш тәгәлләнде, кайсыдыр дәвам итә – шул ук метро, мәсәлән.

25 НЧЕ ТАРИХ

«МЕТРО ТӨЗҮЧЕЛӘРНЕҢ КҮЗЛӘРЕН КҮРСӘГЕЗ ИДЕ СЕЗ...»

Евгения Чеснокова

–Казан метросын төзү дәвере – тормышымдагы әһәмиятле һәм истәлекле сәхифәләр, – ди РФ Дәүләт Думасы депутаты Татьяна Ларионова. – Гамәле белән сүзе тәңгәл килгән ышанычлы кешеләр белән эшләдек без ул вакытта, һәм ул эш бик кызыклы иде. Метро төзүчеләр белән тәмам дуслашып беттек, мондый дуслык белән горурланмый мөмкин түгел!

КАТЛАУЛЫ, МӨМКИН ТҮГЕЛ, ЛӘКИН КИРӘК!

– Татьяна Петровна, 1990 нчы еллар ахырында сез Казан Башкарма комитетында, ул вакыттагы мэр Камил Исхаков командасында эшләдегез, дөрес, социаль яклау идарәсен җитәкләдегез... Бу вазыйфа ни рәвешле метро төзелеше белән бәйле иде соң?

– Төп юнәлешем башка булуга карамастан, миңа һәрчак августның төп вакыйгаларына әзерлекне йөклиләр иде: Казанда Шәһәр көне һәм республика бәйрәме уңае белән уздырыла торган чаралар. 1997 елның августында Татарстан башкаласында Бөтендөнья татар конгрессын үткәрү планлаштырылган иде. Миңа әзерлек этабында аның штабы белән җитәкчелек итүне ышанып тапшырдылар. Конгресс кысаларында метро төзелешенә старт бирү дә күздә тотылды.

Штаб җитәкчесе буларак, күпсанлы эшлекле киңәшмәләрдә катнашырга туры килде. Метро төзүчеләрнең күп кенә терминнары хәтеремә уелып калды: нәрсә ул пионер траншеясы, тоннельнең җир асты үтеше, беренче линияне эшләтеп җибәрү комплексы, берьяклы куып күчерү, куып күчерү тоннеле һ.б. Җәй буена, һәр көнне диярлек, я әче таңнан, я кара төндә, оператив киңәшмәләр уздыра идек. Бик җентекле эш алып барылды: җитди мәсьәләләр чишелде, хәвеф булуны да исәптә тотып, күп җаваплы карарлар кабул ителде. Хәвеф, дигәннән, шәһәрнең җир асты сулары гына да ни тора иде...

– Казан Башкарма комитетында ул чакта бу төзелешнең зарурлыгына карата шик белдерүчеләр бар идеме?

– Ул вакытка инде Казан метросы кирәкме-түгелме дигән бәхәсләр тынып өлгерде. Ә аңарчы коллегалар арасында җитди шөбһә белдерүче кешеләр дә булды. Гомумән, туксанынчы, нуленче елларның гаять катлаулы булуын онытырга ярамый. Җитмәсә, республика белән илдәге икътисадый вазгыятьне исәпкә алып, метро төзелешенә кирәксез бер дуамаллык, ахмаклык буларак караучылар да аз булмады. Кайберәүләр, киресенчә,

Фото: «Казметрострой» АҖнән алынды

төзелешне киләчәк эше, дип санады. Юлларыбыз иркенәеп китәр, шәһәрлеләрнең тормыш сыйфаты яхшырыр, Казанның абруе күтәрелер, республиканың да имиджы ныгыр, дип өметләнделәр.

Мәсьәләдә төп ноктаны 1996 елда Минтимер Шәрипович Шәймиев белән Борис Николаевич Ельцин куйды. Алар бик тә әһәмиятле карар кабул итте: миллион кешесе булган шәһәргә метро, һичшиксез, кирәк. 1997 елның җәендә инде «кирәкме-кирәкмиме» рәвешендә фикер йөрткән кешеләр түгел, ә аек акыл белән хыялны тормышка ашырырга ният итүчеләр килде.

– Ул чакта үзегезгә бу хыялның чынга ашуы мөмкин түгелдер, дигән уй килгәне булдымы?

– Юк! Метро төзүчеләр белән аралашкан кеше буларак, төгәл беләм идем: ничек планлаштырылган, шулай булачак! Сез аларның күзләрен күрсәгез иде... Андагы кызыксынучанлыкны... Гамәлләрендә дә бернинди артык нәрсә юк, шул гына: алга куелган бурыч бар, хәл итәбез! Бурычны чишү юлларын эзләде алар. Гаҗәеп бөтен, бер-берсенә таяныч, терәк була ала торган, чын фикердәшләр командасы иде ул! Девизлары мондый булды: «Казанның меңьеллыгына метро бирергә әзерме син?!» Әйе, катлаулы, мөмкин түгел диярлек, могҗизага тиң бурыч, әмма – кирәк! Без барыбыз да шул девиз белән яшәдек һәм эшләдек!

Төзелеш башланганнан соң, йөзенче көнне узган митингны яхшы хәтерлим. Әле алда тагын берничә йөзләгән шундый көн барлыгын белеп торабыз... Әмма метро төзүчеләр, шәһәр халкы алдына чыгып, эшләнгән эшләр турында сөйләүне кирәк дип тапты. Бу кешеләрдә меңьеллык Казан алдында да, биредә яшәүче халык алдында да җаваплылык беренче көннәрдән башлап, ахыргача шундый булды. Ә иң мөһиме – ярату, эшләгән эшләрен чын күңелдән башкарды бу команда. Ничек аларга сокланмыйсың да, ничек алар белән горурланмыйсың, ди?

ГАҖӘЕП КОМАНДА

– Метро төзелешендә сезне сокландырган һәм дуслаштырган кешеләр турында җентеклəбрәк сөйләп үтсәгез иде...

– Беренчедән, әлбәттә, «Казметрострой»ның генераль директоры Марат Муллахмәт улы Рәхимов. Сүзе дә, эше дә бик төгәл кеше. Ул Казанга, төрле шәһәрләрдән җыеп алып, күпләгән көчле белгечләрне китерде. Арада Мәскәү метросын төзегән затлар да бар иде. Ул – «кирәк» дигән төшенчәне сүздән гамәлгә күчерә белгән кеше. Ярдәм итәргә әзерләрне дә таба, иптәшләрне дә туплый, җитәкчеләрне дә ышандыра... Кыскасы, яхшы итеп эшләүне җайга сала белә! Бөтен вакыйгаларның үзәгендә ул торды!

Олег Дмитриевич Антосенко – аны искә төшерми мөмкин түгел. Төзелеш буенча Исхаковның урынбасары булып эшли иде, Казанның метролы булуына бик күп көч кертте. Казанда ул вакытта бик күп башка объектлар да төзелде, шул исәптән, тузган торакны бетерү программасы актив гамәлгә ашырылды. Планнар янәшә барганда,

тиешле дәрәҗәдә тормышка ашыруның ничек катлаулы булганын күз алдына китерәсездер... Олег Дмитриевич Казанның бөтен төзелеш блогын әйдәп барды, аңа рәхмәтем чиксез! Кызганыч, арабыздан иртә китте, ковид аяктан екты. Метро төзүчеләр җылы итеп искә аладыр: ул җитәкче генә булмады, ә терәк тә, иптәш тә...

Тагын бер шундый фикердәш – Григорий Александрович Клементьев. Метро төзелеше башлангач, финанс мәсьәләрен хәл итәр өчен махсус идарә булдырылды, Григорий Александрович аны җитәкләде.

Билгеле инде, метро – Камил Исхаковның үз куллары белән тудырып үстергән «баласы». Метро булсын өчен, ул җан атып йөрде, кирәклеген башкаларга караганда күпкә кайнаррак дәлилли белде. Төзелеш эшенә караган бер генә җыелышны да игътибардан читтә калдырмады.

ЮЛЛАМАНЫҢ СЕРЕ

– Метро төзелеше башланганда, киләчәк буыннарга юллама салынган капсуланы күмү идеясен тормышка ашыруда сезнең дә ролегез зур булган, дип беләбез...

– 1997 елның августына табарак киләчәк буыннарга капсула салып калдыру теләге туды, миңа аның текст проектын әзерләргә йөкләделәр. Татар конгрессына әзерлек барышында метро төзелеше проекты бердәнбер чара булмаганлыктан, ул чакта эшемдә яши идем диярлек. Текстның кайбер өлешләрен язгалап карадым... Әмма бу шулкадәр зур җаваплылык, тулаем ерып чыгып кына булмый бит... Һәм менә мэр бүлмәсендә чираттагы төнге киңәшмәләрнең берсендә утырабыз, кинәт Камил Исхакович әйтеп салмасынмы: «Ну, төзүчеләр алларына куелган бурычны үтәде, безне Ларионова гына тоткарлый. Текст һаман юк». Коелып төштем, күземнән яшь бәреп чыкканны сизми дә калдым... Кабинеттан тышка атылдым, артымнан Рәхимов, Клементьев һәм Антосенко чыктылар. Салфетка бирәләр, күз яшьләремне сөртәм, әмма алар ага да ага. Аларның игътибарын, кайгыртучанлыгын тойгач, һич туктый алмыйм, иртәнге киңәшмәгә әзерләп өлгертәсе документлар турында да уйлыйм. Кинәт егетләр: «Әйдә, булышабыз!» – ди. Һәм

мин әйтә барган җөмләләрне салфеткаларга терки башладылар. Ни күрим - тезислар җыела! Аннары юллама текстын яңадан укып-барлап чыктык. Булды бит! Моны онытып буламыни?!

– Ахыр чиктә, текст белән ни булып бетте?

– Күтәреп, Камил Шамилевич янына кердем. «Миңа ошый, иң мөһиме – Шәймиевкә ошасын», – диде. Президент Аппаратына килгәндә, дулкынланудан кул-аякларым калтырый, тавышым үземне тыңламый башлады... Бу минем өчен чын мәгънәсендә сынау булды. Минтимер Шәриповичның һәр материалга нинди җентекле игътибар биргәнен белсәгез! Текстны алып калды, икенче очрашуыбызга төзәтмәләр кертеп кергән иде. Шактый саллы һәм күләмле. Нәтиҗәдә, сыйфатлы текст килеп чыкты.

– Анда сүз нәрсә турында бара?

– Әйтәм бит, ул чакта дөньяның барлык почмакларында яши торган татарларны кабул итәргә җыена идек... Текстның караламасы, кызганыч, сакланып калмаган. Эзләтсәм дә, таба алмадык. Үзе бер табышмак!

МЕТРО ТӨЗЕЛЕШЕ ҺӘМ БАЛАЛАР РЕАБИЛИТАЦИЯСЕ

– 1997 елдан соң, Казан метросы язмышына нинди дә булса кагылышыгыз булдымы?

– Әлбәттә! Берничә ел Россия Федерациясе бюджетыннан Казандагы ике объект кына финансланды: метро һәм Горкида инвалид балалар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге. Соңгысының төзелешен Социаль ярдәм идарәсе җитәкләде. Иң катлаулысы – үзара акча алмашулар системасы: тере акча керми, тиешле субвенцияләрне генә алабыз. Гаять катлаулы һәм бик зур тизлек таләп итә торган җитди финанс схемалары корырга кирәк.

Клементьев белән атна саен Мәскәүгә йөрдек. Үзара акча алмашу кагыйдәләре көн дә диярлек үзгәреп тора. Иртән безгә: «Саклык банкында счёт ачыгыз», – дип әйтсәләр, кичкә инде: «Юк, Тышкы икътисадый банкта», – дияргә мөмкиннәр иде. Һәрбер банк үз таләпләрен куя, шартларын чыгара, документлар белән башны катыра, һәр министрлык үз отчётлары белән тилмертә. Һәр үзгәреш буенча без кичкә Исхаков белән шалтыратышып сөйләшәбез. Ул, кич булуга, төн җитүгә карамастан, җаваплы кешеләрне чакыртып ала. Ә таң белән тиешле документларны безгә самолёт рейсы белән җибәрәләр. Билгеле, республика ярдәменнән башка башкарып чыга торган эш түгел, Минтимер Шәрипович белән Рөстәм Нургалиевич үзләре барысын да контрольдә тотты. Шуңа да аяк терәп әйтә алабыз: инвалид балалар өчен шәһәр социаль-тернәкләндерү үзәгенең ачылуы да метростройдан башка була алмас иде.

АТА-АНАЛАР ХАКЫНА

– Метро ачылган 2005 елдан аеруча исегездә нәрсә калды?

– 2005 елның җәендә мин кабат шәһәр штабын җитәкли идем. Бу юлы – Казанның меңьеллыгын уздыру буенча. Метро төзүчеләр командасы белән беренче тармактан узу мөмкинлегенә ия булуым белән бик горурланам.

Тагын бер кешене искә аласым килә: бүгенге көндә Казан Сынлы сәнгать музее директоры Розалия Нургалиева, ул чакта Казанның баш рәссамы иде. Беренче биш станциянең бар матурлыгы – аның командасы казанышы. Алар, чын мәгънәсендә, горурлыгыбызга әйләнде.

2005 елның сентябрендә Ратушада Казанның меңьеллыгы уңаеннан медальләр тапшырдык. Бөек Ватан сугышы елларында шәһәр өчен күп көч куйган ветераннарга да бирелде алар, сугыштан соң фидакарь хезмәт итүчеләргә дә. Камил Шамилевич күпчелек ветераннарга медальне үз кулы белән тапшырды. Чараларның берсеннән соң, аны чәйгә калырга чакырдылар. Әмма ул баш тартты: «Бүген медальне үз әтиемә дә тапшырдым. Тантана узганнан соң, метроның барлык станцияләрен икәүләп йөреп чыгарга сүз куештык. Бу төзелеш – шәһәребезнең, республикабызның горурлыгы, минем дә горурлыгым! Иң якын кешем алдында сынауны узганымны күрсәтәсем, аңа отчет тапшырасым килә!» – диде. Бу чын бәхет бит: эшеңне дөнья белән генә түгел, ә иң якын, кадерле кешеләрең белән дә уртаклаша алу.

ГАСЫР ТӨЗЕЛЕШЕ ДӘВАМ ИТӘ

– Метро төзелешен күзәтеп барасызмы?

– Әйе, эшнең тукталып калмавы сөендерә, республика өчен метро бүген дә – төп әһәмияткә ия бурыч. Бу Рөстәм Нургалиевичның да – гомерлек хезмәте. Кайчандыр аның ярдәмчесе идем, шуңа метрога мөнәсәбәтен бик яхшы беләм. Ул аның үсешен уңышлы дәвам иткән зат кына түгел, метро төзүчеләрнең хезмәтен ныграк бәяләгән кеше дә. Әлбәттә, Казанның хәзерге мэры Илсур Рәисович Метшин да бу юнәлештә максатчан эшли. Казан өчен дә, республика өчен дә – гасыр төзелеше ул. Ил күләмендә дә шулай, дип курыкмыйча әйтергә мөмкин.

Метрополитен – шәһәрдәшләребезнең тормыш сыйфаты билгесе. Һәм бу сыйфат дәрәҗәсе Рәисебез командасы тырышлыгы белән елдан-ел арта гына бара.

ТАТАРСТАН: ДАҺИЛАР ТӨБӘГЕ

Җәй айларында ялдан да яхшырак нәрсә булырга мөмкин? Тик бер нәрсә бар – ял Татарстанда булырга тиеш. «Татарстан» журналы редакциясе моны ел саен гамәлдә исбатлый, чөнки тулы составта республика буйлап сәяхәткә чыга. Төрле елларда чираттагы ялыбызны Идел, Чулман, Нократ һәм Агыйдел ярларында үткәрдек. Татарстан күлләрен күреп ләззәтләндек, кайвакыт экстримнан да баш тартмадык. Тыюлыклы урманнар арасына кереп, Болгар белән Зөянең, Чистай белән Алабуганың архитектура җәүһәрләренә һәм борынгы һәйкәлләренә сокландык...

Ә быел нишләргә? Үткәннәрне кабатларгамы?! Юк, әлбәттә! «Татарстан»ның быелгы ял маршруты күңелле генә түгел, истәлекле, танып-белүне тирәнәйтерлек тә булырга тиеш, дип хәл ителде редакция планёркасында. Без танылган якташларыбызның яшәү һәм иҗат итү урыннары буйлап сәяхәткә чыгарга карар кылдык. Татарстан үзенең матурлыгы белән генә түгел, күренекле шәхесләре белән дә дан тота бит.

Әгәр басмабызны укыгач, сез дә безнең юлдан сәяхәткә чыгасыгыз килә икән, димәк, ялыбыз уңышлы да, файдалы да узган.

Фото: Әхмәт Шакиров

ВАСИЛЬЕВ ЯНЫНА, ВАСИЛЬЕВОГА

Дмитрий Сивков

Васильево бистәсенең Ленин урамындагы бер катлы агач барак хәтта анда рәссам Константин Васильевның мемориаль музее урнашуын белмәүчеләрнең дә игътибарын үзенә җәлеп итә. Өй заманча күпкатлы йорт янында, океан лайнеры фонындагы балыкчылар баркасы шикелле, бик сәер күренә.

Васильевлар йорты. Элеккеге күренеше.

Зур көймә белән ассоциация (нидерланд теленнән «баркас» шулай тәрҗемә ителә) очраклы гына түгел. Казаннан кайтканда, рәссамның дусты һәм минем гид Геннадий Пронин бик билгеле булмаган бер фактны сөйләргә өлгергән иде – Васильев яхта, дөресрәге, диңгез шлюпкасы хуҗасы булган. Васильев картиналарының үзе исән чагында уңышка ирешмәгәнлеге билгеле, андый кыйммәтле көймә сатып алырга акча каян табылган соң?

– Казан сәнгать училищесын тәмамлаганнан соң, Константин беркайда да рәсми рәвештә озак эшләмәде. Мәктәптә рәсем һәм сызым укытты, урман комбинатында һәм пыяла заводында рәссам-бизәүче булды, – дип сөйләде Геннадий Пронин. – Бер урында өч айлап эшли дә китә, үзе өчен картиналарын яза. Бизәү эшләренә заказлар исә даими булып тора иде. 1971 елда җирле хакимият заказы буенча Бөек Октябрь революциясенең түгәрәк датасына рәссам бөтен бистәне бәйрәм транспарантлары белән бизәде. Ул вакыт өчен шактый зур акча – 700 сум алды. Һәм аларны шунда ук туздырды да – җилкән белән дә йөреп булган «Ял-8» шлюпкасын сатып алды.

Рәссамның дусты сүзләренә караганда, аларга җилкәнле көймәдә йөрергә китап буенча өйрәнергә туры килгән. Идел буйлап сәяхәт иткәннәр. Бу иҗади рейслар булган, алардан соң берничә «Зөя» картинасы язылган – алар

Фото: автордан, Геннадий Пронинннан



Васильев яхтасының фотосы сакланмаган, әмма ул менә шушындый булган.

«Кое янында» картинасының эскизы.

хәзер Казанның Бауман урамындагы Васильев музеенда һәм ТР Дәүләт картиналар галереясында саклана.

– Ә күпме тапкыр маҗарага тарыдык! Штормга да эләктек, ул вакытта Идел буйлап күп йөргән кораблардан да качарга туры килде. Костяның вафатыннан соң, яхта да тузды, карап бетерә алмадык... – ди дусты, үкенүен яшермичә.

ЙОРТ

Һөнәре буенча инженер, күңел халәте буенча сәнгатькә мөкиббән Геннадий Пронин – хәзерге вакытта Казандагы Васильев музееның өлкән фәнни хезмәткәре һәм аның әсәрләре коллекциясе иясе. Аны рәссамның язмыш тарафыннан бирелгән саклаучы фәрештәсе дип атарга мөмкин. Күп очракта бу кешенең инициативасы белән, тагын рәссамның сеңлесе Валентина һәм янә бер дусты Олег Шорников ярдәмендә, Васильевны вафатыннан соң да онытмыйлар. Алай гына да түгел, Мәскәүдә алар оештырган күргәзмәләр 1970 нче еллар ахыры – 1980 нче еллар башында провинциаль рәссамның иҗатын бөтенләй башка дәрәҗәгә күтәрә.

Шорников белән Пронинннан башка, Васильево бистәсендә дә рәссамның музее булмас иде. Константинның дуслары, бульдозер юлына басып, баракны ишүдән саклап кала: бульдозерчы ике көнгә югалып торсын өчен, аңа ике шешә аракы бирәләр. Һәм шул вакыт эчендә йортны ишмәскә дигән рөхсәт алырга өлгерәләр. 1996 елда анда музей ачалар.

Музей директоры Марина Антонова.

Минем Васильеводагы Васильев белән танышуым исә шул музейдан башланды да инде. Музей директоры Марина Антонованың безнең гидка карата аерым хөрмәте аркасында «Кое янында» картинасының эскизын кулга тотып карау мөмкинлеге тәэсирләндерде. Аның ниндидер журналдан кисеп алынган репродукциясе безнең кухняда эленеп тора, яшьрәк чакта мине үзенең энергетикасы белән сихерле иде.

Хәзер йөзьеллык бинаны реконструкцияләү эшләренә керешәләр – проект әзер, һәм аны башлап җибәрү өчен акча җыялар. Хәер, капремонттан соң, мемориаль фатирга хас бик кадерле мохит юкка чыгар, дип шикләнәм. Әйе, шәхси әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары, рәсемнәр, эскизлар, картиналар һәм интерьер сакланачак, әмма рәссамның биредә булу тәэсире, һичшиксез, юкка чыгачак: хәзер исә әйтерсең лә ул үзенең беренче мәхәббәте һәм музасы Люда Чугунованы пыяла заводына кадәр озатырга гына киткән һәм тиздән кайтып керер сыман... Шулай булгач, кемнең мөмкинлеге бар, шушы газиз почмакны якын арада, реконструкция өчен кирәкле 56 миллион сум акча җыелганчы, килеп күрергә киңәш итәм.

Васильев тугры дусты Пронин белән.

КОМЛЫК

Ә безгә Васильев исеме белән бәйле урыннар буйлап юлга чыгарга вакыт. Беренче тукталыш – Сумка белән Идел кушылган урында. Рәссамның дуслары җәй көне күп вакытларын биредә үткәргән. Монда су коенганнар, учак якканнар, Васильев үзенең яхтасын да биредә тоткан. Хәзер бу урын тал куаклары белән капланган, кеченә генә причалга бара торган сукмак кына бар, аның янында нәүмизләнеп бер-ике көймә ята.

Аның каравы, берничә йөз метр ераклыкта, инде Идел ярында – комлык. Пронин узган гасырның 60-70 нче елларында биредә агач эшкәртү калдыклары чүплеге булганлыгын сөйләде – эшсез рәссам һәм аның дусты өчен

Кайчандыр чүплек урыны булган җирдә хәзер – пляж. Нәкъ менә шушында Васильев белән Пронин картина рамнары өчен кыртыш җыйган.

Сумка елгасы ярларын хәзер тоташ тал басып киткән.

Оригиналга охшатып ясалган багет.

чын клондайк инде. Монда алар кыртыш – бүрәнә ярганда ике кырыйда кала торган кайрылы такта җыйган. Үз картиналарын рамлау өчен башка материалга рәссамның акчасы булмаган.

Каен тузы кисәкләре ябыштырылган сәер багетка мин үзем рәссамның Казандагы музеенда ук игътибар иткән идем. Аерым алганда, «Көтү» картинасының рамы - кысасы шундый. Хәтерлим әле, мондый оригиналь бизәлеш өчен багет остасы эшенә чын күңелдән сокланган да идем хәтта. Ә моның сәбәбе башкада булып чыкты. Оригиналь «кыртыш» багетлар сакланмаган икән. Бу хакта Геннадий Пронин менә нәрсә ди:

– Картиналар күпмедер вакыт Мәскәү музеенда саклана. Музейны оештыручы белән Васильевның сеңлесе Валентина арасында үзара каршылыклар чыга. Шуннан соң ул урлаша башлый – рамнарын гына калдырып, картиналарны алып китә. Суд карары белән полотноларны кире кайтаралар, ә менә кысалары инде юкка чыккан – сәнгатьтән ерак бер кеше, аларны гади такта дип уйлап, яндырган була. Мәскәүлеләр картиналарны Казанга кайтарганда, багетларын оригиналга охшатырга тырышкан, һәм моның өчен аларга рәхмәт, әмма, әлбәттә, бу инде оста үзе ясаган әйбер түгел, – дип сөйли Геннадий Пронин.

Урман комбинаты чүплегендә Костя белән Гена ДВПдан ясалган әрҗәләргә дә юлыгалар, аларны сүтәләр, һәм рәссам шуларга да картиналарын яза. Мәсәлән, танылган «Дунайның тууы» картинасының Васильеводагы музей экспозициясендә сакланган бер вариантының өске сул почмагында тишек бар – кадак эзе.

Шунда ук – чүп-чар арасында СССР Рәссамнар берлеге әгъзаларына гына бирелә торган станоклы мольберт өчен такталар да табыла. Беркайчан да әгъза булмаган Васильевка ул тәтемәс иде, әлбәттә, аның каравы, ул якын дусларыннан уңа – инженерлар Пронин һәм Шорников аны тасвирламалар буенча ясап бирә.

«ПАРФЕНОН»

Сәяхәтнең икенче пункты – «Парфенон». Васильев үзе укыган мәктәпне (соңрак Пионерлар йорты) шулай дип йөрткән, күпмедер вакыт әле анда укыткан да. Хәзер Ленин урамындагы бу бинаның – бер катлы күпфатирлы торакның (икенче каты 90 нчы еллар уртасында янган) антик архитектура һәйкәле белән бернинди дә охшашлыгы юк. Ә Васильев исән чакта ике катлы бинаның үзәк ишеге колоннада белән бизәлгән була.

«Парфенон»нан Васильевны теңкәгә тигән стакан һәм шакмаклар урынына укучыларга Венера Милосскаяны күчереп ясарга тәкъдим

«Парфенон». Элек нинди булган.

«Парфенон». Хәзерге вакыты.

«Клуб-с три» бүген.

иткәннән соң куып чыгарганнар. «Ялангач хатынны ясарга рөхсәт итмибез!» - мәктәп администрациясенең катгый карары шундый була. Шуннан соң Васильевка урман комбинатының рәссам-бизәүчесенә әйләнергә туры килә.

Ә без урам буйлап алга барабыз. Максат – бистә мунчасы бинасы.

– Без Рәссам белән, – Пронин үзенең дусты һәм кумирының исеме һәм атасының исеме урынына аны еш кына шулай атый, – мунчага шактый еш йөри идек. Һәм юыну өчен дә түгел, ә буфетта сыра эчү өчен генә. Анда сыра бервакытта да бетми иде. Дөрес, кабымлык ярлырак: тоз сипкән кара ипи инде, – дип хәтерен яңартуын дәвам итә Геннадий Пронин.

Шулай бер баруларында, пыяла заводы клубының хуҗалык буенча мөдире Петя абзый аларның өстәл күршесе булып чыга. Васильевның эшләргә киндер юк дип зарлануын колак чите белән ишетеп, ул аңа ярдәм итәргә ниятли. Тагын берәр кружка сыра эчкәч, компания мәдәният йортына китә. Анда чормада КПСС Үзәк комитеты Политбюросының элеккеге әгъзалары портретлары тузан җыеп ята икән.

Шул рәвешле Васильев өч яңа киндергә ия була. Беренчел сурәтләрне бетерү өчен, киндерләрне бензин салынган тазда озак кына җебетергә туры килә.

Хәзер Петя абзыйның бүләгендә язылган картиналар Васильевның алтын фондына керә. Болар – «Урман чытырманы», «Один» һәм «Лена Осеева портреты». Алар Казан музее экспозициясендә тәкъдим ителә.

МӘХӘББӘТ ХАКЫНА

Киләсе локация – бистәгә керү юлындагы «Васильево» билгесе. Иҗатчы мәхәббәтсез яши аламыни?! Константин Васильев та искәрмә түгел. Гәрчә шуны танырга кирәк: остага чын мәхәббәтен очратырга туры килмәгәндер – ул буйдак булып калган. Әлбәттә, аның тормышында да мавыгулар булгалаган. Һәм алар арасында беренчесе – Людочка Чугунова. Безнең чираттагы тукталышыбыз нәкъ менә элеге чибәркәй белән бәйле дә инде. Безнең гид менә нәрсә сөйләде:

– Бу хәл 1962 елда булды. Без өчәүләп (тагын Шорников) Костя бүлмәсендә чәй эчә идек. Шулчакта үзенең сыйныфташы белән апасы Валентина кайтып керде. Сирәк очрый торган

Людочка Чугунова.

чибәр кыз. Өчебез дә шунда ук аңа гашыйк булдык. Әмма без Шорников белән бу юлы читтәрәк торырга ниятләдек, чөнки Костяга кызлар белән танышу авыррак: ул үз эченә бикләнгәнрәк егет, башкалар белән аралашырга яратмый, биюләр вакытында гел читтәрәк тора иде.

Люданы озатырга киткәч (без, аларга комачауламас өчен, Олег белән өйдә калдык), аңа юл чатында пыяла заводы шпанасы ябырылган. Монда урман комбинаты территориясе тәмамлана, хәтта зур капка да тора иде. Менә безнең егеткә эләккән дә инде: беренчедән, «чик»не бозган өчен, икенчедән, «аларның» кызларына күз салган өчен.

Сүз уңаеннан, музейда Васильевның күгәргән урыннарына Людочка сылаган театр гримы саклана. Аларның мөнәсәбәтләре барыбер барып чыкмады, бистә кызына гадирәк һәм тормышны алып бара алырдай кеше кирәк иде. КАИ студентына, үзенең яшьтәшенә кияүгә чыкты. Пыяла заводында эшләнмәләргә бизәк төшерүче рәссам булып эшләде. Хәзер Васильевода яши.

«КАЕНЛЫК»

Без дә «чик»не кичтек. Дөрес, моның өчен җәза бирүче булмады. Пыяла заводы клубын һәм аның артында урнашкан арт-объектны – җирле рәссамнар сурәт төшереп бизәгән озын бетон диварны күрдек. Кайбер сюжетлары танылган якташларының картиналары, аерым алганда, «Уракчылар» белән рухландырылган. Әмма безгә сәяхәтебезнең соңгы пунктына барырга вакыт җитте.

«Васильево бистәсендә каенлыкта, урманда җирләнгән...» дип хәбәр ителә интернетта таратылган мәгълүматларда. Каенлык зират булып чыкты. Дөрес, анда каеннар чыннан да күп үсә. Сүз уңаеннан, рәссам каберен озатучысыз да табарга мөмкин, аңа мәрхүмнең фирма билгесе рәвешендәге күрсәткечләр алып бара – «КВ» вензеле төшерелгән кош канаты. Кабернең тимер коймасында да шул ук вензель шәйләнә.

Кара габбродан ясалган һәйкәл гаҗәеп күренә: бер яктан киселгән плитә нәрсәсе беләндер гильотина пычагын хәтерләтә, әйтерсең лә нәкъ менә ул кылкаләм остасының гомерен өзгән (1976 елның 29 октябрендә рәссамны һәм аның иптәшен тимер юл кичүендә поезд бәрдереп китә).

Пронин нишләп һәйкәл өчен шушы ташны сайлаганын аңлата.

НАРАТ УРМАНЫНДАГЫ МОГҖИЗА

ДАҺИЛАР УРЫНЫ

Әскәр Сабиров

«Кораб урманы». Чынбарлыкта һәм рәссам киндерендә.

«Алабуга рәсемнәрен ясаганда, мин күңелемнән шунда күчә идем – күпме тәэсирләр һәм хатирәләр саклана бит анда! Шулай да язу бик рәхәт булды, бигрәк тә йортыбыз һәм бакчабызны. Мин аларны бик ачык итеп күз алдыма китердем, гүя йокы бүлмәсенең зур тәрәзәсе янында әнием утыра, ә кечен тау бите буйлап астан менгәндә, аның артында тагын кемнеңдер сыны шәйләнә – бу бәлки Катенькадыр, бәлки сеңелләремдер. Әйтәсе дә юк, татлы хатирәләр бик күп...» Иван Шишкин әлеге юлларны 1856 елда язган. Даһи өчен истәлекле урыннар буенча кыска юлкүрсәткеч үзе бит инде бу!

Менә ул – сугышлар һәм революцияләр зилзиләсендә могҗиза белән исән калган туган йорт. Монда сәүдәгәр улы Иван кайчандыр рәсем ясау белән җитди мавыгып киткән, башта кәгазьне «бозгалый» башлаган, ә аннары якындагы коймаларга сурәт төшергән, диләр. Яхшы гаиләдә бернәрсәгә дә яраксыз «буяучы» үсә дип уйлаган әнисенең моңа кәефе кырылган...

Рус пейзажы даһиенең бала чагындагы бу иҗатын вакытлыча онытыйк әле. Безнең өчен юлкүрсәткеч булган хатында Шишкин, күрәсең, бераз башка вакытны искә төшерә – үзенең рәссам булу омтылышында инде тәмам ныгыган чагын. Аңа ул вакытта унҗиде

Фотолар: Айдар Мөшәрәпов

яшь тулган, ул Казан гимназиясендә дүрт ел укып өлгергән, дәфтәрләренә рәсем төшерүдә зур уңышларга ирешкән һәм, чиновник булу перспективасын коточкыч дип санаганга күрә, эти-әнисенә бүтән анда укымаячагын кайтып әйткән инде.

ГАЗИЗ СУКМАКЛАР

Аның каравы, Алабугада ул сәгатьләр буе яраткан эше белән шөгыльләнә: рәсем ясый. Тирә-яктагы урманнарга, болыннарга, өйдән әллә ничә чакрым ераклыкка чыгып китә дә, мондагы матурлыктан хисләре ташып, күргәннәрен кәгазьгә күчерергә тырыша. Яшьтәшләре аны аралашырга яратмый, барысыннан да читләшә торган сәеррәк кешегә санаса да, табигатьтә ул бөтенләй башкага әйләнә: энергияле, эшлекле, мавыгучан. Кызык, киләчәктә атаклы «Нарат урманында иртә», «Арыш басуы», «Кораб урманы» картиналары һәм башка җәүһәрләре белән танылачак автор йөргән сукмаклар кайда икән соң?

Әти-әнисенә язган шул ук хаттан тагын бер ишарә табып алабыз. Кич белән, дип искә ала Шишкин, ул өенә «тау бите буйлап астан менә»... Алабуга тирәсендәге «таулар» – Танай урманы, Кызыл Тау инде ул. Бу шулай ук болгар чоры манарасы хәрабәләре урнашкан һәм бөтен Алабуга уч төбендәгедәй күренеп торган серле Шайтан каласы да: туган йортка, Спас һәм Покрау соборларына аннан гаҗәеп манзара ачыла...

Шишкинның 1849 елда ясалган «Шайтан каласы манарасы хәрабәләре» рәсеме – безнең фаразга иң яхшы дәлил. Әле тагын бер рәсем бар. Анысы күпкә соңрак, унике елдан соң язылачак. Сәнгать академиясен тәмамлап, Шишкин шул елда туган шәһәренә кайтачак һәм яңадан таныш хәрабәләр янына киләчәк. Шул рәвешле бүген Санкт-Петербургтагы Рус музеенда саклана торган «Алабугадагы Шайтан каласы манарасы» пәйда булачак – анысы инде өлгергән оста кылкаләме үрнәге булып тора.

Бәлки, нәкъ менә шушы җир рәссамның иң яраткан урыны булгандыр? Килешәсездер, шундый кыю фикер әйтеп тә, Шайтан каласына бармау дөрес булмас ул.

Ә манара астында гаҗәеп манзара ачыла: Туймна елгасы Чулманга тоташа, тугайлыклар балкып утыра, алар ерактагы горизонтка тоташа...



Менә ул безнең күз алдыбызда - борынгы «Шайтан каласы». Манарадагы «яра» эзе кайчандыр Иван Шишкин сурәтләп калдырган стена фрагменты кайда булганын күрсәтеп тора.

МӘҢГЕЛЕК ИЛҺАМ ЧЫГАНАГЫ

Менә ул безнең каршыда, шул ук таш манара. Аның тәнендәге яра кайчандыр Иван Шишкин сурәтләп калдырган дивар фрагментының кайда икәнен күрсәтә. Манара, исегезгә төшерәбез, XIX гасырның 60 нчы еллары ахырында рәссамның этисе Иван Васильевич Шишкин тырышлыгы белән торгызылган.

Ә манара артында, аста, – искиткеч пейзаж: Туйма белән Чулманның кушылган урыны, кайдадыр бик-бик еракта офыкка тоташкан болыннар... Монда басып торганда, Сәнгать академиясен бик яхшы билгеләренә генә тәмамлап, Европага иҗат сәфәренә бару хокукы бирелгән Иван Шишкинның, ни өчен чит илгә китмичә, нәкъ менә бирегә – үзенең мәңгелек илһам чыганагына юл тотуын аңлый башлыйсың.

Ике елга кушылган җирдә басып торгач, Шишкин кебек өенә «тау бите буйлап астан менү» өчен, аскарак төшәбез. Юл Туйма яры буйлап болыннарга һәм Шишкин буаларына алып бара (монда кайчандыр рәссамның этисе парк ясаган булган). Буалардан өстәрәк рәссамның туган йорты урнашкан. Ул искә алган «безнең бакча» менә шушында, тау битендә, йорттан бераз астарак була. Бакча күптән юк инде. Бәлки, аны торгызырга кирәктер?

ИДӘН АСТЫНДАГЫ «УРАК ӨСТЕ»

Рәссамның туган йорты. Монда барысы да Иван Шишкин үзе исән чактагы кебек. Сүз уңаеннан, замандашларыбызга бу эштә

Рәссамның бүлмәсе.

Иван Васильевич Шишкин һәйкәле.

рәссам үзе ярдәм иткән – ул бүлмәләр һәм җиһазларның барысын да җентекләп рәсемгә төшереп калдырган. Шулай булгач, «Без сезнең белән, этием, биредә Шайтан каласы манарасы турында фикер алыштык һәм Петр атакайның язмаларын укыдык», – дип Шишкин тасвирлап калдырган зал нәкъ моннан гасыр ярым элек ничек булган, хәзер дә шулай. Әтисенең имән өстәле, стенада ау сюжеты төшерелгән гобелен, ау быргысы һәм мылтык... «Шушы ук тәрәзәләр, туганым Николай Иванович, сине дә, синең бүлмәңне дә, мылтыкларыңны да, кайвакыт уңышсыз булган авыңны да, шулай ук ядрә кою һ.б. да хәтерләтә», – дип искә ала Иван Шишкин.

Әтисенең өстәлендәге зур кара савытын күргәч, Иван Васильевичның «Записки достопримечательностей разных» дигән кадерле дәфтәрен ачуын һәм шатлыклы дулкынланудан чак кына калтыранган кулы белән: «13 гыйнварда, 1832 елда, чәршәмбе көнне, төнге сәгать уникенчедә улым туды... Чукындыру вакытында сабыйга Иван исемен куштык», – дип язып куюын күз алдына китерәсең.

Егерме елга якын вакыт узачак һәм «Иван сабыйның» биредә, туган йортының икенче катында, иң беренче тыйнак кына остаханәсе барлыкка киләчәк. Картина рамы, буяулар белән палитра, кылкаләмнәр... Рәсем ясаганда, ул дөньядагы башка нәрсәне онытачак. Бервакыт, шулкадәр эшкә бирелеп китеп, ачык тәрәзәдән түзә алмаслык эсселекне сизеп алгач кына, чынбарлыкка әйләнеп кайтачак: якындагы йортлар яна икән бит. Ул көнне ут ярты Алабуганы юк итәчәк...

Йөз ел узгач, инде совет чорында, йортны ремонтлаганда, эшчеләр идәнне куптарачак һәм бер картина табачак. Экспертлар раслаячак: бу – ул вакытта әле үзлегеннән өйрәнгән рәссам Шишкинның беренче эшләреннән. «Урак өсте» картинасын ул унсигез яшендә язган һәм, әлбәттә, әсәр камиллектән ерак тора. Кем белә, бәлки, Иван Шишкин үзе, «балачак» тәҗрибәсеннән оялып, аны кеше күзеннән ераграк яшергәндер? Икенче яктан, «Урак өсте» булмаса, оста иҗатының иң югары нокталарыннан берсе саналган «Арыш басуы» да язылмас иде...

СПАС СОБОРЫ ЯНЫНДА

Ничек кенә булмасын, ә Шишкинның «Урак өсте» картинасының оригиналын бүген монда, газиз туган йортында күрергә мөмкин. Аны язу вакыты, күрәсең, якынча башка - үзлегеннән өйрәнүче рәссамның киләчәк язмышын билгеләүдә мөһим роль уйнаячак вакыйга белән туры килгәндер. Иван Мәскәүдә Строганов рәсем мәктәбен тәмамлаган иконалар язучы Иван Осокин белән таныша.

Шишкинның туган йортыннан Спас соборына кадәр өч йөз адым үтсәк, кайчандыр бу хәлиткеч танышу булган урынга килеп җитәрбез. Гыйбадәтханәдә еш булган Шишкин (собор манарасы өчен чаңнарның берсен кайчандыр аның бабасы койган) Мәскәү рәссамнарының биредә иконостас ясауларын белми калмаган, әлбәттә. Шунысы гына гаҗәп: Шишкин, бик йомык һәм оялчан булса да, ничектер осталар белән сөйләшергә батырчылык иткән. Ә бәлки, бу озын буйлы егетнең сәгатьләр буе аларның эшләвен күзәтеп торуын күреп, Осокин үзе инициатива күрсәткәндер?

Шишкинның «Урак өсте» картинасының оригиналын әти-әнисе йортында күрергә була.





Юл Туйма яры буйлап уза, болынлыкка һәм Шишкин буаларына алып чыга. Югарыда, буалары өстендә, рәссамның әтисе йорты һәм Спас соборы.

Шунысы хак: әлеге аралашу дуслыкка әйләнә. Осокин, күрәсең, егетнең талантын сизеп ала. Ул аңа буяулар, кылкаләм бирә, белгәннәрен өйрәтә. Иванның портретын ясый. Һәм, иң мөһиме, Мәскәү сынлы сәнгать училищесына укырга барырга киңәш итә. Ике иҗади шәхеснең сәнгать турында әңгәмәләре чәй янында гына бармый, бу хакта туганнары да белеп ала. Аңлашу барышында Иван Мәскәүгә рәсем сәнгатен өйрәнергә барырга теләве турында белдерә, моның белән әнисен бик нык пошаманга сала. Әтисе исә аек фикер йөртә: белмәссең, бәлки укыр да, икенче Брюллов булыр...

БАШКА БЕРКЕМ ДӘ КҮРМӘЯЧӘК МАТУРЛЫК

Троица чиркәве. Рәссамның туган ягындагы тагын бер адрес. Шишкиннар бик дини булган. Кичләрен гаиләнең иң яраткан шөгыле «Изгеләр тормышын» («Житие святых») уку булган, дип сөйлиләр. Ә якшәмбеләрдә, бәйрәм көннәрендә олылар да, кечеләр дә бергә бу храмга гыйбадәт кылырга барган.

Ни өчен зираттагы Троица чиркәве? Эш шунда ки, рәссамның атасы Иван Васильевич Шишкин анда алыштыргысыз чиркәү старостасы була, гаилә тиешле чиркәү дисәтинәсен бирегә бирә. Агач чиркәү тузгач, яңа таш чиркәү төзергә карар кылына, һәм Иван Васильевич тырышлыгы белән храмга шактый акча җыела.

Бервакыт нәкъ менә Троица чиркәвендә сабый Иван Шишкинны чукындырганнар дип уйлаганнар, ләкин бу яңа, таш чиркәүдә булмагандыр – ул вакытка аны әле төзеп бетермәгәннәр. Бәлки, йола иске, агачтан салынганында башкарылгандыр? Яки туган йорттан ике адымда гына урнашкан Спас соборында уздырылгандыр?

Иске Алабуга зираты территориясе сакланган, тимер капка – Надежда Дурова һәйкәле артында ук. Әмма ак таштан салынган собор урынында хәрабәләр генә: храмны узган гасырның утызынчы елларында шартлатканнар. Җимерекләр янында басып торганнан соң, Иван Васильевич Шишкин каберенә баш ияргә бер минут вакыт табыгыз – ватык кабер ташлары арасында исән калган истәлек хачын бик җиңел табарсыз.

Иван Васильевич 1877 елда бакыйлыкка күчә. Ул вакытка «икенче Брюллов» кына түгел, бәлки аңардан да данлырак пейзаж остасына әйләнгән улы өчен сөенергә өлгерә әле ул. Үзенең кешеләрдән читләшкән «Неудачник Ваничка»сының зур рәссам булып танылуын улының, Сәнгать академиясен тәмамлап һәм «Кукко» картинасы өчен Зур алтын медаль алып, 1861 елда туган ягына әйләнеп кайтуыннан соң аңлый. Бу инде бөтенләй башка Иван Шишкин була. Ачык күңелле, үз көченә ышанган, кызыклы әңгәмәдәш. Тик ул барыбер, үзеннән башка беркем дә күрмәячәк матурлыкны эзләп табу һәм әсәрләрендә мәңгеләштерү өчен, Алабуганың тирә-ягын дистәләрчә чакрымлап урарга әзер булган шул ук Иван булып кала.

ЛЕКАРЕВО ЯНЫНДАГЫ «АРЫШ БАСУЫ»

«...Пейзажчы – чын рәссам, ул тирәнрәк, ихласрак тоя, – дип язып куячак бервакыт рәссам көндәлегенә. – Табигать һәрвакыт яңа... һәм һәрвакыт үзенең бетмәс-төкәнмәс бүләкләрен бирергә әзер - без аны тормыш дип атыйбыз. Табигатьтән яхшырак нәрсә булырга мөмкин...» Шишкин бервакыт Осокин белән киңәшкә еллар узгач җавап биргән кебек бу: «Мин ышанам, – дип язган өлкән иптәше Иванга, – сез рәсем ясауда бик күп нәрсәгә ирешкәнсездер, ләкин сез ландшафтларга булган һәвәслегегезне үзгәртәсез, ә бу яхшы. Әмма үзегез дә яхшылап уйлагыз, нәрсә отышлырак соң...»

Бернигә яраксыз киңәш, һәрхәлдә, Шишкин өчен. Барыннан да бигрәк, эшкә керешкәндә ул нәрсәнең отышлырак булуы турында түгел, бәлки, иҗат мәгънәсе турында уйлана. Көндәлегенә: «Рәссам, һәммә нәрсә бертуктаусыз хәрәкәтләнә һәм үзгәрә торган табигатьне күчереп язганда, аның бер мизгеленнән артыгын тотып ала алмый», – дип яза. Һәм һәрвакыт аны – бу кабатланмас мизгелне табарга омтыла. Инде һәр сукмагы, һәр инеше, урмандагы һәр аланы күптән өйрәнелгән кебек тоелган Алабугасына да ешрак кайтырга тырыша.

Ватанына кылган бу сәфәрләреннән соң һәрвакыт диярлек кечкенә генә могҗиза була. Мәсәлән, 1877 елда туган ягына кайтып килгәч, бер елдан соң, Мәскәүдәге күргәзмәдә ул Алабуга янындагы Лекарево авылы янында ясалган этюдлар нигезендә язылган атаклы «Арыш басуы» картинасын тәкъдим итә. Полотноны шунда ук үз галереясы өчен Павел Третьяков сатып ала...

ВАСЫЯТЬ БУЛАРАК – «КОРАБ УРМАНЫ»

Алабуга пейзажлары аны гомеренең ахырында да илһамландыра. 1895 елда ул «Алабуга янындагы Чулман»ны яза, ә өч елдан соң «Кораб урманы» туа, аны Шишкинның илебез сәнгатендәге ярты гасырлык иҗат юлының искиткеч нәтиҗәсе дип атыйлар. Картина эскизында оста «Алабуга янындагы Афанас кораб урманы» дигән язу калдыра.

Полотноны Санкт-Петербургта күчмә рәссамнар күргәзмәсендә тәкъдим итәләр, һәм Иван Иванович иҗатташларының сокланулы бәяләмәләрен дә ишетә. «Картина «яңгырый» башлады, нота көчле, искиткеч – котлыйм, мин генә түгел, барысы да соклана – афәрин», – дип, уртак фикерне белдерә рәссам Савицкий.

Шушы триумфтан соң ике атна үткәч, Шишкин бакыйлыкка күчә. «Ул бик шәп кеше иде. Карап торышка – кырыс, асылда исә, бик юашигелекле. Тышкы кыяфәте белән – волость старшинасы, асылда исә – искиткеч нәзакәтле рәссам», – дип язалар бу турыда «Неделя» газетасында.

Ак таш собор урынында хәзер инде хәрабәләр генә: гыйбадәтханәне узган гасырның утызынчы елларында шартлатталар.

Алабугада рәссам һәйкәле.

«МИН МАКТАУГА МОХТАҖ ТҮГЕЛ...»

Руфия Фазылова

Татарстанның халык артисты, нәфис сүз остасы Рәшит Сабиров редакциябезгә ап-ак күлмәктән килеп керде. Һәм, уенын-чынын бергә кушып, сөйләп китте:
– Сезнең янга гына шулай ак күлмәктән килдем дип уйладыгызмы? Ялгышасыз, мин гел шулай йөрим... Ирексездән елмаештык, чынлап та, кияү егете диярсең!
– Рәшит абый, бер дә картаймыйсыз, – дибез. Ә ул карыша:
– Ю-у-ук, кызлар, картаям. Кайчакта көзгегә карыйм да үземне танымыйм...
Әйе, бүгенге әңгәмәдәшебез сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел, иркенләп утырыгыз: кызык фикерләр ишетерсез.

– Рәшит абый, сезгә 6 июль көнне 70 яшь тулды бит. Бу көнне кайда, ничек үткәрдегез?

– Беренчедән матбугат чараларына, радио-телевидениегә, журналистларга зур рәхмәт әйтәсем килә: бу көннәрдә миңа карата игътибар зур булды. Югыйсә берсенә дә әйтмәдем дә, сорамадым да.

Туган көнгә килгәндә, хәзер зурдан кубып юбилей дип йөрү көлке дә. Җитмеш яшь инде ул шатлык түгел. 6 июль көнне туган авылымда – Яшел Үзән районының Бәчек авылында булдым. Туган апа керде, тәмләп чәй эчтек. Күп котлаулар кабул иттем, шуның берсе турында сөйлим әле. Элек безнең авылда колхоз рәисе булып эшләгән Булат Камалов шалтырата: «Банкетың кайда була, кая килим?» – ди. Без бик дуслар идек. «Бәчек ресторанында үткәрәм. Бер генә

Фото: Лилиана Вәлитова

кеше чакырулы: туганнан туган Зәфүнә апа белән генә үткәрәм. Банкет башланды инде». Аннан көлештек. Ихластан әйтәм: халыкны җыеп, үземне мактаттырып утырасым килми. Әле аны чын күңелдән әйтәләрме, анысы да бар. Мин инде хәзер моңа мохтаҗ түгел: яраткан кеше яратты, яратмаганы юк. Берсенә дә үпкәләмим. Үз анасын яратмаган кешеләр дә бар бу дөньяда, ник әле мине бөтен кеше яратырга тиеш? Андый хәлнең булуы мөмкин түгел!

Шулай да Яшел Үзән районы админстрациясеннән чыктылар, матур гына юбилей кичәсе үткәрергә тәкъдим иттеләр. Район башлыгы Михаил Павлович Афанасьев белән дә сөйләштек, кичәне көзгә калдырырга кирәк дип уйлаштык. Җәй көне халыкны җыю авыр ул. Бергә эшләгән артистларны чакырып, матур гына бер бәйрәм үткәрергә язсын.

– Бала чагыгыз турында сөйләшик әле, Рәшит абый. Ишле гаиләдә үскәнсез. Андый йортта гадәттә балалар бер-берсен тәрбияли. Сездә дә шулай булдымы?

– Шулайрак. Балачак җиңел булды дип әйтә алмыйм, юклык чорында үстек. Тик бик бәхетле чак иде ул. Безнең гаилә туры сүзле, гадел, эшчән булуы белән дан тота. Мин – төпчек малай. Аның уңай ягы да, тискәре яклары да бар. Шунысын тәгаен әйтә алам: абыйларым белән кечкенәдән горурландым, алар минем яклаучыларым булды. «Берәрсе бармак белән чиертсә дә, безгә әйт», – дияләр иде. Дөрес, миңа авылда сугу түгел, авыр сүз әйтүче дә булмады, чөнки үз гомеремдә кешегә бер начарлык эшләмәдем. Туганнарым турында сөйләгәндә, олы абыем Хәмис турында искә аласым килә. Аңа авылда беренче булып мотоцикл алып бирделәр. Олы гына гәүдәле, чын ир-егет иде абый. Аннан курыктылар да, сокландылар да. Заманында таштан ике йорт салды. Мин көрәк тә саплый белмим, ә абый җир җимертеп яшәде: гомере буе шофер булып эшләде, өйләнде, гаиләсе булды.

Балачак дисең бит. Ярлы яшәдек без. Яңа киемне башта Хәмис абый кия. Әни әйтә торган иде: «Абыегыз кызлар белән йөри башлады». Аннан кием Камил абыйга кала, шуннан аны Фазыл абый кия. Чират буенча Фәрит кия һәм, миңа килеп җиткәндә, теге кием кырык ямаулыга әйләнгән була. Ачасыр урта мәктәбен тәмамлагач, Казан театр училищесына чыгып киттем. Менә анда баргач, өс-башымның ни дәрәҗәдә начар икәнен тәгаен аңладым.

– Сез әти-әниегезне зур хөрмәт белән искә аласыз. Аеруча әниегез турында ятап сөйлисез.

– Шулай булмыйча, алар безгә гомер биргән кешеләр. Безнең әти бик гадел булды, кешегә авыр сүз әйтмәде. 1901 елгы иде ул, 88 яшенә кадәр яшәде. Сугыш вакытында әти яшерен почта ташый. Аннан соң аны авыл советы рәисе итеп куялар. Олыгайган көндә кибеттә дә эшләде. Әле картаеп беткәч тә колхозның алма бакчасында каравылчы булып торды. Һәм, беләсеңме, ник шуннан өйгә ике алма алып кайтсын! Әйтәм бит, бик гадел иде.

Әти авыл советы рәисе булып эшләгәндә, беренче хатыны үлеп китә. Әни өч бала өстенә килә: Суфия апа, Сания апа, Ситдыйк абый. Аннары үзе дә биш ул, бер кыз таба. Әнә шулай әти белән әни тугыз баланы аякка бастыралар.

Әни гел бер хәлне сөйли иде: өй салкын, утын юк. Әле бит казан асып, ашарына да пешерергә кирәк, өй тулы бала-чага. Әни күрше апа белән төнлә колхоздан утын урлап кайта. Әти күрмәгәндә шул утынны идән астына төшерәләр һәм күрше апа белән шунда кисәләр дә. Шулвакыт әти кайтып керә һәм урланган утынны күрә. «Нәрсә, мине төрмәгә утыртасың киләме? Кайдан алдың, шунда илтеп куегыз. Хәзер үк!» – дип әйтә. Әни күрше апа белән төнлә утынны кире илтә. Авылда иң соңгы булып, 1965 елда гына абзардан салам түбәне төшереп, такта белән япты. Әтинең кушаматы «куркак» иде. Әйе, куркырсың да, аның заманы шундый булган.

Әни бик көчле характерлы, батыр хатын иде. Шулай булмаса, өч балалы әтигә кияүгә дә чыкмас иде. Аның чисталыгы! Әгәр әнинең юган керләрен күрсәң, шаккатасың. Алар көлеп тора иде. Бу миңа да күчкән. Бәчектәге өем, Казандагы фатирым да чипчиста. Бу, бәлки, авырудыр да. Соңгы ун елда әнием Паркинсон чиреннән интекте, бик кадерләп карап, аны соңгы юлга озаттым. Һәм моның белән горурланам да, сөенәм дә: әнине бер көн ялгыз калдырмадым.

– Гомерем буе сәхнәдә...

– Әни көчле характерлы, батыр хатын иде.

– 35 яшьтә Татарстанның халык артисты исемен алгансыз. Ул заманда бу бик зур дәрәҗә булган дип аңлыйм...

– Театр училищесының актерлык төркемендә 25 кеше укыдык. Бүгенге көндә без ике генә кеше профессиональ сәхнәдә эшлибез. Аның берсе – Гүзәл Мостафина, икенчесе – мин. Без аның белән партия үткәргән хөкүмәт концертларын күп алып бардык. Мин – татар телендә, Гүзәл рус телендә эшләде. Безнең икебезгә дә халык артисты исемен бирделәр. Шөкер, хезмәтемне гел бәяләделәр: 29 яшемдә Татарстанның атказанган артисты исемен алдым. Ә ул вакытта исемне бик саран бирәләр иде. Равил Шәрәфиев әйтә иде: «Рәшит, Камал театрының атаклы артистлары да халык артисты исеме ала алмый, ә син бәхетле». Әлбәттә, бу исемнәрне хөкүмәт концертлары алып барганга гына бирмәделәр. Училищены тәмамлауга, Әлфия апа Авзалова төркемендә эшли башладым. Ә ул – дүртәр айлык гастрольләр... СССРның кайсы гына почмагында булмадык.

– Әлфия апа Авзалова турында сүз чыккач, сорамый кала алмыйм: легендар җырчы белән эшләргә ни дәрәҗәдә җиңел һәм авыр булды? «Уф, туйдым» дигән чакларны хәтерлисезме?

– Әйтү түгел, уйлаган да булмады! Киресенчә, гомерем буе аңа рәхмәтле булдым, ул мине кеше итте, хәтта сөйләргә өйрәтте. Әлфия апа белән егерме елдан артык эшләдек. Иң беренче тунны миңа Әлфия апа бүләк итте. Эшли генә башлаган чаклар. Гастрольләргә чыккач, сөт тракторлары, ат чаналарында барырга туры килә. Салкын үзәккә үтә. Казанга кайткач, ул мине бер складка алып керде һәм ак тун алып бирде. Ул тун милиционерлар өчен тегелгән булган икән, без аны коңгырт төскә буядык. Шулай итеп, мин җылындым.

– Кырык елдан артык Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә хезмәт иткәнсез. Иң истә калган сәфәр дип кайсын әйтә аласыз?

– Алай нинди дә гайре хәлләр бик истә калмаган. Алай да Әлфия апа концертында бер-ике тапкыр ут сүнде. Микрофонсыз чыгыш ясаган чаклар булды.

– Рәшит абый, бүгенге эстрадага мөнәсәбәтегез? Сезнеңчә, ул алга киттеме, әллә киресенчә, артта калдымы?

– Элек татар эстрадасы бик югары дәрәҗәдә иде, хәзер төште, дисәм, бу дөреслеккә туры килмәячәк. Һәр чорның үз «авыруы» һәм һәр чирнең үз докторы була. Татарлар Россия буенча гына түгел, бөтен дөньяга таралган һәм алар туган телендә җыр тыңларга зар-интизар булып көтеп тора. Алар өчен берәр артистны күрү, татар җырын тыңлау – зур бәхет, татлы ризык ашаган кебек. Шулай булгач йөрсеннәр, эшләсеннәр. Кемнең начар, кемнең яхшы җырчы икәнен вакыт үзе күрсәтә ул.

– Күптән түгел редакциябезгә язучы Камил Кәримов килде. «Зәвыклы юмор белән тамак туйдырырга мөмкин түгел. Тамашачының зәвыгы бозылды, аны көлдерү өчен юмористлар «түбән» темаларны сайларга мәҗбүр», – дип әйтте. Сез бу фикер белән килешәсезме?

– Аңа халык гаепле түгел, моңа без, ягъни сәнгать юлындагы кешеләр гаепле. Алар җи-

– Бик күп атаклы артистлар белән эшләргә туры килде.

Яшел Үзән районы башлыгы Михаил Афанасьев белән.

җел юморга өстенлек бирә, чөнки фәлсәфи, акыллы әйберләрне эзләргә кирәк. Ә чүпчар аяк астында гына, җиңел бит. Без үзебез ул – халыкны бозып йөрүчеләр. Менә Фаил Шәфигуллинның «Сагынырлар әле безне таулар» китабын алсаң, андагы матур хикәяләр... Менә ул зәвыклы юмор, аны теләсә кайсы аудитория алдында сөйләргә мөмкин. Халык аны яратып тыңлаячак һәм тыңлый да. Туфан Миңнуллинны алырга мөмкин, менә дигән юмор. Зөлфәт Хәким хикәяләрен карагыз, бүген аның кебек язучы юк, минемчә. Кыскасы, татарда юмор бар, тик аларны белүче генә аз. Ә бүген юмор сөйләүчеләр кемнәндер махсус яздыртып, үзләреннән өстәп, ыштан бөрмәләре турында сөйләп йөри. Безнең халык күпне күргән, ул бик тәртипле, без, артистлар, үзебез тәртипсез.

– Сезнең репертуарда нинди генә шагыйрь, язучыларның шигырьләре, хикәяләре юк. Ә үзегез аеруча кемне яратасыз?

– Икенче һөнәрем буенча укытучы мин, КДУның татар филологиясе бүлеген тәмамладым, алты ел читтән торып укыдым. Шулай булгач, татар әдәбиятын яхшы беләм дип әйтә алам.

Аеруча кемне яратасың дигән сорауга... әле генә санап киттем инде: Фаил Шәфигуллин, Туфан Миңнуллин, Зөлфәт Хәкимнәр... Башкортстан ягыннан булган язучы, шагыйрьләрнең дә әсәрләрен яратып сөйлим. Яттан бик күп өзекләр, шигырьләр беләм. Мин аларны бик тиз ятлыйм, хәзер дә шулай.

– Кеше яши-яши үткәнгә карап нәтиҗәләр ясый. Нәрсәнедер ялгыш эшләгәнмен дип тә уйлый. Сездә андый уйлар тумыймы?

– Тормышта үкенерлек әйберләр бар инде ул. Тик аларны хәзер үзгәртеп булмый... Вакытында гаилә корырга кирәк дип саныйм. Дөресен әйтим, гаиләм булмаганга хәзер үкенәм. Ир кешегә хатыны, балалары булу бик мөһим. Балалар – ул синең киләчәгең, картлыкка өметең. Мин балаларны бик яратам, хәтта автобуста күргән сабыйларга да елмаеп китәм. Әнисе белән урамнан узган балаларга да еш кына сүз катам, аеруча татарча сөйләшкәннәрен ишетсәм, мактыйм. Шулай бер малайга кәләпүш тә бүләк иттем. Кәләпүш дигәннән, шушы милли баш киемен яратам. Хәлемнән килсә, республика җитәкчеләрен дә түбәтәйдән йөртер идем.

– Редакциягә Рәшит Сабиров үзе килеп, бер мәзәк тә сөйләмәсә, әңгәмә тулы булмаячак...

– Кыска мәзәкләр бик юк минем, гадәттә, озын юмористик хикәяләр сөйлим. Кайберләрен үзем дә уйлап чыгарам. Менә шуларның берсе искә төште әле: җырчы Фердинанд Фәтхи гайбәт чыгарган. Янәсе, мин мәрхүм Усман Әлмиевне төштә күргәнмен икән. Усман абыйдан сорыйм икән:

– Я, теге дөньяда ничек хәлләр? Анданиләр белән шөгыльләнәсез?

– И, Рәшит, монда шундый рәхәт. Исән чактагы кебек концертлар да куябыз, бенефислар үткәрәбез. Монда, Рәшит, синең дә афишаң эленеп тора. Бер-ике атнадан син дә монда киләсең икән...

Фердинанд Фәтхине күреп әйттем: андый төш күргәнем юк, әле мин Усман Әлмиев янына тиз генә барырга җыенмыйм, кешегә әллә ниләр сөйләп йөрмә, дидем...

– Рәшит абый, гомер көзенә егетләр кебек кереп киләсез. Моның сере нәрсәдә? Спорт белән дуслык бармы? Туклануга игътибар бирәсезме?

– Ялгыз кешенең тукलануы нәрсә бар, шуны ашыйм дип атала. Иркәләп торучы юк. Спорт белән шөгыльләнүгә килгәндә, иртән, юынганчы ук, «Тәртип» радиосын ачып куям. Анда иртән күнегүләр эшләтәләр. Аларга кушылып, мин дә физкультура ясыйм. Өйдә массаж ясый торган җайланмам бар, аны кулланам. Һәм көн саен шактый гына җәяү йөрим. Авылга кайткач та ындыр артларын урап кайтам. Сәламәтлекне кайгыртырга кирәк. Хәрәкәттә – бәрәкәт! Борынгылар белми әйтмәгән.

Равил абый Шәрәфиев белән аралашам һәм аны үзем өчен үрнәк итеп куям. Ул хәзер дә спорт белән шөгыльләнә, йөзә, кышын рәхәтләнеп чаңгыда йөри. Менә ул һаман да егетләр кебек. Барыбызга да шулай картаерга язсын!

Бөек Җиңүгә 80 ел тулу уңаеннан, «Кырык беренче ел балалары» рубрикасын дәвам итәбез. Бу юлы Бөек Ватан сугышы елларында өлкәннәр белән бергә тормыш арбасын җигелеп тарткан гади бер авыл баласының язмышын бәян итәбез.

Фото: Лилиана Вәлитова

«ТУГАНЛЫК ҖЕПЛӘРЕ НЫК БУЛСА...»

Руфия Фазылова

Бөек Ватан сугышы башланганда Минһаҗ Шәрәфиевкә унике яшь, дөресрәге, унөч тулырга ике атна калган була. Әгерҗе районының кечкенә генә Касай авылында әти-әнисе белән яшәүче малай 22 июнь иртәсен бик яхшы хәтерли. Йокысыннан ул әнисенең елаган тавышына уяна. Тәрәзәгә күз салса, урам тулы халык. Башына килгән беренче уе: берәрсе үлгән, ахры. Ләкин бик тиздән Минһаҗ «сугыш» дигән куркыныч сүзне ишетә. Әмма әле ул чакта үсмер малай олы фаҗигане бөтен асылын аңлап бетерми...

ӘТИЛЕ БАЛАЧАК

– Урамга чыктым, – дип, хатирәләре белән уртаклашты Минһаҗ бабай. – Кешеләр җыелып тора, мин дә алар янына бардым. «И, тормышлар әйбәтләнә генә башлаганда, тагын кара кайгы», – дип сөйләшәләр. Ир-атларның күбесе эштә, урамда безнең кебек үсмер малайлар да хатын-кызлар. Шул ук көнне билгеле булды: яше җиткән һәр ир-атны хәрби комиссариатка чакыралар, сугышка озатачаклар икән...

Минһаҗ абый – гаиләдә төпчек бала. Абыйсы Кашшаф, ике апасы – Сәйдә белән Саймә ышыгында иркәләнеп үскән малай ул. Унике яшенә кадәр. Аннан соң кисәк кенә олыгаерга туры килә аңа – колхозның бөтен эше аларга, ягъни үсмер егетләргә кала. Ләкин ул яшьтәшләренә караганда бәхетлерәк була, чөнки әтисе Шәрәфине сугышка алмыйлар. Инде алтмыш яше тулган була аңа. Тик барыбер алар гаиләсенә дә илдә барган афәт җиле кагыла.

– Кашшаф абыйны 1942 елның язында сугышка алдылар, – дип дәвам итте Минһаҗ абый. – Әниләргә аның бердәнбер хаты килгән. «Мәскәү астында бик каты сугышта булдык, әле алгы сызыктан чыктык. Сугышлар тизрәк туктасын да, Җиңү белән туган якларга әйләнеп кайтсак иде. Барыгызны да бик сагынам. Минекеләрне ташламагыз», – дип язган. Шуның белән шул. Абый сугышка киткәнче өйләнгән, ике кызы туган иде. Берсе өч яшьлек, берсе әле тәпи дә китмәгән кызларын калдырып киткәндә үзәкләре өзелгәндер. Хәер, ул хәсрәт бездә генә түгел, ирләрен кан-яшь түгеп озаткан йөкле хатын-кызлар авылда байтак булды. Кашшаф абыебыз хәзергә көнгә кадәр хәбәрсез югалганнар исемлегендә йөри. Балалар эзләтеп тә карады, һич таба алмыйлар. Әллә фамилияләрдә хата киткән, аптыраш...

Авыр булса да, Минһаҗ абый сугыш елларын зарланып сөйләми. Беренчедән, әти-әнисе янәшәсендә булган. Сыйныфташлары, күрше малайлары «әти» дип әйтергә тилмергәндә, ул бу бәхеттән мәхрүм ителми. Икенчедән, маллар асраганга күрә, табыннарыннан ризык өзелми. Әтисе белән, икесенә ике ат җигеп, көнне төнгә ялгап колхоз басуында эшләсәләр дә, ул барыбер ятим үсми.

– Авылда бөтен сөйләшү сугыш турында иде, – дип, хәтерен яңартты Минһаҗ абый. – Кемне генә очратсаң да, фронттагы улы, ире турында сөйли. Безнең дә өйдә гел шул сүз. Бигрәк тә әни өзгәләнде – абыйдан хәбәр көтте. Авылга берәрсенең яраланып кайтканын ишетсә: «Минһаҗ, улым, бар сорашып кайт әле, алай-болай абыеңны очратмадымы икән? Адәм баласы энә түгел, бер-бер хәбәре булырга тиеш бит...» Әни үлгәнче абыйны көтте. Абый безнең бик мөстәкыйль, ут булган. Мин тугач, әти-әнигә әйтеп тормыйча, авыл советына да үзе киткән. Шуннан кайткан да: «Әти, бәбәйне яздырып кайттым – Фаиз исеме куштым», – дигән. Ә этинең миңа Минһаҗ исеме кушасы килгән. Ни өчен дигәндә, аларның унике яшендә Минһаҗ исемле уллары үлгән булган. Әнә шуның истәлегенә миңа бу исемне бирергә уйлаган эти. Абый, моны ишеткәч: «Соң, ярар, хәзер барам да Минһаҗ дип төзәттерәм, аның нәрсәсе бар», – дип әйткән. Шулай итеп, миңа эти теләгән исемне кушканнар. Төпчек булгангадыр, абый мине бик ярата иде, күтәреп кенә йөртте. Яшь аермасы – 19 ел. Сугыш чыкмаган булса, гел шулай тату яшәгән булыр идек тә бит. Шөкер, туганнар белән гомергә тату яшәдек, әни белән эти шулай өйрәтте. Үзләре дә үрнәк гаилә иделәр – әниебез Латыйфа 73 яшендә, этиебез Шәрәфи 88 яшендә бакыйлыкка күчте.

Туганлык җепләре, дигәннән. Абыйсы Кашшаф сугыш башланганда Актаныш районының Пучы авылында партком секретаре булып эшли. Алда әйтелгәнчә, гаиләсе була. Уллары сугышка киткәч, Шәрәфи карт, ат җигеп,

Гаиләнең бергә җыелган вакыты.

Пучыга чыгып китә. «Килен, әйдә җыеныгыз. Чит җирдә яшь балалар белән үзең генә интегеп ятма. Авылда сезгә зур булмаган йорт сатып алдым. Бергә җиңелрәк булыр, балаларны үстерешергә дә ярдәм итәрбез», – дип әйтә. Һәм сүзендә тора да: Кашшаф улыннан туган Клара, Флера исемле оныкларына үзе үлгәнче күз-колак булып, ярдәм итеп яши.

«ТӘРБИЯДӘ ЯШИМ...»

Минһаҗ абыйга июнь азагында 96 яшь тулды. Бүген ул кызы Дамирә тәрбиясендә, бик кадерле әти, дәү әти булып гомер кичерә. Әйе, бернәрсә генә күңелен борчып тора – туган авылын ташлап китәргә туры килгән аңа. Моның сәбәбен Дамирә апа болай аңлатты:

– Әти белән әни җитмеш бер ел бергә гомер итте. Әни бакыйлыкка күчкәч, әти бик боегып калды. Җитмәсә, авылда энекәш тә мәрхүм булды. Әти янына чиратлашып кайтып йөрдек, аннары берәм-берәм дә үзебезгә алып карадык. Өч ел элек һич уйламаган җирдән җәмәгатем дә вафат булды. Бер-беребезгә иптәш булырбыз, дип, әтине Олы Әтнәгә алып килдек. Бу йортны ирем белән пенсиягә чыккач, рәхәтләнеп яшәрбез, дип салган идек. Нишлисең, күңел меңне сагышлар, Ходай берне багышлар, диләр.

– Бабай туган ягын бик сагынамы?

– Баштарак сагынды инде, хәзер ияләнде кебек. Апрель азагында әтине авылга алып кайтып килдек, Әгерҗе бик ерак бит, еш кайтып булмый. Әле барыбер җәй беткәнче бер алып кайтырсыз, дип утыра.

– Сезнең гаилә тарихын тыңладым да, Шәрәфи бабагыз тырыш та, кешелекле дә булган дигән фикер туды, – дим.

– Әйе, искиткеч кеше иде. Берәр төрле эш коралы кирәк булса да, Шәрәфи бабайга киләләр иде. Ә безгә – оныкларга карата булган мөнәсәбәтен сөйләп аңлата торган түгел. Әбекәй дә шулай иде. Беребезне дә сыйламыйча чыгармыйлар иде. Сугышта хәбәрсез югалган Кашшаф улыннан туган Клара, Флера апаларны да бик якын иттеләр, килен, кызга бүленеш юк иде.

Алма алмагачыннан ерак төшми шул: әнә бит, Минһаҗ абый үзе дә гомере буена балалар, оныклар дип яшәгән. Җәмәгате Маһирә апа белән алты бала – өч ул, өч кыз үстергән. Ни аяныч, төпчек улы берничә ел элек мәрхүм булган.

Күптән түгел бабайның туган көне гөрләп узган. Балалар, оныклар, егермедән артык кеше җыелган. Минһаҗ бабай түрдә елмаеп, бик канәгать булып утырган. Гомумән, янында күбрәк балалар булган саен сөенә икән ул. Безгә дә шул турыда каткат әйтте:

– Балаларга бик рәхмәт, бабай дип үлеп торалар. Барысы да тәртипле булды. Араларында әллә нинди дәрәҗәле һөнәр ияләре дә бар. Бөтен оник, оныкчыклар бергә җыелган чакта 70 кешегә тулабыз. Бер генә теләк – барысы да исән-сау булсын. Нәселебез бөтен Татарстан, Россия буйлап таралган. Горурлык та, олы бәхет тә!

Шулай дигәндә, Минһаҗ абыйның күзләре яшьләнде. Бәхет шул, зур бәхет... Сөйкемле бабайга алга таба да шулай куанып яшәргә язсын. Бу яшькә җиткәч, саулыкка туеп торгач, Аллаһы Тәгалә йөзне дә тутырырга насыйп итсен!

акыллы гамәлләр

мәңгелек кыйммәтләр /

игелекле эшләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Беренче татар газетасы **кайчан** чыккан

Матбугат йорты китап басу традицияләрен **ничек** саклый

Татар әсирләренең җырлары **кайчан** туган якка кайткан

Мәрҗани йорты **ничек** сакланган

Фотолар шәхси архивлардан алынды

ТӨНЬЯКТАН ТАРАЛГАН «НУР»

Айдар Шәйхин

Беренче татар газетасы – «Нур»ның 120 еллыгы уңае белән, аның тарихи сәхифәләрен барлап, язмыш битләренә күз салыйк әле.

«НУР»СЫЗ ГАСЫРЛАР

Татарлар үз телендә беренче газета чыгарырга рөхсәт алганда, Россия империясендә 75 төрле телдә 1002 исемдә газета-журнал дөнья күрергә өлгерә. Төрле сәбәпләр аркасында, патша хөкүмәте дә, губерна идарәләре дә татарча матбугат оештырырга теләүчеләрнең гарызнамәләрен кире кага килгән. Ә бит инициатива күрсәтүчеләр күп булган! 1863 елда Казанда бөек мәгърифәтче Каюм Насыйри белән матбагачы, ташбасма хуҗасы Мөхәммәтгали Яхин хәрби губернатордан «Таң йолдызы» газетасын нәшер итәргә рөхсәт сорыйлар. Үтенеч кире кагыла, әмма газетага альтернатива буларак, Насыйриның календарьлары барлыкка килә. Санкт-Петербургта татарча газета чыгару хыялы белән галим, тарихчы һәм тел белгече Хөсәен Фәезханов та янып йөри. Ләкин аның да хыялы чынга ашмый, Габделхәер Котлыяров белән Хәбибулла Бикбулатовның «Дәфтәре мөҗдәвәр» («Яңалыклар дәфтәре») дигән газета чыгару тәкъдиме дә, 1885 елда Сәхипгәрәй Әхмәровның проекты да, Габдрахман Ильяси, Ольга Лебедева идеяләре, 1903 елда Әхмәтһади Максуди белән Ибраһим Терегуловның гозере дә, Камил Мотыйгый белән Габдулла Тукайның гаризалары да кире кагыла. Кыскасы, төрки-мөселман халыкларының үзаңы үсүдән һәм сәяси хәрәкәте көчәюдән куркучыларның позицияләре озак еллар какшамас кала бирә.

Әмма 1905 ел Россиягә бихисап үзгәрешләр алып килә. Беренче рус инкыйлабы басымы астында патша хөкүмәте үз халкына төрле ирекләр вәгъдә итәргә мәҗбүр була, парламент барлыкка килә, сүз, вөҗдан, җыелышлар ирекле игълан ителә, дини чикләүләр

кими. Татар мәдәнияте өчен иң кадерле хокукларның берсе исә вакытлы матбугат оештыру иреге була.

КАСЫЙМЛЫ АХУННЫҢ ХЫЯЛЫ

«Нур»га рөхсәт алуга ирешкән шәхес, дин әһеле һәм җәмәгать эшлеклесе Гатаулла хәзрәт Баязитов 1847 елда Рязань губернасы Касыйм өязенең Төмәнсу авылында Баязит мулла Шәхсеваров гаиләсендә туа. Туган якларында, Казан губернасындагы атаклы Кышкар мәдрәсәсендә укый, имам-хатыйб һәм мөдәррис вазыйфаларына билгеләнә, указ ала. 1871 елдан аны Санкт-Петербургка чакыралар һәм башкаладагы Касыйм татарларының мәхәлләсенә имам итеп куялар.

Мәхәлләнең үз мәчете дә булмый, гыйбадәт кылыр һәм вәгазьләнер өчен мөселманнар Баязитовның фатирына, ә бәйрәм намазларына арендалаган урыннарга җыела. Гатаулла хәзрәт яшәгән «Мойка, 22» адресы империя елларында Питердагы татарлар өчен кадерле урынга әверелә. Гыйлеме, телләр белүе, төрле дәрәҗәдәге кешеләр белән уртак тел таба алуы сәбәпле, Гатаулла хәзрәт озакламый хәрби ахун вазыйфасын да башкарырга тотына. Петербург гарнизонында, аерым Кырым татарлары эскадронында, Балтыйк флотында хезмәт иткән мөселман хәрбиләре өчен имам була ул.

Хәзрәтнең дәүләт каршында дәрәҗәсен күтәргән тагын бер хезмәте – Тышкы эшләр министрлыгында тәрҗемәче (тылмач-драгоман) һәм министрлыкның Азия департаментында көнчыгыш телләрен өйрәтү бүлегендә укытучы булып эшләве. Бу барлык хезмәтләре өчен ул императорның төрле бүләкләренә дә лаек була.

1905 ЕЛНЫҢ 2 СЕНТЯБРЕНДӘ САНКТ-ПЕТЕРБУРГ ШӘҺӘРЕНДӘ «ИЛЬЯС МИРЗА БОРАГАНСКИЙ ҺӘМ ШИРКӘТ» БАСМАХАНӘСЕНДӘ «НУР» ИСЕМЛЕ ТАТАР ГАЗЕТАСЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ САНЫ БАСЫЛЫП ЧЫГА. АНЫ БАСТЫРЫРГА РӨХСӘТ ШУЛ УК ЕЛНЫҢ 4 АПРЕЛЕНДӘ БИРЕЛГӘН БУЛА.

Рухани, мөгаллим, тәрҗемәче кеше әле китаплар һәм дәреслекләр дә яза, рус матбугатында мәкаләләре белән чыгыш ясый. Аның француз галиме Эрнест Ренан белән гыйльми бәхәскә керүе дә, ислам диненең асылын, аның техник прогресс заманында тоткан урынын, киләчәген күзаллаган китаплар язып бастыруы да киң җәмәгатьчелеккә мәгълүм. Шулай итеп, хәзрәт һәм түрәләр, һәм мөселманнар, һәм галимнәр арасында абруй казана.

Санкт-Петербург – империя мәркәзе генә түгел, иге-чиген колачлап булмаган зур дәүләтнең төрле халыклары һәм мәдәниятләре, дин һәм традицияләре бергә очраша торган урын да. Мөселманнар биредә шәһәр нигезләнгәннән бирле яшәгәннәр, аның мәдәни ландшафтында мөһим урын билгәннәр. Баязитовлар кебек гаиләләрнең үзләрен бу шәһәрнең чын гражданнары кебек хис итәсе килә. Шуңа да Гатаулла хәзрәт татар-мөселманнарның хокукларын, мәдәни һәм дини ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен матбугат ачарга омтыла.

Баязитов 1891 елда ук газета өчен көрәш башлый. Шул елның көзендә русчалы-татарчалы чыгарга тиешле «Һәфтә» («Атна») исемле газетага рөхсәт сорый. Ике елдан соң янә бер талпыныш: бу юлы «Чишмә» исемле газета чыгарырга нияте барлыкка килә.

Газетаның икенче редакторы Мөхәммәтсафа Баязитов.

Мойка елгасы яры, 22 – «Нур» редакциясе, 2 нче мәхәлләнең гыйбадәт бүлмәсе һәм Баязитовлар фатиры урнашкан йорт.

Петербургта беренче мәчеткә нигез салган көн. Уртада – Бохара әмире, янында Гатаулла Баязитов.

Тагын ике елдан өченче үтенеч: монысында русча һәм татарча чыгарга тиешле газетаның исеме – «Нур». Бу гариза да кире кагылгач, Гатаулла Баязитов газета чыгару ниятен 10 елга калдырып торырга мәҗбүр була.

ТӨНЬЯКТАН ТАРАЛГАН НУР

Инкыйлабка кадәрге татар матбугатында «Нур» кебек тотрыклы рәвештә чыгып килгән басмалар күп булмый. 1914 елга кадәр ул озак тәнәфесләрсез, аена уртача биш-алты тапкыр чыгып килә. Дөрес, соңгы елларында ешлыгы кими, айга бер тапкыр чыккан чаклары да була. Баштагы мәлдәге даимилеккә Гатаулла Баязитовның шәхси сыйфатлары бәрабәренә ирешелә.

Башка татар газеталарыннан аермалы буларак, «Нур»ның матди хәле сәүдәгәрләр яки химаячеләргә бәйле булмый. Гатаулла хәзрәт газетага үз акчаларын тота. Ике ел буена газетаны чыгарыр өчен ул үз кесәсеннән 8 мең сум сарыф итә. Хөкүмәт эшендә һәм дини вазыйфадагы кеше өчен бу бик зур чыгымнар, әлбәттә. Баязитовлар гаиләсе, матди һәм рухи көчләрен кызганмыйча, 310 санны нәшер итәргә өлгерә.

Газета битләрендә Фатыйх Кәрими, Гаяз Исхакый, Әхмәтһади Максуди, Риза Фәхретдин, Шәриф Камал, Гайсә Еникиев, Садри Максуди, Котлымөхәммәт Тәфкилев, Әбүсогыд Әхтәмов, Кашшаф Тәрҗемани, Кәбир Бәкер, Сәгыйть Сүнчәләй, Зыя Насрый, Мостафа Сабитов, Мөхәммәд Хәмиди кебек әдипләр, галимнәр, сәясәт һәм җәмәгать эшлеклеләренең мәкаләләре, шигырь һәм фельетоннары, хатлары басылып бара. Аңлашыла ки, Гатаулла хәзрәт Баязитовның үзе өчен дә «Нур» төп мөнбәргә әверелә. Мәгариф һәм мәгърифәт, төрки-татар теле, милләт, дин, руханиларның дәүләттә статусы һәм урыны, мөселман халыкларының язмышы, – боларның барысы турында уйланып, күпсанлы мәкаләләрен бастыра ул.

> «НУР»ДА, БЕРЕНЧЕЛӘРДӘН БУЛЫП, КАЗАН ТАТАРЛАРЫНЫҢ ТЕЛЕ ТУРЫНДА ДИСКУССИЯ КУЗГАЛА. БЕЗНЕҢ ӨЧЕН ӘДӘБИ ТЕЛГӘ ӘВЕРЕЛГӘН ШИВӘ НӘКЪ «НУР» БИТЛӘРЕНДӘ МАТБУГАТ ТЕЛЕ БУЛЫП ФОРМАЛАША.

Баязитов – консерваторлар лагереннан. Бер яктан бу парадоксаль күренеш: прогресс-тәрәккыятнең иң күренекле билгеләреннән саналган вакытлы матбугатны милләт өчен һичшиксез кирәкле нәрсә дип күзаллаган шәхеснең шул ук вакытта консерватив карашлары да сакланган. Шунысын да онытмыйк: «Нур»ны оештырган вакытта Гатаулла хәзрәткә 60 яшь тирәсе була. Ул – күпне күргән, гомере буе патша хакимиятендә, Тышкы эшләр министрлыгында эшләгән, ислам өммәтенә Россия империясенең йөрәгендә – Санкт-Петербургта хезмәт иткән шәхес. Ил һәм милләт киләчәген ул бергәләшеп эшләүдә, акыллы һәм нигезле, әмма сак адымнар ясауда күрә.

1911 елның апрелендә Гатаулла хәзрәтнең вафатыннан соң, редакторлык эшенә аның улы Мөхәммәтсафа Баязитов алына. Тарихта аның да үз исеме бар: 1915 елның 28 июленнән 1917 елның 22 мартына кадәр ул мөфти вазифасын башкара. Империя дәверенең соңгы мөфтие булудан тыш, Баязитов «Сыйрател мөстәкыйм», ягъни «Туры юл» исемле Бөтенроссия мөселман берлегенең оештыручы буларак та танылa.

«Нур»да рәсми хәбәрләр, хөкүмәт яңалыклары һәм карарларыннан тыш, Дәүләт думасы депутатларының нотыклары да чыга. «Нур» татар укучысын Россия һәм дөнья яңалыклары белән таныштыра, әдәби әсәрләргә, шигырьләргә, парчаларга урын бирә. Фәлсәфә, социология, сәясәт теориясе кебек гыйлемнәргә нисбәтле фәнни-популяр мәкаләләр дә урын таба.

Газетаның беренче саннары Санкт-Петербургта мөселман китапларын күпләп бастырган «Ильяс мирза Бораганский һәм ширкәт» электрик басмаханәсендә чыга. «Ширкәт» дигәннәре дә шул ук Гатаулла хәзрәт була. Кырым татары Ильяс мирза Петербургта 1880 нче еллардан башлап каллиграфия нигезләрен укыта, басмаханә ача. Бу типографиядә Госман Коръәненең факсимиль басмасы нәшер ителә.

Алга таба типография кайбер елларда «Нур» исеме белән атала башлый, «Гатаулла Баязитов басмаханәсе» төшенчәсе дә барлыкка килә. Һәрхәлдә, Бораганский үзе 1911 елдан соң татар телендә китаплар бастырудан читләшергә мәҗбүр була, 1917 елдан соң исә Петроградта башкортча газета нәшер итә, ә 1920 нче елларда басмаханәсе белән бергә Стәрлетамак шәһәренә күчеп итә.

Баязитовлар «Нур»ны, беренче татар газетасы һәм империя башкаласында чыккан матбугат чарасы булгангамы, югары сыйфатта, затлы кәгазьдә бастырырга омтылалар. Татар матбугаты елъязмачысы Исмәгыйль Рәмиев, беренче татар газетасының эшләгән тәнкыйтьләсә дә, полиграфия үзенчәлегенә,

аның сыйфатлы кәгазьдә басылуына игътибар итә. Газетаның дизайны да тора-бара матурая, камилләшә бара.

БЕРЕНЧЕ ГАЗЕТАНЫҢ ТӘҮГЕ САНЫ

120 ел элек дөнья күргән газета битләренә күзәтү ясыйк. Газетаның беренче номеры «Телеграф хәбәрләре» дигән рубрикадан башланып китә. Аның эчтәлегеннән «Нур»ның үз алдына зур максат куюы, төрки-татарларны бөтен дөньяның мөһим яңалыклары белән таныштырып барырга омтылуы аңлашыла. Мәсәлән, Портстмутта барган солых конференциясе яңалыклары. Гомумән, барлык яңалыклар да рус-япон сугышы нәтиҗәләренә, булачак солых килешүенә багышлана. Татар тормышына 1904–1905 елгы сугышның йогынтысы турында беләбез: ул әдәбиятта да тасвирлана, ә Порт-Артурны яклау вакыйгалары татар-башкорт халыкларында җырга әверелә. «Нур» мисалында без моннан 120 ел элек Казанда да, Питер белән Уфада да, татар яшәгән һәрбер шәһәрдә телдән төшмәгән сәяси сорауларның матбугатта яктыртыла башлавын күрәбез.

«Нур»да хәбәрләр бүлегендә Европа һәм Россия газеталарыннан алынган яңалыклар да китерелә. Мәсәлән, Токио хәлләре һәм солых турында сөйләшүләрдән канәгатьсезлек турында «Таймс»та чыккан мәкаләнең эчтәлеге бирелә. Ә Лондонда нәшер ителгән «Дейли телеграф» газетасы Микадоның (Япония императоры – **ред. иск.**) солых килешүен хупламавы Америка һәм Англиянең «Япунга мәхәббәт дустлыгы» сәбәпле булыр дип әйтә. Гомумән, газета битләреннән 1905 елда халыкара мөнәсәбәтләрдә кабул ителгән төшенчәләрне дә, төрле илләрнең сәяси корылышын һәм яңалыкларын да белергә була.

«Әхбар хәрбия», ягъни хәрби хәбәрләр рубрикасында барлык язмалар да рус-япон сугышының нәтиҗәләренә, тиз арада имзаланасы Портсмут солых килешүенә кагыла. Шуңа да монда хәрби хәрәкәтләр тасвирланмый, игътибар үзәгендә – дипломатия. Мәсәлән, Россиянең солых төзү өчен җаваплы вәкилләре Сергей Витте белән барон Роман Розенның Портсмут конференциясендә сөйләгән нотыкларына анализ ясала. Газета 2 сентябрьдә чыга, ә килешү 5се көнне игълан ителә. «Нур» иң актуаль яңалыкларны күзәтеп барган, димәк.

Икенче зур тема – төрек дөньясыннан килгән хәбәрләр турында. Истанбул яңалыкларында – янә сугыш афәтләре. Ул вакытта Госманлы империясенә кергән Йәмән җирләрендә фетнә чыгып, шуны бастырыр өчен җибәрелгән Фәез пашаның хәрәкәтләре турында хәбәрләр бирелә.

«Әхбар дахлия» рубрикасында эчке хәбәрләр һәм сәүдә-икътисад дөньясыннан яңалыклар урнаштырыла. Шунысы кызык: чыгышы Касыйм ягыннан булган Баязитов газетада аерым итеп «Ханкирмән яңалыклары»н бирә. Ханкирмән – Касыйм шәһәренең борынгы исемнәренең берсе.

«Фельетон» рубрикасында Шәриф Камалның «Әфгале милләтә бер имган» мәкаләсе басыла. Бу – булачак классик язучының матбугатта дөнья күргән беренче язмасы.

Беренче татар газетасының тууын котлап язган хатларның кайберләрен Баязитов аерым «Тәбрик хатлары» рубрикасында бастырган. Мәсәлән, Париждан (газетада шәһәр исеме Парис дип языла – **ред. иск.**) ниндидер бер Садретдиннең хаты килгән. Моның Сорбонна университеты студенты, булачак сәясәтче Садри Максуди тәбрикнамәсе икәнлеге аңлашыла.

«Нур» беренче саннан башлап ук игъланнар да урнаштырган. Иң беренче рекламаланган товар – китап. Коръәннең Казан басмасын сатучыга, Петербургта бастырып чыгарылган «Коръән Госмани бихат куфи», ягъни куфи стилендә язылган Госман Коръәненең факсимилесына һәм Самарадан Ибраһим Котлыәхмәтовның бик кызыклы басма продукциясенә урын бирелә. Соңгысының игъланы менә мондый: «Баш киемне мөселманга мәхкәмә урыннарында салмаска рөхсәт булуы хосусында Сенат разъяснениесе сатылмактадыр. Йөз данәсе өч рублә, бер данәсе җиде капика, почта маркасыны һәм кабул итәмез». Шулай итеп, татар-мөселманга Аллаһ кануны да, җир кануны да тәкъдим ителә.

ВАСЫЯТЬ

1914 елга Сафа Баязитовның газета чыгарудан башка да мәшәкатьләре арта. «Сыйрател мөстәкыйм» хәрәкәте, министрлыкта эшләр һәм башкалары да игътибарны таләп итә; өстәвенә, Баязитов әле исән мөфти Мөхәммәдьяр Солтановның тиздән бушарга мөмкин булган вазыйфасы өчен көрәшкә кушыла. Солтанов 1915 елның июнендә вафат була, әмма исән чагында ук «Мөфти кем булырга тиеш?» темасына бәхәсләр чыгып, татар җәмәгатьчелеге тарафыннан төрледән-төрле «кандидатуралар» тикшерелә.

Бу мәшәкатьләр дә, татар матбугатының гомуми үсеше, Санкт-Петербургта башка татар газеталарының чыгуы да, «Нур»ның тиражы кимүгә китерә. Тора-бара бу эш Баязитовка да канәгатьлек китерми башлый, ахрысы. 310 нчы саныннан соң газета чыгуын туктата.

Соңгы елларында газета либераль карашлы татар матбугатының тәнкыйтен күп татый. Әмма «Нур» үз кыйбласын югалтмый. Баязитовлар милләт киләчәген үзләренчә күргән, дөньяга аларча карау лязем түгел. Тик Гатаулла хәзрәт тә, Мөхәммәтсафа мөфти дә беренче чиратта үзләре хакында түгел, ә төрки-татар халкы, дине, милләтнең хәле-хокуклары турында уйлаган.

1905 елның көзендә төньяк мәркәздән татар дөньясына чәчелгән матбугат нурлары исә бүген дә балкуын дәвам итә. Гел шулай булсын.

Г. Баязитовның «Ислам и прогресс» китабы. Лев Толстойга бүләк ителгән нөсхә.

БЕРЕНЧЕ САНДА ГАТАУЛЛА ХӘЗРӘТ ҮЗ МӘКАЛӘСЕН ДӘ УРНАШТЫРА. «НУР» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МӘСЛӘГЕ» ДИГӘН БУ ЯЗМАНЫ ГАЗЕТАНЫҢ МАНИФЕСТЫ ДИП АТАСАК ТА ЯРЫЙ. «МӨХӘРРИР БАЯЗИДОВ» ИМЗАСЫ БЕЛӘН ЧЫККАН МӘКАЛӘДӘ АВТОР ИЛДӘ-ВАТАНДА БЕРЛЕК ҺӘМ ДУСЛЫК, КҮРКӘМ МӨГАМӘЛӘ УРНАШТЫРУ КИРӘКЛЕГЕНӘ ИГЪТИБАР ИТӘ. XX ГАСЫРНЫҢ ГАҖӘЕП ПРОГРЕСС ДӘВЕРЕ ИКӘНЛЕГЕН, БУ ПРОГРЕССТАН ТӨРКИ-ТАТАР КАВЕМЕНӘ ДӘ ФАЙДАЛАНЫРГА КИРӘКЛЕГЕН АССЫЗЫКЛЫЙ.

КИТАП БАСУ СЕРЛӘРЕН ХӘТЕРЛИ ТОРГАН БИНА

Николай Крушинин

Кайвакыт җансыз предметларның да – мәсәлән, биналарның – туган көннәре билгеләп үтелә. Бәйрәм вакытында кунаклар аларның «әти-әниләрен» – кайчандыр үзләренең «балаларына» гомер биргән архитектор һәм төзүчеләрне дә җылылык белән искә ала. Мондый юбилярлар фани дөньяда еллар, гасырлар, кайвакыт мең еллар буе да яши бит. Акылга сыймаслык даталарга кадәр яши – иң мөһиме, кем дә булса бу даталарны теркәсен һәм истә тотсын гына.

Менә, мәсәлән, совет конструктивизмы үрнәге – Бауман урамындагы барлык казанлыларга мәгълүм Матбугат йорты. Әлеге бина, хәзер бу йортта урнашкан «Ногай» кунакханәсе хезмәткәрләре көче белән, июльдә 90 еллык юбилеен билгеләп үтте.

Архитектурасы белән башкалардан нык аерылып торган бинаны 1935 елда архитектор Семён Самойлович Пэн проектлаштырган.

КУЫП ТА ҖИТӘРБЕЗ, УЗЫП ТА КИТӘРБЕЗ!

Узган гасырның 30 нчы еллары башына Казанда полиграфия тармагында хәлләр ничегрәк булган соң? Индустриальләштерү һәм күмәкләштерү чоры, беренче бишьеллыклар һәм «Куып та җитәрбез, узып та китәрбез!» шигаре астындагы төрле «ыргылышлар» заманы бу.

Ә куып җитәрлек нәрсәләр күп була шул. Узган гасырның 30 нчы еллары башында Казанда алты типография эшли: «Красный печатник», Александров исемендәге, Камил Якуб исемендәге, «Пролетарское слово», полиграфия мәктәбенең Луначарский исемендәге типографиясе, «Восток» типолитографиясе. Әлеге типографияләрнең барысында бергә 76 китап басу, 22 литография һәм 115 китап тышлау машинасы исәпләнә. Бу бик аз, чөнки, бер як-

Фото: Александр Ефремов

Җеп белән тегә торган БНШ-6 брошюра-тышлау операцияләре машинасы. Мондый машина Татарстан китап нәшриятының тышлау цехында эшләгән.

тан, яшь совет иле халыкның наданлыгыннан ашыгыч темпларда котылырга омтылса, икенче яктан, партия сәясәте дә гаять зур күләмдә матбугат һәм агитация-пропаганда басма материалларын таләп итә. Дәреслекләр һәм китаплар җитми. Өстәвенә, татар телендәге бөтен китап басу эше Казанда, «Татарстан китап нәшриятында» («Татиздат») тупланган була. Әле нәкъ менә шул ук вакытта латин әлифбасы да кертелә башлый. Кыскасы, җирле китап басучыларның эше муеннан була, ә полиграфия куәтләре җитешми.

Ул замандагы мәшһүр газетачы Сафа Борһан язуынча, Казанның типографияләре бөтенләй яраксыз урыннарда – «Казан ханнары заманыннан диярлек калган» ниндидер ярым подвалларда урнашкан була. Ә тагын ул Казанда «полиграфчыларныкы кебек үк начар хезмәт шартлары булган башка бер генә тармак та юк, ә бит полиграфия җитештерүе иң зарарлыларның берсе санала», дип тә язып калдыра.

Шуңа күрә нәшрият эшенә катнашы булган бар халык «якты киләчәк» төзү планына үз ихтыяҗларын да кертү – социализм чорына лаеклы югары механикалаштырылган китап бастыру фабрикасы төзү турында хыяллана. Бу хыялны «Татиздат» башлыгы Салих Заһит улы Шәрәфетдинов Мәскәүгә «алып китә» һәм аның белән, башкалада яшәп, конструктивизм белән мавыгучы яшь архитектор Семён Пэнны да мавыктыра ала.



Кунакханә китапханәсе.

Һәм Президент номеры китапханәсе.

Кунакханәнең һәр номерында – «Литературная Казань» нөсхәсе. Чөнки, татар шагыйре Хәсән Туфан язганча:

«һәр икәүнең гомере –
тиңсез роман,
һәр берәүнең көне –
хикәя».



Моннан 90 ел элек язучы һәм шагыйрьләр менеп-төшеп йөргән легендар баскыч...

65 000 СУМГА ТҮГЕЛ, Ә 28 000 СУМГА 1 ЕЛ ЭЧЕНДӘ ТҮГЕЛ, Ә 4 АЙДА

Казанлыларны җирле архитекторларның проектлары ни өчендер канәгатьләндерми, ә менә мәскәүле Пэнның проекты күңелләренә хуш килә. Сафа Борһан «Кызыл Татарстан» да нәкъ менә Пэнны сайлауларын болай шәрехли: «ИТХ «Татиздат»ка Азәрбайҗанда Матбугат йорты төзегән инженер-полиграфчы Пэнны тәкъдим итте. Инженер Пэн «Татиздат»ка Матбугат йорты төзелеп беткәнчегә кадәр эшкә алынды. Ул эскиз проектын төзеде. Инженер Пэнның эскизы Мәскәүдә расланды һәм монда Полиграфчылар берлеге өлкә бүлеге президиумының киңәйтелгән утырышында, Камил Якуб исемендәге типография һәм «Кызыл Татарстан» типографиясе эшчеләренең берләштерелгән производство киңәшмәсендә, ТР Дәүләт планында, ТР Төзелеш берләшмәсендә җентекләп тикшерелде һәм бөтен җирдә дә хупланды.

Шәһәр Советы урын бирде. Эш проектны төзүгә кадәр барып җитте. Казандагы Төзелеш берләшмәсе эш өчен 65 мең сум сорады һәм 1 ел вакыт билгеләде. Тагын Мәскәүгә мөрәҗәгать итәргә туры килде. Әмма Моссовет каршындагы Моспроект эше күп булганга баш тартты, бары тик ТР Халык Комиссарлары Советының Моссовет президиумына телеграф мөрәҗәгатеннән соң гына, Моспроект Казанда Матбугат йорты проектын төзергә ризалашты, өстәвенә, 65 мең сумга түгел, ә 28 мең сумга гына, һәм бер елда түгел, ә иң күбе дүрт айда әзерләп бирергә булды...»

Шул рәвешле, ул вакытта инде даны таралган ике бина – Мәскәүдәге «Красный пролетарий» типографиясе клубы һәм Бакудагы Матбугат йорты (сүз уңаеннан, безнең Матбугат йортына бик охшаган) авторы булган Пэн эшкә тотына. Бу урындагы Иске икмәк базары хәрабәләреннән җилләр исә.

МАТБУГАТ ЙОРТЫНЫҢ КИТАП ДӨНЬЯСЫ

Бүген Матбугат йортында китап кибете дә, китап рестораны да, узган гасыр китап басучыларының традицияләрен саклый торган кунакханә дә «яши». Кунакханәгә килүчеләр әле монда, әле анда бина буйлап сибелгән махсус «музей почмакларында» җеп белән тегә торган БНШ-6 брошюра-тышлау операцияләре машинасын, Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь Муса Җәлил Бөек Ватан сугышы башланганчы утырып эшләгән өстәлне кызыксынып өйрәнә. Моннан 90 ел элек язучы һәм шагыйрьләр менеп-төшеп йөргән баскычтан йөри... Шулай ук китап укырга да мөмкин – кунакханә китапханәсендә дә, һәр номерда да аларга монда аерым урын бирелгән. «Президент» люксы булсынмы, «эконом» бүлмәләрме – һәркайда.

ХӘТЕРНЕҢ ДӘҺШӘТЛЕ БИТЛӘРЕ

2025 ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ

80 ЖИҢҮ!

1948 елда Казан Тел һәм әдәбият институтының фольклор секторы галимнәре Хәмит Ярми белән Халидә Гатина һәм булачак язучы, ул вакытта Казан университеты студенты Нурихан Фәттахов сугыштан соң беренче тапкыр Татарстанның Актаныш, Калинин (бу район 1959 елдан Актаныш һәм Мөслим районнарына бүлеп бирелә), Мөслим һәм Минзәлә районнарына фольклор экспедициясенә чыгалар. Сугыш тәмамланып өч ел узган. Әмма, тыныч тормыш башлануга карамастан, сугыш турындагы истәлекләр дә, ул калдырган яралар да яңа була әле. Бу экспедицияләр вакытында галимнәр белән аралашучыларның, мәгълүмат бирүчеләрнең дә күбесе – Бөек Ватан сугышында катнашкан кешеләр, фронтовиклар. Алар Бөек Ватан сугышы турында шактый гына истәлекләре белән дә уртаклашалар, үзләре катнашкан яулар, дошман тылына разведкага барулары, сугышчан дуслары турында да сөйлиләр.

Сезне дә 1948 елгы шушы фольклор экспедициясе вакытында Халидә Гатина белән Нурихан Фәттахов язып алган сугыш турындагы истәлекләр белән таныштыруны дәвам итәбез. Язмаларны, сөйләүчеләрнең сөйләм үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, үзгәрешсез диярлек тәкъдим итәбез. Сугыш ветераннарының җанлы сөйләме истәлекләрдәге вакыйгаларны тулырак күзалларга, шул чорның дәһшәтен тоярга ярдәм итәр, дип өметләнәбез.

Фотолар: Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге фондыннан, Минзәлә туган якны өйрәнү музееннан.

ХАННАН МАЛИКОВ: «КЕЧКЕНӘДӘН ГЕРОЙ ИДЕ...»

Илсөяр Закирова

Истәлекләр арасында сугыштан кайтмый калган геройлар турында язмалар да бар.

Баян Дәүләтов 19 яшендә Белоруссия җирендә барган каты сугышлар вакытында һәлак була. СССР Югары Советы Президиумының 1943 елның 30 октябрендәге указы белән Днепрны кичкәндә һәм аның уң як ярында плацдармны тотып торуда күрсәткән батырлыгы өчен лейтенант Баян Дәүләтовка Советлар Союзы Герое (үлгәннән соң) исеме, Ленин ордены бирелә.

Истәлекне Актаныш районы Татар Әҗбие авылы кешесе Ханнан Маликовтан 1948 елның 14 июлендә Халидә Гатина язып алган. Ханнан Маликов шул авылда туып-үскән Баянның 10 яшьтән ятим калган авыр балачагы, кечкенәдән хәрби хезмәт турында хыяллануын сөйли, аның белән бәйле вакыйгаларны искә төшерә.

– Баян үзе фәкыйрь семьядан. Анасыннан – 2–3 яшьләрендә, атасыннан 10 яшьтә калды. 1924 елны туган бала ул. Атасы үлгәч, үги анасы кияүгә китте, малайны күрше-күлән тәрбиягә алды. Мин дә аңа бияләе булмаганда бәяләй бирдем, башка әйбере булмаса – башканы. Ашау-эчү минеке түгел ие. Укыттык.

Мин, 1914 елгы империалистик сугышта катнашып, күрсәткән геройлыкларым өчен «Георгиевский крест» алдым. Шул сугыштан, бер аякны калдырып, инвалид булып кайттым. Баян бу хәлләр белән кызыксына иде. Ул миннән сорый иде: «Ничек-ничек алдың моны?» – дип. Мин әйтә идем: «Сугышлар була ул, бу азаккы сугыш түгел әле, суга керергә кушсалар – суга кер, утка керергә кушсалар – утка кер. Разведкалар була, дошманнарның кайда торганын алдан барып белешеп кайтасың», – ди торганыем. Шуларны кызыксынып миннән сорарые.

Минем аның белән бер яшьтәге Тимершәех исемле балам барые. Аның белән бергә уйныйларые. Икесенә ике мылтык ясап бирдем. Мин аларга солдат уеннары өйрәтә идем, балалар уеннары өйрәтә идем. Алар берсе аклар булып, берсе кызыллар булып, берсенә берсе каршы чыгаларые. Чыгып китәләр иде пычраклар аркылы... Минем малай пычракларга бик керми иде, ә ул – керә. Малай бик герой була иде. Аны үги анасы бик каты тиргәр иде. Анасы бик нык тиргәгән чакларда баланың күлмәк-ыштаннарын үземнең корткага юарга бирәдер идем. Мин аны күп тәрбияләдем. Ул, тормыш авыр булуга карамастан, 7 классны бетереп, ФЗӨгә (фабрика-завод өйрәнчеклеге - ред. иск.) китте, Дербышкига. Ул 3–4 яшендә вакытта атасы белән Дербышкида торып алган. Шунда рус телен өйрәнгән, русча бик яхшы сөйләр иде.

Көннәрдән бер көнне, китәләр минем балалар җуага (юага – ред. иск.). Анда үзәк киртә бар иде. Шул киртә артында бер кәҗә бәрәнләп җата икән. Балалар әйләнеп кайта. Шуннан минем улым Баянга сөйли: «Без бүре баласы күрдек», – ди. Бу җөрәгенә чыдый алмый: «Давай, барабыз!» – ди. Балалар риза түгел. «Бүре ашар», – диләр. Мин әйтәм: «Бар, Баян». Агачтан ясалган мылтыкны алды да китте бит бу. Малайлар тегенең артыннан баралар. Балалар чын бүре дип баралар инде, үзләре күреп,

куркып кайтканнар бит. Бу инде агач мылтык белән герой булып бара. Шуннан, барсалар, кәҗә бәрәннәре җата. Бу күңеле төшеп кайта: бүре булмады бит. Шуннан соң инде балалар көлешәләр. Баян әйтә: «Сез бернәрсә дә булдыра алмыйсыз», – ди.

Ул армиягә бик шатланып китте. Ул иркен тормышта яши торган кеше баласы түгел иде. ФЗӨдән кайткач: «Минем төрле үнәр (һөнәр – ред. иск.) өйрәнәсе килә», – дип, минем белән тәгәрмәчләр эшләргә үрәнде (өйрәнде – ред. иск.). Колхозга эшли иде. Мин әйтер идем: «Бу колхозга эшләгәнгә, хезмәт көнен миңа язалар бит», – дия идем. Ә ул: «Миңа көн кирәкми, миңа үрәнү кирәк», – дия иде.

Армиягә киткәч, миңа хатлар язды: «Шулай-шулай, мин геройлыклар күрсәттем», – дип. Мин аңарга җавап яза идем: «Шулай, яхшы эшлә, мин син кайтырга матур кызлар хәзерләп куярмын», – дип. Ул сүзне бик тыңлаучан иде, ни кушсалар да, каршы әйтмәде. ФЗӨдән кайтып, армиягә киткәнгә кадәр колхозда кибән кую һәм башка шуның кебек эшләрдә күп эшләде.

Мин үзем 1892 елны туган. 1913 елны солдатка алындым. 1914 елны сугышка киттем, ул чакта ефрейтор идем. Сугыш вакытында наступление каты булгач, без бара алмадык, окоп казыпяттык. Бервакыт төнлә сорыйлар: «Кем разведкага бара?» Кемгә булса да барырга кирәк бит инде илне сакларга. Мин китәргә булдым инде, шиста (шест, озын таяк – ред. иск.) алып, киттем елганың тирәнлеген үлчәргә. Күпернең эченә кереп бер салдым, ике салдым, тирәнлеген белеп булмый гына бит. Өченче салуда ата башладылар. Арттан да, алдан да аткан шикелле. Инде без артка чиктек. Иптәшләр качып бетте. Барып утырдым бер бакча буена.

Мин утырган вакытта лыш-лыш килгән бер тавыш ишетелә башлады, карасам, кеше икән. Ул кеше миңа: «Давай утыр, давай, плен калыйк», – ди. Мин әйтәм: «Булмый», – дим. Шуннан без киттек, кай якка барганбыздыр инде. Без кайта торган юлда бер раненый ята. Моннан пропуска сорыйбыз. Бу әйтә: «Рус мин», – ди. Шуннан моның мылтыгын алып, җилкәгә киеп, кулга кулны тотып, үзен күтәреп, җилгә каршы үзебезнең юнәлеш белән кайта башладык. Кайта-кайта, тагын шәүлә күренә, «пытыр-пытыр» килә. Кайда барырга да белмибез, ни булса булыр, дип, киттек шәүләгә таба.

Болар тагын үзебезнекеләр булып чыкты. Барыбыз унике кеше бергә җыелдык. Авыруны да үзебез белән алып кайттык. Елганың тирәнлеген белә алмадык.

Иң зур республика агрохолдингларының берсенә нигез салучы. Россия чаңгы ярышлары федерациясе вице-президенты… Болар барысы да – бер кеше, Илшат Фәрдиев. Тик шулай да, аның тормышындагы төп эш – энергетика. Илшат Фәрдиев – «Челтәр компаниясе» АҖнең генераль директоры, хәтта көндәшләре дә аңа һәм ул җитәкләгән оешмага охшарга омтыла.

ИЛШАТ ФӘРДИЕВНЕҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

TOYOTAДАН – «КӨМЕШ» ДӘРӘҖӘ

Узган җәйдә «Челтәр компаниясе»нә чит ил аудиторлары килеп төшә. Нәрсәгә дисезме? Илшат Фәрдиев җитәкләгән компаниянең дәрәҗәсе никадәр югары икәнен бәяләргә тели алар. Дөресрәге, эталон исәпләнгән «Тойота. Тосиа Хорикири, Toyota Engineering Corporation» гомуми җитештерү системасы принциплары буенча ул ничә баллга туры килә? Әмма баштан ук тынычландырып куялар: борчылмагыз, максималь 5 баллга бәяләнә торган компанияләр җир шарында бөтенләй юк. «Хәтта шул ук Toyota үзе дә заводларының эшчәнлеген 4,2–4,6 баллга бәяли, – дип хәбәр итәләр «Челтәр компаниясе» вәкилләренә. – Күпчелек башка компанияләр 1 дән алып 2 балл арасында тирбәлә...» Әмма Татарстан энергетиклары шуны исбат итте: алар – күпчелек түгел. «Челтәр компаниясе» аудит нәтиҗәләре буенча 3,76 (җитештерүне бәяләү өлешендә) һәм 3,59 (идарә итү) баллга лаек дип табылды. Һәм дөнья күләмендәге ун компания арасында берьюлы ике юнәлеш буенча да көмеш дәрәҗәгә ия булган оешмаларның берсе булып танылды. Үз секторында – гомумән дөньяда бердәнбер. Нәрсә дип атап була моны? Фәрдиев стратегиясе, диеп, бәлки? Асылда, ул стратегия бик гади һәм аңлаешлы: «Җәмгыятькә файда китерергә, эшне һәрдаим хезмәт күрсәтүнең югары сыйфатына ирешеп алып барырга». Нәкъ менә шулай булганда гына чын мәгънәсендә дөрес кыйммәтләр тәрбияләнә, эш ысуллары, хәтта монополияле эшчәнлек төрендә дә, көндәшлекле өстенлеккә ия булырга мөмкинлек бирә.

ГЕНЕРАЛ БУЛАСЫҢ КИЛСӘ, ТҮБӘННӘН БАШЛА

«Беренче көнне үк миңа багана буярга куштылар. Ә кичләрен ике ай буена мин фабриканың схемасын сыздым», – дип искә төшерә үзенең хезмәт биографиясен Илшат Фәрдиев. Институтны «Шәһәрләр белән авыл хуҗалыгы сәнәгать предприятиеләрен электр белән тәэмин итү» белгечлеге буенча тәмамлаган егет, «Тукай» кошчылык фабрикасына эшкә урнаша. Җылы урынны аңа бирәү дә әзерләп куймый – гап-гади электромонтер буларак кабул итәләр. Әмма җитәкчелекнең яңа кадрны эштә сынап карарга, бәяләргә бик яхшы мөмкинлеге пәйда була.

Авыл җирендә үскән малайны эш белән куркыта алмыйсың: нәрсә әйтсәләр, шуны ялт итеп башкарып куя. Өлкәнрәк агайлары өйрәткәнне дә үзенә сеңдереп бара, үзләштерә. Баш энергетик Дмитрий Соколов белән цех башлыгы Анатолий Платонов аның өметле булуын, алга китәчәген шунда ук абайлап ала. Ике елдан соң, Фәрдиев инде өлкән инженер булгач, һәм аны Чаллыдагы тимер-бетон заводына чакырып алгач, Соколов чын күңелдән борчылып әйтә: «Мин бит сине үз урыныма әзерләгән идем...»

Фото: tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

БЕРДӘМ ОРКЕСТР ҺӘМ МАЭСТРО

Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары узганда, Фәрдиев һәм аның командасы янәдән булдыклылыкларын күрсәтә: энергия белән тәэмин ителештә бернинди өзеклекләр булмый. «Чемпионатка әзерлек эшләрен спортчыларны әзерләү белән чагыштырып була: анда да, монда да публика бу эш барып чыксын өчен нинди зур көч куелганын сизәргә тиеш түгел, – диде Фәрдиев урынбасарларының берсе. – Әлбәттә, без спорт объектларын энергия белән тәэмин итүдә шактый зур тәҗрибәгә ия: Универсиаданы да, су спорт төрләре буенча дөнья чемпионатын да искә алырга була... Әмма, шулай да, мондый масштабларга иялэшеп булмый. Бу кадәр югары җаваплылык территориясенә кергәч, һәрвакыт зур киеренкелек кичерәбез».

Илшат Шәех улы һәм аның командасы бу гаять зур киеренкелекне ничек җиңә дә иң катлаулы бурычларны ни рәвешле башкарып чыга соң? Монда Фәрдиев ачыклыкны инде үзе кертә: «Бездә үз һөнәренең чын осталары эшли, алар бу эшкә бөтен көчен бирә, зур җаваплылыктан курыкмый. Безнең уңышның сере шунда – эш тиешенчә җайга салынган. Бөтен коллектив, күпьеллык тәҗрибәсенә таянып, бердәм оркестр кебек эшкә көйләнгәндә, башкача була да алмый». Ә без болай дип тә өстәр идек: яхшы оркестрның ярты уңышы – ул әле аның дирижёры чын оста булуда. Җитмәсә, иң идеаль системаны да стихия ныклыкка сынап карарга мөмкин бит...

СТИХИЯГӘ КАРШЫ – КОМПЕТЕНЦИЯЛӘР, ТӘҖРИБӘ

2010 ел. Гадәттән тыш хәл. Көчле кар һәм бозлы яңгыр бөтен Чистай районын утсыз калдыра, тирә-якта – ерып чыкмаслык кар көртләре. Төбәк диспетчер идарәсе баш диспетчеры Валерий Кандалинцев бик зур авырлык белән диспетчерлык пунктына барып җитә. Ни күрсен: диспетчер янәшәсендә итекләрдән һәм олы колчакчынлы бүректән, курткадан берәү тора һәм кызып нидер аңлата. Баш диспетчер аптырап кала: «Эш нәрсәдә, нишләп объектта чит кеше?» – дип кызыксына. «Чит кеше» аңа борыла – ни күзе белән күрсен, Фәрдиев үзе! Ул, Кыш бабай сыман, нindидер могҗиза белән кар көртләрен ерып, диспетчерлык пунктына килеп җиткән! Шунда ук энергосистема өлкәсендәге хәлләрне сөйләшәләр, эш планын коралар. Илшат Шәехович күрсәтмәләр бирә дә китеп бара. Офиска түгел, юк, ә иң «кайнар» ноктага – Чистайга, кешеләр утсыз һәм җылысыз утырып калган тарафка...

Бу гомумән Фәрдиевнең төп сыйфатларыннан берсе: кабинетта утыру – аның өчен түгел. Ул – һәрчак вакыйгалар уртасында. Командада бик яхшы беләләр: бу күз буяр өчен генә эшләнми. Катлаулы очракларда Фәрдиевнең компетенциясе, тәҗрибәсе – уңыш өчен гарантия.

БИТАРАФЛЫККА ТАБУ

Бервакыт, әле «Татэнерго» җитәкчесе булганда, Фәрдиев менеджерларны җыеп ала да хәбәр итә: «Иртәгә Минзәләгә барабыз». Катлаулы яшүсмерләр укый торган коррекцион мәктәпкә килгән булып чыгалар. Күргән нәрсәләр барысын да шаккатыра: ишекләр урынына төсе уңып беткән чаршаулар эленеп тора, рәтле караватлар да, тумбочкалар да юк... Фәрдиев әйтә: «Йә, нишлибез?» Барысы да – ләм-мим. Ә ул инде үзе өчен карар кабул иткән булып чыга. Энергетиклар мәктәпне үз шефлыгына алганнан соң, хәлләр үзгәрә. Битараф булмау – Фәрдиев характерындагы төп сыйфатларның берсе. Ни кызганыч, ул һәрбер җитәкчедә дә юк шул. Хәтта «Фәрдиев балалары» дигән гыйбарә дә пәйда була. Болар – аз керемле гаиләләрдә тәрбияләнә торган кызлар белән егетләр. Илшат Шәех улы аларга, укуларын түләп, югары уку йортында белем алырга мөмкинлек бирә. Укырга баручы балаларга да Фәрдиевнең шәхси кеременнән мәктәпкә әзерләү өчен акчалар бүленә. Мөмкинлекләре чикле булган балаларга коляскалар алып тапшырыла. Ел саен алар – дистәләгән.

ИРТӘГӘГЕ КӨННЕ КҮЗДӘ ТОТЫП ЯШӘҮ

90 нчы еллар уртасында Фәрдиев туган ягына кайта – мондагы җирле хуҗалыкны үз кулына ала. Ул кайтканчы, хуҗалык инде шактый таушалган була. Илшат Шәех улы соңрак сөйләгәнчә, аның укытучылары өлкән агайлары – Феликс һәм Ринат. Ринат Зәй районында колхоз рәисе вазифасын үти, һәр иртәне диярлек алар Пучы җирләренең чигендә, ызанда очрашалар. «Абый миңа киңәшләрен бирә, сөйләшәбез. Ул вакыттагы ТР авыл хуҗалыгы министры Фатыйх Сәүбән улы Сибгатуллин еш килә иде. Нәкъ менә ул мине иртәгәге көнне уйлап яшәргә һәм даими рәвештә технологияләрне яңартырга өйрәтте», – дип искә ала Илшат Шәех улы.

Иртәгәне күз уңында тотып яшәү һәм технологияләрне яңартып тору – «Челтәр компаниясе» топ-менеджеры бүген дә эзлекле һәм даими рәвештә шуларны үти. Киң колачлы реконструкция – бер мәртәбә уздырыла торган кампания түгел, ә даими эш. Яңа подстанцияләрне ачу Татарстан энергетика системасын тагын да ышанычлырак итә, «Челтәр компаниясе»нең «акыллы» счетчиклары энергиянең хәрәкәтен һәм ресурсларны югалту, урлау нокталарын төгәл билгели, беренче цифрлы подстанцияләр – болар ныклап уйланылган программаларны, бүгенге көндә иң яхшы саналган технологияләрне гамәлгә кертү нәтиҗәсе.

Хәер, югарыда аталганнар – инде «бүгенге көн». Татарстан энергетикасының иртәгәсе күп очракта Илшат Фәрдиевнең идея һәм планнарыннан тора. Ә бу идеяләр белән планнар һәрчак заман белән бергә атлый. Дөресрәге - бер адымга алдарак та.

ФИДАКАРЬ ХЕЗМӘТ ҮРНӘГЕ

Компетентлылык, профессиональлек, яңалыкны кабул итүгә һәм кертүгә әзер булу, камиллеккә омтылу. Бу җитәкче ия булырга тиеш сыйфатларның кайберләре генә. Ләкин алар да һәрвакыт иң югары нәтиҗәне бирмәскә мөмкин. Үз предприятиеңне эшли торган өлкәсендә төп флагман итү, вакыттан алдарак бару һәм конкурентларны артта калдырып юл яра белү – моңа бик сирәк, чын мәгънәсендә үзенчәлекле шәхесләр, беренче дәрәҗәдәге топ-менеджерлар гына сәләтле. «Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев кебекләр.

Рәүзил Хаҗиев,
«Татэнерго» АҖ генераль директоры

Энергетика – Илшат Шәех улының гомерлек эше ул. Гап-гади электромонтёрдан үз тармагының генералына кадәр үткән юл – шәхеснең ни дәрәҗәдә башкалардан аерылып торуына яхшы дәлил. Ил өчен катлаулы чорларда ул «Татэнерго» оешмасын җитәкләде, ТР энергетика министры буларак, тармакны үстерүдә төп бурычларны анык билгеләде.

Бүген ул җитәкләгән «Челтәр компаниясе»нең беренчел бурычы – электр энергиясенә ихтыяҗны тәэмин итү, аны тапшырганда, сыйфат һәм ышанычлылыкны нигез итеп кую. Компания бу гаять катлаулы бурычны ничек үтәгәнен, асылда, Татарстандагы зур саммитлар барышында да, көндәлек шартларда да энергетика объектларының төгәл эшләве раслап тора. Моның сере коллективның югары дәрәҗәдәге оешканлыгы һәм эшне алып бару осталыгына бәйле, әлбәттә. Тик алай гына да түгел, бу – иң беренче чиратта, Илшат Фәрдиев тарафыннан җентекләп уйланылган һәм еракка карап төзелгән эш стратегиясе. Әлеге стратегия даими рәвештә технологик камилләшүне күздә тота. Инновацияләр, цифрлаштыру, импортны алмаштыру, яңа технологияләр – болар барысы да перспективаны күздә тоткан максатлар, әмма бер үк вакытта нәкъ менә бүгенге көннең үсеш кораллары да.

Мисаллар китерү бик җайлы. Узган елның азагында энергетиклар ПС 110 кВ «Сокуры» электр подстанциясен гамәлгә кертте. «Ул Казан агломерациясе, Кама арьягы һәм Башкортстан белән чиктәш территорияләрнең триумфаль рәвештә цифрлашуын исәптә тота», – дип хәбәр итте газета-журналлар. Бу яулаган үрләрнең берсе генә: озакламый яңа буын подстанцияләренең цифрлашуы Татарстан электр челтәре комплексының тулаем йөзе үзгәрүгә китерәчәк. «Челтәр компаниясе»нең 70 млрд сумга исәпләнгән биш еллык инвестицион программасы әлеге ниятләрне тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк. Меңләгән киловатт өстәмә «цифрлы» куәткә, диде Илшат Фәрдиев, Казан, Алабуга, Бөгелмә шәһәрләре ия булачак.

«Челтәр компаниясе»нең, яңа технологияләр кертүкәндә, үзебезнең илнекеләргә өстенлек бирүе дә бик мөһим. ТР премьер-министры Алексей Песошин билгеләп үткәнчә, «Челтәр компаниясе»нең сәясәте – энергетика кластерын үстерү һәм бүген югары дәрәҗәдәге заманча җитештерүне җайга салган предприятиеләр белән эшне тыгыз бәйләнештә алып бару. Болар барысы да Татарстан электр челтәре комплексының ышанычлы, тотрыклы эшләвенә нигез булып тора».

Тагын бер мөһим факт. Узган елны «Челтәр компаниясе» Россиядә беренче мәртәбә сакчыл җитештерү өлкәсендә («Toyota» T-TPS Бөтендөнья җитештерү системасы критерийлары буенча) һәм предприятие белән идарә итү системасы юнәлешендә (TMS халыкара стандартлары ягыннан) көмеш дәрәҗәгә лаек дип табылды. Бу бәяләү системасы, исегезгә төшерәм, дөньядагы нәтиҗәле менеджментның эталоны исәпләнә.

Илшат Фәрдиев, дөрес, компаниянең уңышларын үз уңышы гына дип исәпләүдән ерак тора торган кеше. «Бездә үз һөнәренең чын осталары эшли, алар бу эшкә бөтен көчен бирә, зур җаваплылыктан курыкмый, – ди ул. – Безнең уңышның сере шунда – эш тиешенчә җайга салынган. Бөтен коллектив, күпьеллык тәҗрибәсенә таянып, бердәм оркестр кебек эшкә көйләнгәндә, башкача була да алмый».

Талантлы кеше һәр нәрсәдә дә талантлы, диләр. Илшат Шәех улы – әлеге сүзләргә ачык мисал. Ул нигез салган агрохолдинг – уңышлы эш үрнәге, ул җитәкли торган ТР Чаңгы ярышлары федерациясе – чемпионнар үстерә торган «уңдырышлы туфрак». Ул әле гаять юмарт, авыр вакытта ярдәм кулын сузарга әзер кеше дә. Мондый сыйфатлар хәзер бик сирәкләргә генә хас.

– Хөрмәтле Илшат Шәехович!

«Татэнерго» АҖ коллективы, шулай ук оешманың ветераннары һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән котлыйм! Республика энергетикасының үсеше – Сезнең җитәкче талантыгыз, оештыру сәләтегез һәм югары компетенциягез турында сөйли. Тарихи яктан карагында, кыска гына вакыт эчендә энергетика тармагы тулаем яңартып корыла, үсешкә яңа импульс бирелә. Сез – бик белдекле, нәтиҗәне алдан күрә белә торган җитәкче, күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, алдыгыздагы бер бурычтан та, кыенлыктан да чигенми торган шәхес. Безнең коллектив кайчандыр «Татэнерго» руле Сезнең кулда булган заманнарны горурлык белән искә ала. Сез – компаниянең нигезен салган кеше. Бәлки, шуңа да безнең хезмәттәшлек уңышлы, нәтиҗәледер. Аның нигезендә, тармакны яхшы белү генә түгел, идеяләр уртаклыгы һәм чын дуслык та ята.

Сезгә бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман, сәламәтлек, Татарстаныбызның иминлеге хакына башкарыла торган эшегездә уңышлар телибез. Гаиләгездә дә, күңелегездә дә тынычлык, иминлек булсын!

Фотолар «Татэнерго» АҖ матбугат хезмәтеннән алынды.

ҖИҢҮ ҺӘМ КАЗАНЫШЛАР ЭНЕРГИЯСЕ

«Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры Илшат Фәрдиев электромонтёрдан энергетика тармагы җитәкчесенә кадәр юл үтте. Республика энергетикасы өчен кадрлар әзерләүнең ни дәрәҗәдә мөһим булуын аның кадәр аңлаучы башка берәүне табып та булмастыр.

Эдвард Абдуллаҗанов,
КДЭУ ректоры, ТР Дәүләт советы депутаты

Электр челтәрләре буенча республикабыздагы иң эре инфраструктура альма-матер – Казан дәүләт энергетика университеты белән хезмәттәшлеккә бик зур роль бирә. Бу хезмәттәшлекнең компания җитәкчелеге вәкилләре тарафыннан лекцияләр уку яки студентларның компания предприятиеләрендә практика узуы кебек традицион формаларыннан кала, заман таләп иткән башка формалар да бар. Мәсәлән, «Челтәр компаниясе»нең ике филиалында (Идел буе һәм Казан электр челтәрләре) КДЭУның «Югары көчәнеш электр җиһазлары» һәм «Интеллектуаль электр энергетикасы системалары белән челтәрләре» кафедралары эшли. Биредә укыту, студент һәм мөгаллимнәрнең фәнни эшләре җитештерү бурычлары белән турыдан-туры бәйле, димәк, оешма һәм тулаем энергетика сәнәгате ихтыяҗлары өчен максатчан рәвештә кадрлар әзерләүнең сыйфаты да арта.

Фән, мәгариф һәм практиканың нәтиҗәле хезмәттәшлегендә төп рольне Илшат Фәрдиев үти. Компаниянең генераль директоры – үзе дә МЭИның Казан филиалын тәмамлаган кеше. Ул хезмәт юлын кошчылык фабрикасында гап-гади электромонтёр булып башлаган, ә аннан инде Татарстан энергетикасында югары вазыйфаларга күтәрелгән кеше. Үз заманында «Татэнерго» белән җитәкчелек итте, Премьер-министр урынбасары – ТР энергетика министры булды, ә 2012 елның маеннан башлап – «Челтәр компаниясе» АҖ генераль директоры. Аның кул астында эшләгән оешмада энергетиканың вакытны узып алга бара торган тармак булуын яхшы аңлыйлар. Бу яктан «Челтәр компаниясе» Россия күләмендә әйдәп баручы оешмаларның берсе булып тора. Аерым алганда, Smart grid, яки «акыллы челтәрләр» җиһазларын кертү һәм эшләтеп җибәрү программасын тормышка ашыру буенча. Әлеге «акыллы челтәрләр» бүлү челтәрләре белән белән дистанцион идарә итү мөмкинлеге бирә. Бу исә, үз чиратында, бернинди тоткарлык һәм өзеклекләргә юл калдырмый. Үз сегментында компания Россиядә иң яхшылардан исәпләнә, шуңа да Казанга еш кына әлеге тармакта тәҗрибә туплар өчен илнең төрле төбәкләреннән белгечләр килә.

Илшат Шәех улы коллегалары өчен тагын бер яктан үрнәк шәхес – хыял-омтылышларыңны тормышта максималь дәрәҗәдә чынга ашырып булуы һәм кирәклеге ягыннан, мисал өчен. Төп эше, ягъни Татарстанда иң эре агрохолдингларның берсен булдырудан тыш, ул әле тагын дүрт чакырылыш ТР Дәүләт советы депутаты, атаклы химаяче дә. Тулы бер төркем – «Фәрдиев балалары» өчен зур тормышка юл ачкан зат: мөмкинлекләре чикле, яшәү шартлары авыр булган гаиләләргә булышып, аларның кыз-улларына югары белем алырга мөмкинлек тудырып, балаларны мәктәпкә әзерләүдә чыгымнарны үз өстенә алып, инвалид балалары булган гаиләләрне коляскалар белән тәэмин итеп. Илшат Фәрдиев – ТР Чаңгы ярышлары федерациясе президенты һәм Россиянең Чаңгы ярышлары федерациясе вице-президенты.

«Боларның барысына да ничек өлгерергә һәм ирешергә була?» – дип сорарсыз. Гадәттә, студентларда булачак һөнәрен күзаллаган чакта андый сорау туа. Августта 65 яшьлеген билгеләп узарга җыенучы Илшат Фәрдиев моңа бик гади генә бер киңәш белән җавап бирә алачак: «Нинди генә эш булса да, сайланып, вакланып тормаска, тотынып, җиренә җиткереп эшләргә».

– Хөрмәтле Илшат Шәехович!

Безне һөнәри ориентирлар гына түгел, ә уртак тарих та берләштерә. Сез – МЭИның Казан филиалы чыгарылышы вәкиле, ә бу – илебездәге иң алдынгы, әйдәп баручы вузларның берсе. Безне бәйләп торган әлеге җепләр мөнәсәбәтләребезне тагын да ныграк итә. Хәзерге вакытта Казан дәүләт энергетика университеты белән «Челтәр компаниясе» арасындагы дуслык инде ныклы нигезгә корылган – без бергәләп инженер кадрлар әзерлибез, тәҗрибә уртаклашабыз, төбәкнең энергетика тармагын алгарышка илтергә омтылабыз.

Казан дәүләт энергетика университеты һәм шәхсән үз исемемнән Сезне чын йөрәктән юбилеегыз белән тәбриклим! Ныклы сәламәтлек, көч-энергия һәм барлык хыялларыгызны тормышка ашырыр өчен илһам чыганагы булуын телим!

Фотолар КДЭУның матбугат хезмәтеннән алынды.

ЧАҢГЫЧЫЛАР ГАИЛӘСЕ БАШЛЫГЫ

Берничә ел элек, Татарстанның чаңгы җыелма командасы инде берничә ел рәттән Россиядә иң яхшы булып танылгач, Татарстан Республикасы Чаңгы ярышлары федерациясе президенты Илшат Фәрдиев журналистларга болай дигән иде: «Ни өчен Татарстан чемпионатта җиңдеме? Чөнки ул – команда рухы көчле булган бер гаилә кебек». Сере Фәрдиев аңлатмасында «бер гаилә кебек» дигән сүзләрдә яшеренгәндер дә, мөгаен. Югыйсә Илшат Шәехович рейтингта 38 нче урынны алып торган команданы кыска гына вакыт эчендә ничек лидерларның берсенә әйләндерә алыр иде.

Елена Вяльбе, Россиянең Чаңгы ярышлары федерациясе президенты, өч мәртәбә Олимпия уеннары чемпионы

Фәрдиев бу спорт төрен яратучыларның барысын да бергә туплый алды: профессионалларны да, үзешчәннәрне дә, функционерларны да. Һәм, бу, чыннан да, әйтерсең, зур бер гаилә. Ә гаиләдә берсе икенчесе өчен җан атып тора, җиңүләр дә уртак казаныш буларак кабул ителә. Борчулар, уңышсызлыклар да бергә үтелә, авыр вакытта бер-берсенә иңен куймагач, нинди гаилә инде ул? Илшат Шәехович үзе – бу олы чаңгычылар гаиләсенең башлыгы, әтисе, ул барысын да туплап тота, бар нәрсәне дә оештыра, үз өстенә җаваплылык ала, хәлиткеч, язмышларын үзгәртерлек карарларны кабул итә, аларның җиренә җиткереп үтәлүен күз уңыннан ычкындырмый.

Мин үзем боларның барысын да күреп-белеп торганга, ышанып әйтә алам. Моны мин төрле очраклар мисалында раслый да алам. Менә бер очрак: әйдәп баручы Россия спортчылары кинәт кенә спонсорлар ярдәменнән колак какты. Күпләре үзләрен Татарстан чаңгы федерациясе командасына кертүләрен сорап, миңа мөрәҗәгать итте, шалтыратты. Мин, федерация җитәкчесе буларак, үзем дә аңа нәкъ шундый мөрәҗәгать белән чыктым. Фәрдиевкә әлеге карарны кабул итүе җиңел булмаганын яхшы аңлыйм, әмма ул аны кабул итте, спонсорларны ризалаштырыр дәлилләр дә таба алды... Чөнки аның чаңгычылар гаиләсендә бик әһәмиятле принцип яши: үзебезнекеләрне ташламыйбыз.

Бүген Татарстанның чаңгы җыелма командасына иң яхшы Россия чаңгычылары керә, аларның артына басып яңа буын – Татарстан яшьләре үсеп килә. Алар – иртәгәге көн йолдызлары. Монда яхшы гаиләдәге кагыйдәләр белән тәртипләр хөкем сөрә – өлкәнрәкләр кечкенәләрне тәрбияли. Үсеш өчен шартлар да бик яхшы куелган: Татарстандагы чаңгы трассалары һәм стадионнары Россиядә иң шәпләрдән исәпләнә.

Фәрдиевнең чаңгычылар гаиләсендә югары казанышлар спорты гына өстенлекле саналмый. Киң массалар, ягъни халык өчен спорт – Илшат Шәехович бу турыда да кайгыртучанлык күрсәтә, хәтта ки профессиональ спорттан да күбрәк көч бирә. Модульле чаңгы базалары, алардагы бөтен тиешле кирәк-яраклар – мондый спорт корылмалары һәр районда диярлек булдырылган, алар яңгырдан соң үсеп чыккан гөмбәләрне хәтерләтә. Массачыл ярышлар да даими уза, стартка кайчагында ун меңләп кеше чыга. Болар барысы да Казанның чаңгы башкаласына әверелеп баруы турында сөйли.

Татарстан башкаласында күптән түгел генә узган чаңгыроллерлар буенча чемпионат югарыда әйтелгәннәргә тагын бер дәлил. Серен дә ачып узыйм инде. Ярышлар барган көннәрдә Фәрдиевкә «Челтәр компаниясе»ндә килеп чыккан бер инцидент хакында җиткерәләр. Проблеманы төн буена хәл итәләр, шуңа да карамастан, төнлә керфек тә какмаган Илшат Шәехович икенче көнне иртән иртүк Мирныйда урнашкан чаңгы-биатлон комплексында иде инде. Ярышлар барган көнне ул, бик җаваплы кеше буларак, җентекләп, һәрнәрсәне үз контролендә тотты...

– Хөрмәтле Илшат Шәехович!

Үзегез күрсәткән үрнәк белән Сез бик күпләрне чаңгы спортына җәлеп итә, аның кирәклегенә ышандыра алдыгыз. Сәламәт яшәү рәвешен тормышның бер кануныя әйләндердегез. Киләчәк чемпионнарын әзерләү буенча чын мәгънәсендә югары дәрәҗәдәге спорт вертикале төзүгә ирешүегез Сезнең оештыру талантыгызны күрсәтә. Ярышларны исә шундый яхшы итеп уздыра беләсез, миңа хәтта: «Бик зур рәхмәт!» – дип әйтер өчен, татар телен өйрәнергә дә туры килде.

Сезне юбилеегыз белән чын күңелдән котлыйм. Үзегезгә дә, бер гаилә булып яши торган командагызга да спортта озын гомер, күркәм эшләрегездә уңышлар телим. Һәр җиңү финишыннан соң, яңа стартлар булып торсын, алда яңа мөмкинлекләр көтсен. Аларны да югары профессиональ дәрәҗәдә кабул итеп, башкарып чыгу Сезнең көчегездән килә.

Фотолар Россиянең Чаңгы ярышлары федерациясе матбугат хезмәтеннән алынды

«АҢАРДАН КӘНФИТ ИСЕ КИЛӘ ИДЕ...»

Фото: Нәсүр Йөрешбаев архивыннан

Луиза Янсуар

Нәсүр Йөрешбаевны без журналист, сценарийлар авторы һәм режиссёр буларак беләбез. Ул озак еллар ГДРда яши һәм анда калган татар эзләрен барлый, икенче бөтендөнья сугышы вакытында хәбәрсез югалган солдатларны эзли, безнең милләткә кагылышлы архивларны өйрәнә. Беренче Бөтендөнья сугышындагы татар-башкорт әсирләренең тавышлары яздырылган пластинкаларны табып, ватанга бу тавышларны кире кайтара. Гомере буена Муса Җәлил һәм Гайнан Кормаш төркемен, аларның язмышларын өйрәнә. «77 адым» дигән фильмның сценарий авторы.

2025 ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР ЕЛЫ

80 ЖИҢҮ!

– Балачак китапларыгыз нинди?

Алар күп түгел, тик мин аларны беркайчан да онытмыйм: «Мең дә бер кичә», «Су анасы», «Шүрәле», «Татар халык әкиятләре», «Капитан Грант балалары», «Шерлок Холмс», «Итил суы ака торур», Жюль Верн китаплары.

– Сезне шәхес буларак формалаштырган китаплар?

– Этель Лилиан Войничның «Кигәвен» әсәре, Гариф Гобәйнең «Маякчы кызы», Николай Островскийның «Корыч ничек чыныкты?», Александр Фадеевның «Яшь гвардия», Юлиан Семёновның «Язның унҗиде мизгеле» һ.б. китаплары.

– Европадагы китап культурасы беләндездәге нык аерыламы?

– Европада китапка ихтирам әйтеп бетергесез зур. Китап анда бик кадерле, китапны туган көнгә бүләк итү яки алу – зур мәртәбә. Китаплар анда бик төрле һәм күп чыга, гаять актуаль, уңайсыз темалар да күтәрелә. Матбугатта да яңа басмалар турында резонанс зурдан, алар турында бөтен җирдә дә сөйләшәләр, әңгәмәләр корыла. Китапханә, интеллектуаль даирәләрдә генә түгел, гомумән, бөтен җирдә: кухняда да, урамда да... Нинди дә булса яңа китап турында хәбәрдар түгелсең икән, бу... оят санала.

– Татар мәдәнияте гомер-гомергә китаплы булган, әмма күп кенә онытылган мирасыбыз безгә урау юллар кичеп кайтты. Сез үскәндә, алар турында бик үк ишетелмәгәндер дә...

– Мин Уралдагы бер авылның урта мәктәбендә 10 ел укыдым, классыбызда 36 бала иде. Барыбыз да татарча сөйләшәбез, русчаны юньләп белмибез дә. Минем русча әйткән беренче сүзем – «далеко». Урамда уктан атып уйнап йөргән ике рус малае бар иде, шулар һавага очкан укка карый да: «У-у-ух, далеко-о-о!» – диләр. Шуннан бу сүз миңа кереп калды. Икенчесе – «зола». Без мәктәптә укыганда тырыша-тырыша тимер-томыр, чүпрәк, сөяк, кәгазь, агач кайрысы һәм көл җыя идек. Йорт саен йөреп. Бездән ерак түгел генә Наумовлар дигән рус гаиләсе яши. Шуларга кермәкче булам, әмма көлнең русча ничек булганын белмим. Әти әйтте: «Зола, улым», – диде. Шул сүзне карандаш белән учыма язып, барып кердем. Тик: «Дайте,

Лейпцигта беренче татар китабын кулга алу мизгеле.

пожалуйста, золу», – дияргә сүз запасым җитмәде. «Зола», – дип тик тордым. Карчык миңа бик озак текәлеп карап торды-торды да, елмаеп, бер чиләк «зола» алып чыгып бирде. Безнең класс көл җыю буенча беренче урын алды! Шуннан соң, русчаны яхшырак өйрәнү максаты белән китапханәгә киттем. Анда нинди генә китап юк иде! Мине бәхет басты...

Сабан туе җитсә, Казаннан бик күп китап кайтаралар иде. Мин шешә җыеп акча эшлим дә, шуларны барып сатып алам. Ачам да күрәм: «Бауман урамы», «Татарстан китап нәшрияты» дип язылган. Күз алдыма китереп карыйм: имештер, ул Бауман дигән урам тулы китап, кеше сумка-сумка китап ташый, машиналар да, атлар да китап ташый, ә юл буенда карт бабайлар китап язып утыралар. Казан миңа серле тауда утырган ак шәһәр кебек күзаллана иде. Тау артында – дәрья, анда җилкәнле кораблар йөзә. Үсеп җитеп, бер чиләк алма сатып алам да, җәяүләп шул сихри калага барам, дип хыяллана идем.

Шундый вакыт җитте: Казанга поездда килдем. Университетта укыган чакта Әбрар Кәримуллинның «Язмыш, язмыш...» китабына юлыктым. Анда Лейпциг шәһәрендә сакланып калган беренче татар китабы турында язылган иде. Шул китапны табарга хыяллана башладым... 12 ел үткәч, Германиягә барып, аны эзләп таптым!

Чыгарганда бик дулкынландым... Ул инде дөнья кадәр зур китаптыр шикелле... Алып чыктылар моны. Якынча 20 сантиметрга 17 сантиметрлык басма. Өстәлгә куйдылар. Немецлар мине күзәтеп тора. Урындыкка утырдым да китапка төбәлдем. Нишләргә белмим, тирләдем-пештем. Әкрен генә ачтым да иснәп карадым: ни гаҗәп, аннан кәнфит исе килә иде...

– Сез Германиядән алып кайткан татар әсирләренең җырлары һәм аннары бу юнәлештә алып барган эшчәнлек зур игътибарга лаек. Кайсы төп чыганакларны өйрәндегез?

– Әлбәттә, журналист булып эшләүнең үз плюслары бар. Миңа Германия канцлеры Меркель белән генә дә 6 мәртәбә очрашырга насыйп булды. Төрле архивларда эшләдем, озаклап казындым һәм бер мәлне Лейпциг архивында кызыклы китапка юлыктым: «Татарские тексты». Ул немец телендә үзе. Укый башласам, шаккаттым! Бу Готтхольд Вайльның Беренче Бөтендөнья сугышындагы әсир төшкән татар-башкорт солдатларыннан язып алынган пластинкалардан текстка күчермәсе булып чыкты. Димәк, кайдадыр пластинкалар да булырга тиеш! Берлинга томырылдым... Гумбольдт университетында бер ханым белән таныштым. Ул миңа бик булышты. Акрынлап пластинкаларның эзенә төштек, «хуҗасын» таптык.

Архивта рәсми очрашу алдыннан төне буе йоклый алмадым. Икенче көнне, очрашкач, сорадым: «Миңа кадәр бу пластинкалар эзеннән кем дә булса килдеме?» «Юк», – дип җавап бирделәр. Шул җавапны ишеткәч, мин, биштәремнән Татарстан Республикасы флагын алдым да өстәлдәге вазага урнаштырдым. Йөз ел элек яздырылган татар әсирләренең тавышларын елый-елый тыңладым. Иң тәэсир иткәне – «Аһ, заман, заман»...

– Хәзерге көндә Европа, дөнья архивлары белән фондларында татар тарихына, язмышына кагылышлы без белмәгән чыганаклар да бардыр...

– Татар тарихы чәчелмәгән, таралмаган урын җир шарында юктыр ул. Антарктида белән Арктикада да бардыр, бәлкем... Мәсәлән, эзләнүләр вакытында мин татар әсирләре уйнаган уен кораллары теркәлгән чыганаклар да таптым. Алар Көнбатыш Германиядә саклана. Алып кайтасы иде! Болар бит – уникаль архивлар! Аларны еламыйча тыңлап булмый... Җырларны карагыз сез, шулкадәр чиста, сыйфатлы яздырылганнар! Ә бит яздыру вакытлары – 1916–1918 еллар!

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре мөрәҗәгать итте: Дрезденда «Фляйшер каталогы» булырга тиеш, диләр. Барып таптым, күчермәсен Казанга алып кайттым. Ул каталогта татар мәдәниятенә, тарихына кагылышлы 400ләп ядкәр теркәлгән. Андагы архивларда безнең тарих ята...

– Август – җәлилчеләр ае, сез Җәлил һәм аның аркадашлары темасына гомер буе мөрәҗәгать итәсез...

– Җәлил-Кормаш төркеме тарихында әле бик күп «ак таплар» бар. Сораулар күп, мәгълүмат аз. Иң беренче чиратта, бу теманы өйрәнүче һәркем Рафаэль Мостафинга мөрәҗәгать итәргә тиеш, билгеле. Мин аның эшләрен кайта-кайта укыйм, кулланам. Шулай ук – Шәйхи Маннурны, Рөстәм Гыйльметдиновның «Операция «Шаровая молния», Шаһинур Мостафин китапларын. Искәндәр Гыйләҗевның яңа эзләнүләре игътибарга лаек. Бу өлкәдә шулай ук язучылар һәм әдәбият белгечләре, музейчылар Вахит Имамов, Михаил Черепанов, Фәрит Баттал, Луиза

«Атилла хәзинәсе» фильмында төшкән балалар белән.

Янсуар, Рафис Корбан әзләнә. «77 адым» киносценариен язганда, мин бик күп материал белән таныштым, бу юнәлештә безгә тукталып калмаска кирәк.

– Сез кайсы телләрдә укыйсыз?

– Иң беренче чиратта, татар телендә. Шулай ук – башкортча, русча, немецча. Польша архивларында казынганда, азрак поляк телен дә үзләштердем.

– Өстәл китапларыгыз нинди?

– Хәзерге көндә Җәүдәт Сөләйманны укыйм. Миңа аның белән Казанда очрашырга насыйп булды, китапларын бүләк итте. Фәлсәфәсе бик ошый. Уйлары яшәргә көч бирә. Хәзер өстәлемдә берничә бестселлер авторы, немец язучысы Ландольф Шерцерның «leben im schatten der stuerme» («Жизнь в тени штормов») китабы да. Өченче китап – дустым Линар Әхмәтҗановның «Агент русской разведки» маҗаралы детективы.

– Электрон китаплар, кушымталарны кулланасызмы?

– Хәзерге көндә аларсыз булмый.

– Татар менталитетын, асылын аңлар өчен, һәр кеше укырга тиешле төп әдипләр, сезнеңчә, кемнәр?

– Һәр милләтнең асылын аңлар өчен, иң башта аның тарихы белән кызыксынырга кирәк. Кол Гали, Габделҗаббар Кандалый, Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Габдулла Тукай, Һади Такташ, Гаяз Исхакый, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил, Әмирхан Еники, Хәсән Туфан. Болар – безнең үлемсез классиклар, аларны белү нигез шарт, дип уйлыйм. Алардан кала, билгеле, милләтнең заман язучыларын да укырга кирәк. Алар бик күп.

– Татар әдәбиятына, сезнеңчә, нинди жанр-формалар, юнәлешләр җитеп бетми?

– Маҗаралар, детективлар.

ФИЛЬМОГРАФИЯ:

1. **«Трасса», 2002 (документаль фильм)**
«Уренгой – Помары – Ужгород» газ трассасы төзелешенә һәм бу «гасыр төзелеше»ндә катнашкан ун меңләгән немецның язмышына багышланган.

2. **«Иван Петрович, или Что такое русская душа?», 2003 (документаль фильм)**
Немец дустының «Нәрсә соң ул рус җаны?» дигән соравына җавапны Нәсүр Йөрешбаев белән алар Уралга кайтып һәм Россиянең йөрәгенә үтеп кереп эзлиләр.

3. **«Звуки курая над Сеной», 2004 (документаль фильм)**
1812–1814 еллардагы походларда рус армиясендә, руслар белән беррәттән, империянең башка халыклары – татарлар, башкортлар, калмыклар, якутлар да сугыша...

4. **«Легенда о Запорожце», 2013 (документаль фильм)**
Германиядә культ дәрәҗәсендә йөргән автомобильгә багышлана.

5. **«Два узника: Джавит и Вальтер», 2013 (документаль фильм)**
Фильм ике өлештән тора. Беренчесенең герое – Уралдан Икенче Бөтендөнья сугышы ветераны һәм аның Германиядәге концентрацион лагерьдагы әсирлеге тарихы. Икенче өлештә – Кызыл Армия тарафыннан пленга төшерелгән, Уралдагы хәрби әсирләр лагерена озатылган немец солдатының язмышы.

6. **«Не потерянная деревня», 2013 (документаль фильм)**
Россиянең Урал урманнары эчендә урнашкан, бушап, югалып барган авыллары турында.

7. **«Танки Германии», «Танки СССР», «Танки мира», «Поезда СССР», «Трактора СССР» документаль фильмнар сериясе, 2014**

8. **«Нигез йорт» («Отчий дом»), 2017 (нәфис фильм)**
Галимҗан Гыйльмановның хикәясеннән үсеп чыккан бу фильмда туган йортын калдырып китәргә теләмәгән Сания әби белән аның балалары арасындагы каршылык гәүдәләнә. «Кем без – туган нигезсез?» дигән сорауны куя заман тамашачысы алдына режиссёр.

9. **«Авторучка», 2020 (балалар өчен нәфис фильм)**
Әлеге фильм авылларда беренче тапкыр авторучка пәйда булган вакытка алып кайта, ул маҗараларга корылган. Беренче мәртәбә мәктәп диварларында төшерелгән һәм кино сәнгате аша педагогик максатларны тормышка ашырган тасма.

10. **«Атилла хәзинәсе» / «Сокровище Аттилы», 2024 (балалар өчен нәфис фильм)**
Атилланың хәзинәләр белән тулы югалган сандыгын эзләүгә корылган маҗаралы фильм.

11. **«Беренче басма татар китабы эзләреннән» / «В поисках первой печатной книги татар», 2024**
Әлеге тасма күренекле татар галиме Әбрар Кәримуллинның 100 яшьлек юбилеена багышлап төшерелгән.

КӨМЕШ-КҮЛ: ИСЕМ ҖИСЕМГӘ ТУРЫ КИЛСӘ...

Фото: Лилиана Вәлитова

КӨМЕШ-КҮЛ

Җәйнең санаулы көннәре калып барганда Мамадыш районының иң матур исемле авылына сәяхәт кылдык – Көмеш-Күл. Баксаң, авылның атамасы элек башкача булган. Егерменче гасырның уртасында, төгәлрәк әйтсәк, 1954 елда халык, үзара киңәшләшеп, әнә шундый исем сайлаган. Дөрес, авылда әлегә көмеш күл юк. Тик бик тиздән исеме җисеменә туры киләчәк икән.

Руфия Фазылова

ИЗГЕ НИЯТНЕ ТОРМЫШКА АШЫРУ

Көмеш-Күл әлләни зур авыл түгел: 36 хуҗалык бар, 298 кеше яши. Мәдәният йорты, төп белем бирү мәктәбе эшли. Соңгысы капиталь төзекләндерүдән соң балкып тора. Бирегә балалар бакчасын, авыл җирлеге идарәсен дә күчергәннәр. Мәктәп янына ук яңа ФАП салып куйганнар. Кыскасы, бу урын авылның үзәге хәзер. Аеруча уку елы дәвамында күңелле икән: укучылар мәктәпкә килә, кайта...

Җәен исә авылның «үзәге» су буена күчкән. Хәер, әле быел гына шулай. Ни өчен дигәндә, биредә бик матур балалар мәйданчыгы эшләгәннәр. Элек монда Сабан туе бәйрәмнәре узган. Соңгы елларда ул ярым ташландык хәлгә килгән булган. Һәм шушы авылда туып, хәзер Кукмарада яшәүче шәхси эшмәкәр Алмаз Гатин әлеге урыннан алма бакчасы да булган ял итү урыны ясарга ниятләгән.

– Без биредә уйнап үстек. Бу әле төзекләндерүнең башы гына, алга таба планнар зурдан, – диде Алмаз. – Дөресен генә әйткәндә, болай ук зурдан кубып эш башлау түгел иде. Язын тау башындагы талларны чистартып, алмагачлар утырттым. Шуннан соң уйладым да: «Тукта әле, балаларга уйнарга мәйданчык та булсын», – дидем. Әнә шулай башта тимердән беседка, аннан соң атынгычлар

Мәктәп капиталь төзекләндерүдән соң балкып тора.

Мәктәп янына ук яңа ФАП салып куйганнар.

алып кайттым. Хәзер авыл балалары көннәр буе монда мәш килә. Ата-аналар килеп каткат рәхмәт әйтә.

Алга таба Алмаз чишмә буен да матурларга уйлый: әлегә ул инеш булып кына ага. Чыганакны казып, чишмәгә йорт эшләп куйсаң, һичшиксез, әлеге урынның бизәге булачак ул.

– Авылның исеме Көмеш-Күл бит, – дип дәвам итте Алмаз Гатин. – Шушы урынга күл ясарга дигән ният тә бар. Ә нәрсә, инеш агып тора, буып куясың да менә сиңа күл. Аннан соң инде балыклар җибәрергә дә мөмкин.

– Көмеш күлдә алтын балыклар йөзәргә тиештер инде, – дим.

Алмагач бакчасы булган ял итү урыны ясарга ниятләгән Алмаз Гатин.

Хәзер авыл балалары көннәр буе монда мәш килә.

– Насыйп булсын. (Көлә).

Су буендагы мәйданчыкта пылау пешерергә казан, кулъюгыч, өстәл – барысы да бар. Бирегә һәр теләгән кеше килеп утыра ала икән. Тик бер шарт бар – хәләл кануннары сакланган булырга тиеш. Алмаз Гатин үзе дә диндәге кеше. Бу яктан Көмеш-Күлне иманлы авыл дияргә мөмкин, биредә күп хатын-кызлар намазда, хәер, ир-атлар да калышмый.

«ЧИШМӘГӘ ДӘ, КИБЕТКӘ ДӘ БЕРГӘ...»

Су буеннан кайтып килгәндә, чиләккөянтә аскан апаларны очраттык. Пардан киенгәннәр. Авылның «Мирас» ансамбле икән. Әллә көн саен шулай йөриләрме дисәк, без киләсен ишетеп, алдан әзерләнгәннәр.

2014 елның октябрендә авыл апалары, бер төркемгә берләшеп, ансамбль оештырганнар. Иң кызыгы – алар җырларга гына түгел, чишмәгә, кибеткә дә бергә йөриләр!

– Ике көнгә бер җыелып чишмәгә суга төшәбез, аннан кайткач, кибеткә ипигә барабыз. Бишебез дә бергә фермада эшләдек, – диде Римма апа Галиуллина. – Шулай булгач, кызлар белән гомергә бергә яшәдек, дип әйтә алам. 2014 елны лаеклы ялга чыктым. Ирем мәрхүм булды. Һич онытмыйм: капка төбенә чыгып, балаларны озатып калдым. Үземә генә күңелсез, моңаеп басып торам шулай. Карасам, урамнан авылыбызның мәдәният йорты җитәкчесе Рифат Хәсәнов узып бара. Минем халәтемне күрде дә: «Римма апа, болай ямансулама син. Әйдә, бүген кич клубка килегез. Фермада эшләгән кызларга да әйтермен, җыелышып сөйләшик»,- диде. Әнә шулай итеп ул көнне клубка җыелдык, ансамбль оештыру турында сөйләштек. Рифат оста гармунчы, Алабуга мәдәниятагарту училищесын тәмамлаган оста белгеч тә. Репертуарны үзе сайлый, аннан бергәләп өйрәнәбез. Рифат безгә баянда уйнап тора, бик күңелле яшибез.

Шулай оешкан ансамбль бүген район, республика буенча җырлап йөри, төрле конкурсларда катнаша, җиңүләр яулый. Апаларның костюмнарына игътибар иттек: чигүле ак яулык, чигүле алъяпкыч. Алар шундый үзебезчә, матур!

– Заказга чиктердегезме? – дим.

– Юк, заказга түгел. Чигүчебез дә, тегүчебез дә үзебездә! – диеште апалар.

«Тегүче дә, чигүче дә» дигән кеше – Рәйхана Җиһаншина икән. Тумышы белән Көмеш-Күлнеке. Мәрхүм җәмәгате белән өч кыз, ике ул үстергән. Бүгенге көндә үзе генә яши. Белмәгән эше юк, аның кебекләр турында «Баскан җирдән ут уйната», диләр. Рәйхана апа безне өенә чакырды. Бермәл телсез калдык: биредә бөтен әйбер чигүле. Иң гаҗәпләндергәне: бизәкләр бер-берсенә охшамаган!

– Рәйхана апа, әллә сез безгә күрсәтергә дип шулай күргәзмә эшләдегезме? – дибез.

– Юк, мендәр, япмаларым – барысы да чигүле. Һәм алар гел шулай тора. Дөрес, бала-

«Мирас» ансамбле апалары җырларга гына түгел, чишмәгә, кибеткә дә бергә йөриләр.

Рәйхана Җиһаншинаның кул эшләрен төрле күргәзмәләргә дә сорап алалар.

лар, кайткач, мендәр тышларын алыштыралар. Сөлгеләрне дә шулай чигүле, урындык япмаларын да үзем бәйләдем. Матурлык яратам, шул гына.

Моңа өстәп, хуҗабикәнең тавышы да моңлы икән: җырлап күрсәтте.

– Җәмәгатем Наил бик акыллы иде, дүрт ел элек яман чирдән мәрхүм булды. Бик сагынам үзен. Кичләрен әнә шулай уйларга бирелеп чигәм, бәйлим. Җырлап та җибәрәм, елап та алам. Әле бер кызым авылда калды, почтада эшли. Калган дүртесе Чаллы шәһәрендә яши. Рәхмәт балаларга, кайтып йөриләр. Ун оныгым бар, алар да, дәү әни, дип кенә тора. Тик менә бабаемны барыбер бик сагынам.

«Мирас» ансамбленә килгәндә, бу аларның инде икенче костюмнары икән. Беренчесен дә Рәйхана апа үз куллары белән теккән булган.

– Әни бик оста чигүче иде, – дип дәвам итте Рәйхана апа. – «Аятел Көрси» догасын чиккәнен дә хәтерлим. Безнең өйдә бөтен нәрсә чигүле иде. Кияүгә чыккач, мин аларны әле күчереп чиктем. Ә үзем өченче улым Фирзәр белән декрет ялында утырганда гына ныклап торып чигә башладым. Хәзер дә төрле матур үрнәкләр эзлим. Кайчагында хәтта телевизордан да фотога төшереп алам. Өйдә Наилнең әбисе чиккән бик матур мендәр тышлары бар иде, аннан да карап эшләдем.

Рәйхана апаның кул эшләрен төрле күргәзмәләргә дә сорап алалар икән. Сабан туйларына дип, заказ буенча да сөлгеләр чигә. Әле җәен иң олы оныгын кияүгә биргән. Аңа да бик матур чигүле бирнә әзерләп биргән.

КИЛЕН-КАЕНАНАЛЫ НИГЕЗ

Көмеш-Күлдә шуңа игътибар иттек: киленкаенаналы йортлар күп. Хәтта моңа бераз аптырадык та, кем белән генә сөйләшә башласаң да, фәлән ел каенанам белән яшим, диләр.

Әнә шундый гаиләләрнең берсе – Кашаповлар. Саимә апа әлеге йортның иң өлкән кешесе – күптән түгел 89 яшен тутырган. Мамадыш районының Козгынчы авылыннан җитмеш ел элек бу авылга килен булып килгән. Бүгенге көндә улы Райнур, килене Дания янәшәсендә бик матур картлык кичерә.

Саимә апага без киләсен алдан әйткәннәр: дулкынланып көтеп торган.

– Хуш килдегез, әйдә, әйдә, – дип ишек төбенә үк чыгып каршы алды. Югыйсә улы белән килене дә янәшәдә, әмма Саимә апа үзен хуҗа итеп хис итә.

– Башта шуны әйтим әле балалар: бүген оҗмахта яшибез. Без – бер телем ипи ашарга тилмереп үскән балалар. Ә бүген карагыз, өстәлләр ризыктан сыгылып тора! Эх, эти белән әнине бер генә көнгә алып кайтып, шушы тормышларны күрсәтер идем...

Саимә апа гомер буе колхозда хезмәт куйган. Төрле эшләрдә булган: утын ташыган, язын-көзен кырда эшләгән, кышын исә басуда печән, салам эскертләрен кардан чистарткан.

– Элек кар ферма биеклеге була иде, – дип искә алды Саимә апа. – Буран вакытларында адашмас өчен, арканның бер очын – билгә, исенчесен ат чанасына бәйләп, печән эскертен чистартырга китә идек. Аннары ат йортүче ир-ат арканны тарта да, без шуның буенча киләбез. И, ул чордагы тормыш авырлыкларын сөйләп-аңлатып кына булмый...

Саимә ападан авыл тарихы турында сораштык. Ул килен булып төшкәндә, авыл бермә-бер зуррак булган. Яше-карты «Искра» колхозында эшләгән. Ә менә мәктәп башлангыч кына булган. Бары тик 1983 елда Көмеш-Күлдә урта мәктәп ачыла. 2014 елда исә төп белем бирү мәктәбе булып кала.

– Революциягә кадәр авылда ике мәчет булган, – диде Саимә апа. – Мин килен булып төшкәндә, аларның берсе дә юк иде инде. Шулай да Көмеш-Күл халкы барыбер диннән ваз кичмәде. Җомга намазларына да җыелды халык, Коръән ашларын да уздырдык.

Кашаповлар – авылның үрнәк гаиләсе.

1998 елда авылыбызда мәчет төзелде. И, шуңа куанганнар.

Саимә апа авылның ак әбисе – күп еллар Көмеш-Күлнең остабикәсе булган. Хәзер инде бу эшне яраткан килене Дания апага тапшырган. Әниләренең бер җөмләсен дә бүлмичә, елмаеп тыңлап утыручы Райнур абый белән Дания апага таба борылдык. Ир белән хатын кырык елдан артык бергә тату гомер итә икән. Бер ул, бер кыз үстергәннәр. Райнур абый гомер буе урманчы булып эшләгән. ТРның атказанган урманчысы әле быел гына лаеклы ялга чыккан. Дания апа исә унтугыз елдан бирле Көмеш-Күл мәктәбе директоры булып хезмәт куя. Мөгаллимлек стажы 43 елга тулган, ТРның атказанган укытучысы. Туганнар, авылга кунакка килгән кешеләр – барысын да матур итеп каршы алып, кунак итеп озатып кала.

– Җитәкче хатын-кыз белән яшәү авыр түгелме? – дидек Райнур абыйга.

– Ул бит өйдә кайгыртучан хатын, сабыр килен, – дип елмайды гаилә башлыгы. – Әни белән дә гомергә тату яшәделәр. Әллә нәрсә мактанып утырасым да килми, шөкер, янәшәмдә гел яхшы хатын-кызлар минем.

Дания апада әчке бер тәрбиялелек сизелә. Директор ханым безне Көмеш-Күл мәктәбендә каршы алган иде, шунда чакта ук аның бу сыйфатына игътибар иттек. Ә Дания апа ясаган чәйнең тәмлелеге! Районга берәр кунак килсә, аны чакыралар икән. Җәен төрле үләннәр җыеп, җиләк-җимештән нинди генә кайнатма ясамый. Нәтиҗәдә, иң тәмле чәй белән сыйлаучы исемен алган.

– Мин әнигә дә, Райнурга да бик рәхмәтле, – диде Дания апа. – Үземнең әти белән әни картайгач, без аларны монда алып килеп тәрбияләдек. Әти биш ел урын өстендә булды. Без иртән эшкә чыгып китәбез, каенанам алар яныннан китмәде: тамакларын кайгыртты, сөйләшеп утырды. Тормыш бит ул җырлап-биеп кенә узмый, аның төрле чаклары була. Ир белән хатын авыр вакытта бер-беренә терәк икән, бу гаилә нык дигән сүз.

– Саимә апа әле хәзер дә җитез күренә, сөбханалла. Яшь чагында тагын да үткен булгандыр, – дим.

– Әнинең бер усаллыгы да юк. Гомергә безнең тормышка кысылмады. Аннары ул бит күп еллар диндә булды, ә намазлы йортка бәрәкәт иңә. Мин дә әнидән карап намазга бастым, шөкер, мәдрәсә дә тәмамладым. Менә шулай дөньялык белән динне бәйләп яшәп ятыш.

«ХАЛЫК ӘЙБӘТ БЕЗДӘ»

Көмеш-Күл авыл җирлеге башлыгы Илгизәр Сәләхетдинов белән авылны йөреп чыктык. Фермерлар күп икән биредә. Пай җирләрен авыл халкы берләшеп, бүлеп алган: үзләре эшкәртәләр. Бу исә авылның тырышлыгы турында сөйли. Авыл җирлеге башлыгы белән күрше Зур Өске авылына да барып килдек, ул Көмеш-Күл җирлегенә керә. Биредә авылның имамы Рафис Саматов, иганәчеләр тырышлыгы белән чишмәләр каралган. Җиде улаклы чишмәне күреп ис китте.

– Ел саен 500әр сум үзсалым акчасы җыябыз, – диде Илгизәр Сәләхетдинов. – Ул акчага күбрәк юллар карыйбыз, күпер дә ясадык. Әле менә быел дәүләт программасы нигезендә авылга кадәр юл яңартыла. Моңа бик сөендек. Халык әйбәт бездә, иң зур байлык шул.

Чынлап та, Көмеш-Күлнең кешеләре әйбәт. Алар әллә нинди затлы йортларда да яшәми, әмма мондагы халыкның күңеле бай. Монда элеккечә күрше күршегә хәл белешергә керә, эшләр дә уртак. Инде татар авылларында югала барган күп кенә матур традицияләр сакланган биредә, монысы аеруча кыйммәтле тоелды.

Күрше Зур Өске авылы чишмәләрен күреп сокландык.

ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

1954 елга кадәр Көмеш-Күл авылы Биләтле исеме белән йөри. Әлеге авылга бәйле документлар архивларда 1680 нче еллардан ук башлана.

Биләтле – борынгы болгар-татар телендәге билән – «батынкы җир, ияр кебек билләнеп эчкә кереп торган чокырлы урын» дигәнне аңлата дип карала. Авылда хәзер дә нәкъ менә шундый урыннар күп. Авылны урталайга бүлеп Өске елгасы үтә.

Гөлзия Сәләхетдинова, Көмеш-Күл төп белем бирү мәктәбенең тарих укытучысы

афиша

МӘСКӘҮ КАЗАК ХОРЫ КОНЦЕРТЫ (6+)

Бию номерлары, көрәш элементлары, сөңгеле трюклар һәм кылыч фланкировкасы белән үрелеп барган дәртләндергеч һәм гаҗәеп мавыктыргыч тамаша. Һәм, әлбәттә инде, борынгы казак җырларының тылсымлы күптавышлылыгы... Әлеге концерт программасы тамашачыга казак халкының җырлары, көнкүреше һәм мәдәнияте традицияләренең бай тарихына кагылу мөмкинлеген бирә. Халыкара, бөтенроссия конкурслары һәм фестивальләре лауреаты, Россиядә дә, аннан читтә дә танылуга лаек Мәскәү казак хоры башкаруында казак халкының лирик, шаян-биюле, туй, сугыш, поход җырлары яңгырый.

24 август, 18:00
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе
Казан, Павлюхин ур., 73

ГҮЗӘЛ ЭПОХА ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ (12+)

Дәүләт Эрмитажыннан сирәк кузгатыла торган җәүһәрләрне «Гүзәл эпоха. XIX гасыр азагы – XX гасыр башы Европа сәнгате» экспозициясендә күреп була. Анда Камиль Писсарро, Клод Моне, Поль Гоген, Андре Дерен, Огюст Ренуар, Анри Море, Альфред Сислей, Поль Сезанн, Анри Матисс, Пабло Пикассо, Анри Руссо, Альфред Моурер, Альфонс Муха, Анри де Тулуз-Лотрек, Эжен Грассе һәм башка бөек осталарның 175 чын картинасы куелган. Барлык картиналар Belle Epoque, яки Гүзәл эпоха (Европа тарихының XIX гасыр азагыннан алып 1914 елга кадәр чоры шулай атала) вакытында язылган. Әлеге дәвер сынлы сәнгатьтә һәм бөтен дөнья тарихында үзгә бер урын алып тора. Европа өчен иң бәхетле һәм ваемсыз еллар бу, гөрләп үсү, тынычлык, муллык эрасы. Һәм барыннан да бигрәк Франция өчен – Belle Epoque атамасы шунда туган. Гүзәл эпохада иҗат ителгән даһи әсәрләр – кешелекнең бөек мирасы.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне
«Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 нче кат
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

СУГЫШ ЧОРЫ РЕЛИКВИЯЛӘРЕ (12+)

Танылган совет хәрби җитәкчеләре Иван Конев, Федор Толбухин, Василий Чуйков, Николай Ватутин, Иван Черняховский һәм башкаларның шәхси әйберләре, кием-салым һәм кораллары Туп сараендагы күргәзмәдә тәкъдим ителә. Килүчеләр Ватаныбызның утлы һәм салкын коралларын, шулай ук трофей үрнәкләрен күрә ала: Дегтярев системасы танк пулемёты, ТТ пистолеты, 1931 елгы Вальтер системасы пистолеты, 1927 елгы кавалерия шашкасы. Күргәзмә экспонатлары арасында Советлар Союзының беренче маршалларыннан берсе Климент Ворошиловның пальтосын, шулай ук 1941–1942 елларда Казанда Генштабның югары махсус мәктәбенең разведка кафедрасы мөдире булган бронялы танк гаскәрләре маршалы Павел Рыбалконың шәхси әйберләрен күрергә була. Барлык бу уникаль предметлар – Россия Федерациясе Кораллы Көчләре Үзәк музее һәм «Казан Кремле» музей-тыюлыгы фондларыннан.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр
(җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)
Дүшәмбе – ял көне
Туп сарае музее
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

Фото: kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, tatfil.ru, kamalteatr.ru

КӨТӘР КЕШЕҢ БАРМЫ? (16+)

«Бу тарих Ленинградта, шәһәр урамнарының берсендә, шул урамның бер йортында булды. Ул әлеге биш кичтән алданрак башланган иде һәм әле тиз генә тәмамланмас та. Кыш, кичен кар ишә. Ул мәктәп каникулларын, ишек төбендәге очрашуларны, үткән кышларны күңелдә яңарта...» Үзенең иң танылган «Биш кич» пьесасын драматург Александр Володин әнә шулай башлый. Һәм бөтен пьеса төп герой шуларның уртасында кайнаган сугыш турында хатирәләр ачысы белән сугарылган. «Ә сугышка кадәр бередә минем беренче мәхәббәтем яшәгән иде», – ди Ильин беренче сәхнәдә. «Сугыш кына була күрмәсен», – дип тәкрарлый финалда Тамара. Әлеге конкрет тарихи вакыйгага бәйлелек XXI гасырның яшь режиссёрларын куркытырга яки аптырашта калдырырга тиештер кебек. Әмма Айдар Җаббаров башкача уйлый. Аның өчен әлеге вакыйга аерым чорга бәйләнмәгән – бу «Санаулы кичләр» үзен көтүче Хатын-кыз янына кайткан Ир-ат турында. Димәк, бу вакыйга Ленинградта, хәтта Санкт-Петербургта да түгел, бөтенләй башка җирдә, ихтимал, нәкъ менә бередә һәм хәзер булгандыр...

16 август, 17:00. Зур зал

Г. Камал исем. Татар дәүләт Академия театры (яңа бина)

Казан, Һади Такташ ур., 74

«ЮПИТЕРДАН» БОРЫНГЫ ОСТАЛАРГА КАДӘР (6+)

«Яңа караш» күргәзмәсендә XVII гасыр голланд рәссамнары полотноларын һәм борынгы Европа сынлы сәнгатенең башка уникаль әсәрләрен күреп була. Әлеге атама очраклы түгел: экспозиция – ТР Сынлы сәнгать музее тупламасын аның хезмәткәрләре һәм Пушкин исемендәге ДССМ белгечләренең бергәләп өйрәнүе һәм бәяләве нәтиҗәсе. Экспозициядә шулай ук XVI–XIX гасырлар Италия классик гравюрасы, шул исәптән Джованни Батиста Пиранези (1720–1778) эшләре тәкъдим ителә, алар арасында аның иң танылган хезмәте – 30 елга якын иҗат иткән «Рим күренешләре» сериясеннән үрнәк тә бар. Экспозиция раритетларыннан тагын берсе – антик керамика, аны кайчандыр музейга Дәүләт Эрмитажы тапшырган булган. Барлык предметлар да Грециянең Кара диңгез буендагы колонияләре үзәкләренә (Херсонес), шулай ук Боспор патшалыгы шәһәрләренә (Пантикапей (хәзер Керчь), Фанагория, Феодосия) карый. Көнбатыш Европа декоратив-гамәли сәнгате коллекциясеннән фарфор һәм керамика тәкъдим ителә, бу – Европа фарфор заводларының иң яхшы эшләнмәләре үрнәкләре, анда көнкүреш әйберләре дә, югары сәнгать әсәрләре дә бар. Тупланманың аеруча кызыклы өлеше – итальян майоликасы. «Юпитер» уникаль скульптурасы 1766 елда Тюрингиядә эшләнгән «Тәңре сыннары» сериясенә карый.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр

(пәнҗешәмбе – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)

Дүшәмбе – ял көне

ТР Дәүләт сынлы сәнгать музее

Казан, Сандецкий утары, К. Маркс ур., 64

ПАЛЕОЗОЙНЫҢ «ПРОГРЕССИВ РЕПТИЛИЯЛӘРЕ» (0+)

«Аномодонтлар – палеозойның теш экспериментаторлары» күргәзмәсендә моннан 260 млн ел элек яшәгән борынгы рептилияләрнең скелетларын һәм әлеге гаҗәеп җан ияләренең реконструкцияләрен күреп була. «Прогрессив» дип йөртелгән әлеге рептилияләр хәзерге Киров өлкәсе территориясендә динозаврлар пәйда булганчы яшәгән һәм планетада иң күп таралган үсемлек ашаучы җанварлардан саналган. Нәкъ менә шунда, Нократ елгасы буендагы Котельнич шәһәре янында, уникаль фауна комплексы табылган: 20 дән артык төр Пермь дәвере хайваны, шулардан 16сы моңарчы фәнгә билгеле булмаган һәм бик яхшы хәлдә сакланган.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр

(пәнҗешәмбе – 11:00 дән 20:00 гә кадәр)

Дүшәмбе – ял көне

Татарстан табигать тарихы музее

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

МИЛЛИ КИЕМ МОДАСЫ (0+)

«Казан Идел буе: халык мәдәнияте образлары» күргәзмәсендә XIX гасырның икенче яртысы – XX гасырның беренче яртысында яшәгән рус, татар, мари, мордва, чуваш һәм удмуртларның 40 тан артык милли кием комплексын күрергә була. Әлеге уникаль экспозиция – Татарстанда үткәрелгән зур фәннитикшеренү эше нәтиҗәсе. Киемнәрне яңадан торгызу өчен, музей фондларында, хосусый тупланмаларда, мәктәпләрдә сакланган сирәк экспонатларны өйрәнгәннәр. Нәтиҗәдә Татарстан халыклары традицион бәйрәм мәдәнияте үрнәкләренең уникаль галереясы пәйда булган. Проектта Идел буе төбәкләреннән 100 дән артык музей, галимнәр, тикшеренүчеләр, культурологлар катнашкан. Кием-салым, бизәнү әйберләре, аксессуарлардан тыш, экспозициягә ул чакта Идел буенда яшәгән халыкларның музыка уен кораллары һәм көнкүреш кирәк-яраклары да куелган.

Көн саен 10:00 дән 18:00 гә кадәр

(җомга 11:00 дән 20:00 гә кадәр)

Дүшәмбе – ял көне

Кабул итү урыннары күргәзмә заллары

«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

МИЛЛИОНМЫ, ӘЛЛӘ МӘХӘББӘТМЕ (12+)

Тәмам аерылышыр чиккә җиткән ике гаилә кызып-пешеп туйга әзерләнә. Тик яшьләр генә әлегә бу хакта берни дә белми. Айнур белән Рушания әти-әниләренең теләгенә буйсынырмы, әллә үз юлларын сайлармы? Нәрсә кыйммәтрәк? Миллионнармы, әллә эчкерсез мәхәббәтме? «Стоп, кода! Туй була!» комедиясе гаилә кыйммәтләренең асылын, бәхетнең нечкәлекләрен ачарга өйрәтә. Киңәш бирергә без барыбыз да оста. Тик менә үзебез тормышта киңәшләргә колак салабызмы соң?

27 август, 19:00

К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры

Казан, Горький ур., 13 Т

Казаныбызда сакланып калган, тарихлары милли мәдәниятебезнең асыл шәхесләре белән бәйле агач йортлар белән таныштыруны дәвам итәбез. «Казанның агач йортлары» проектын «Татарстан» журналы «Татар ядкәрләре» шәхси оешмасы белән берлектә эшли.

ФӘН ҺӘМ ИМАН ЯШӘГӘН ЙОРТ

Луиза Янсуар, Фәнзилә Җәүһәрова

Иске Татар Бистәсенең Каюм Насыйри, 10 А адресы буенча урнашкан йорт 1858 елда төзелә. Биредә 1858 елдан 1889 елга кадәр XIX гасырның мәшһүр татар мәгърифәтчесе, дин әһеле һәм белгече, фәлсәфәче, этнограф Шиһабетдин Мәрҗани яши. Халык теленә дә бу мәдәни ядкәр «Мәрҗәни йорты» дип кереп калган.

Фото: Александр Ефремов

АТАКЛЫ КУНАКЛАР ТУКТАЛГАН УРЫН

Биредә 30 ел яшәү дәверендә Шиһабетдин Мәрҗани искиткеч күп фәнни хезмәтләрен, атаклы китапларын яза. Алай гына да түгел, монда фәнни әңгәмәләр, фикерләшүләр, бәхәсләр дә яңгырап тора. Йортның сакланып калган диварлары үз заманының атаклы шәхесләрен «хәтерли» булса кирәк.

Шушы йортта татар мәктәпләре инспекторы, академик Василий Радловны, Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты Иосиф Готвальдны, профессор Николай Катановны кабул итә торган була Шиһаб хәзрәт. 1876 елның мартында, Көнбатыш Себергә китеп барышлый, бу йортта «Хайваннар тормышы» дигән атаклы китап авторы, алман зоологы Альфред Брем да туктала.

1889 елда, Шиһаб хәзрәтнең вафатыннан соң, йорт аның улы Борһанетдинга – Казанның Беренче Җәмигъ мәчете имамы милкенә күчә.

ЛАЛӘЛЕ КӘРНИЗЛӘР

Йорт ике катлы, катнаш конструкцияле: өлешчә – агачтан, өлешчә таштан эшләнгән. Урам якка фасады белән чыгып тора һәм биш тәрәзәсе белән карап балкып утыра. Керү ягы, йола буенча, – ишегалдында. Урамнан ул агач капка, дивар белән уратып алынган һәм «ябып» куелган.

Татар Бистәсенең үзенчәлекле архитектурасына хас булганча, кирпечтән салынган аскы каты хуҗалык итү өчен, өске агач каты исә яшәү өчен кулланылган.

Төп фасадның симметрик композициясе биш квадрат тәрәзәдән гыйбарәт, үзәк тәрәзәне аеручы тар такталар бар. Алар барысы да вертикаль рәвештә каймалап алынган һәм озынча ромблар белән бизәлгән. Беренче катның тәрәзә уемнары кечкенәрәк һәм бизәксез. Икенче кат тәрәзәләренең кәрнизе лалә чәчәкләре белән бизәлгән.

ШИҺАБ ХӘЗРӘТ РУХЫ

Истәлекләргә караганда, Мәрҗанинең бай китапханәсе булган. Әмма ул, ни кызганыч, 1918 елгы янгын вакытында харап булган.

2012–2013 елларда йортка реставрация ясала. 2017 елда, Шиһабетдин Мәрҗанинең 200 еллыгы уңае белән, эчке интерьер да ремонтлана. Элеккеге вакытта йорт ничек Иске Татар бистәсенең үзәге һәм бизәге булган булса, хәзер дә ул, әйтерсең, татарның бөек рухание рухын саклый.

2012–2013 елларда йорт реставрацияләнә, хәзер ул – республика әһәмиятендәге һәйкәл, агач төзелеш сәнгате үрнәкләренең берсе.

Ял итәргә чыккан шәһәр халкы һәм туристлар Кабан күле яр буенда Шиһаб хәзрәткә куелган бюст белән дә таныша ала. Аңа нигез итеп кайчандыр Бакый Урманче иҗат иткән сын алынган.





«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫН САТЫП АЛЫРГА

ozon.ru

market.yandex.ru

tatmedia.shop/ru

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНДА РЕКЛАМА БИРЕРГӘ

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер. 1925 ел

«Татарстан» журналының реклама бүлеге:

тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

«ТАТАРСТАН»ЖУРНАЛЫ ЯҢАЛЫКЛАРЫН УКЫРГА

protatarstan.ru

t.me/pro_tatarstan

vk.com/protatarstann

Реклама 16+